КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№ 2
28 июль
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

2 Рашат НИЗАМИ. Әгәр әхлак югала икән, тормышыбыз да теткәләп-тишкәләнеп беткән мескен бер алма хәленә калачак.

5 Дилбәр САИНОВА. Татарстанның әкияти төбәген — «Татар Швейцариясе»н коткару өчен нишләргә соң?

8 Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Мәктәптә татар телен бетерү дигәндә сәгатенә «йөз чакырым» тизлек белән чапсак, туган телебезне кире кайтаруда бер алга, биш артка карыйбыз.

16 Дамир ИСХАКОВ. Казан ханлыгы мәсьәләләрен үзәккә алган зур дәрәҗәле халыкара җыенның булганы юк. Кабер тынлыгы түгелме бу?

17 Надир ДӘВЛӘТ. Татарга бүген үз сәнгате, үз мәдәнияте аша дөньяга чыгарга кирәк.



Кулкубыз тартсаң — көй чыга, Бирәнә тартсаң — өй чыга...!

МИН ӘЙТТЕМ...

Рашат НИЗАМИ

Әхлакка кайтырга вакыт!



Әхлак ул — үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, кешегә җәмгыятьтә кирәкле рухи һәм эчке сыйфатлар, аларның гамәлдәге үтәлеше.

С.Ожегов. «Словарь русского языка».

Мин иң өлгереп җиткән мәсьәлә хакында ике генә сорауны куймакчы булам: җәмгыятебездә ни өчен әхлак югалды, аны төзәтер өчен нәрсә эшләргә?

Сүзне чагыштырудан башлыйк. Агачында өлгереп яткан алмага җәй көне бермәл кортлар хуҗа була: эченә-үзәгенә үтеп керәләр, тишеп-бораулап йөри торгач, аны тәмам теткәләп бетерәләр, кояштай балкып яткан җимешне чүплеккә ташларлык мескен бер йомрыга әйләндерәләр...

Җәмгыятебездә дә әнә шундыйрак күренеш күзәтелә. Әгәр әхлак югала икән, тормышыбыз да тетелеп-тишкәләнеп беткән мескен бер алма хәленә калачак.

Мисаллар белән мавыгасым килми. Чөнки һәммәсен укып та, ишетеп тә, көндәлек тормышта шәхсән күреп тә торабыз. Чынбарлыклар күз алдында ич: әйтик, Әрмәнстан һәм Чеченстан хәлләре — әхлаксызлыкның югары бер үрнәге ләбаса!.. Балык башыннан че-ри дигәндәй, иң аянычы шул — әхлаксызлык элек-электән югары даирәләр яшәешендә тамыр ныгыта, аннары аның үрнәкләре гади халык тормышына үтеп керә башлый. Әйтик, җитәкчеләр рәхәт яшиме-яши (бер уйласаң, хезмәтенә күрә шулай, икенче карасаң, «законный» итеп урлашулары да күзгә бәрелеп тора). Халык менә шуны күрә дә, угрылыкка үзенчә җай эзли: колхозчы әле саламын, әле арыш-бодаен, әле төзү кирәк-яракларын дигәндәй; эшче сыйныф завод-фабрикадан тегесен-монысын үз файдасына чөлдерүне кирәк таба.

Коммунистлар партиясе заманында рәсми хакимият безне идеологик «яңгыр» белән коендыра һәм тәрбияли килде. Без капитализмнан көлдек, дөресрәге, безне аңардан көләргә мәктәп эскәмиясеннән үк өйрәтә килделәр. Баксаң, «череп барган капитализм» дигәнебез череп баеган булып чыкты! Дәүләт дәрәҗәсендәге алдашу бик күпләрнең күңелен рәнҗетте, иманнарын какшатты.

Галимнәр әйтүенчә, хәзерге вакытта кешелеккә өч төрле куркыныч яный: атом сугышы, экологик афәт, рухи-мәдәни кыйммәтләрнең җимерелүе. Без менә хәзер соңгысының хәвефле җәтмәсенә килеп эләктек шикелле. Җинаятьчелекнең котыруы да әхлакый кыйммәтләрнең югалуына турыдан-туры бәйле. Аерым алганда, татар авылларыннан да шәһәргә таба бик көчле миграция, күчеш булды, илдәге зур-зур төзелешләр татар авылларының җелеген — эшче көчләрне үзенә суырып алды. Шәһәрнең «неон-капрон» тормышында андыйларның милли йөзе югалды, манкортлар күбәйде, субкультура үзгәрде. Әлеге гаиләләрдәге яшь, яңа буын сутсыз-тамырсыз шартларда үсте, иманын югалтты.

* * *

Җәмгыятебездә әхлак югалуның бик тә тирәнгә киткән тамырлары бар, билгеле. Гомумиләштереп алсак, аларны өчкә бүлеп карарга мөмкин:

Беренчесе — тарихи сәбәпләр.

Заманында чәчәк аткан Болгар дәүләтебез булган. Казан ханлыгыбыз да үз хакимияте, үз низам-тәртипләре белән мөстәкыйль яшәп яткан. Урыс дәүләтенең басып алу сәясәте татар дөньясын челпәрәмә китергән: рәхимсез сугыш, башка дин, колонизаторлыкның чит-ят тәртипләре, көчләп чукындырулар, халыкны курку астында тоту һәм башкалар... Без, менә шулай акрынлап, бар яктан урыс чолганышында калганбыз. (Уйласаң, Татарстан бүген дә Рәсәй чолганышында яшәп ята, ләбаса!) Динебез тапталган, мәсхәрә ителгән, мәчетләребез яндырылган. Большевиклар хакимияте исә бу эшне патшадан да тизрәк, аяусызрак хәл итте. Ә бит шәригать кануннары, кагыйдә буларак, әдәпкә, яхшылыкка, мәрхәмәткә генә өйрәтә. Бу рухи кыйммәтләрне таптау, югалту бик кыйбатка төште. Ә инде Рәсәйнең буйсындыру, башка халыкларны басып алу һәм алар өстеннән хакимлек итү сәясәте — җинаять иде. Җинаятьтә исә әхлак була алмый. Ничек инде чеченнар, ингушлар, татарлар, якутлар яисә эстоннар нәкъ менә урыс халкы төсле яшәп китсеннәр икән? Аларның бит гасырлар буена җыйналып килгән үз яшәеше, гореф-гадәтләре, үз тарихлары бар. Йөзләгән милләтне уртак бер коридорга куалап кертсеннәр дә «тигезләп» куйсыннар әле! Менә кайдан килә хатаның тамырлары. Рәсәй канаты астына килеп эләккән бик күп халыклар милли йөзен, гореф-гадәтләрен югалтуга дучар ителде, эчкечелеккә өйрәнде. Инде наркоманнар күренә башлады. Әйтергә кирәк, соңгы җитмеш елда гына да татарның генофондына өч тапкыр удар ясалды: гражданнар сугышы, шәхес культы, Бөек Ватан сугышы... Менә шушы канлы вакыйгалар сәхнәсендә татарның да иң акыллы, иң эшчән, иң зыялы вәкилләре юк ителде. Бу интеллектуаль байлыкны кире кайтару мөмкин түгел.

Әхлакның югала баруына китергән сәбәпләрнең икенчесе — иҗтимагый-социаль сәбәпләр.

Бер нәрсәгә игътибар итик әле: Җир шарының кайсы гына төбәгендә ызгыш-низаг килеп чыкмасын, аның сәбәпләре һәрвакыт милли мәсьәләгә барып тоташа. Рәсәй дигән империядә элек-электән йөзләгән милләтләр яшәде. Ләкин ни патша заманында, ни совет чорында милли мәсьәлә берничек тә гадел хәл ителмәде. Хәзер дә шулай. Большевиклар милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын таныдылар, гамәлдә исә шуның киресен эшләделәр. СССРны оештырганда республика, автономия һәм өлкә чикләрен ничек теләсәләр, шулай бүлгәләп куйдылар. Нәтиҗәдә, татарның да бик күп тарихи җирләре Оренбург, Ульяновск, Башкортстан һәм башка якларга ычкынды! Шуның аркасында без күпме тарихи бәйләнешләрне, әхлакый тамырларны, туган телебезнең үсеш мөмкинлекләрен югалттык.

Өченчесе — икътисади-сәяси сәбәпләр.

Рәсәй күп кенә өлкәләрдә, шул исәптән икътисади мәйданда да, гел экспериментлар белән шөгыльләнде. Алар күбесенчә гаделсез, фәнни-иҗтимагый яктан сай иделәр. Россия Америка капитализмын кабатларга тиеш түгел, дип саныйм мин үзем. Яхшы сыйфатлары бар икән — алыйк, үзләштерик. Заманында бит алар үзләре дә безнең бик күп идеяләребезне «суктылар» ич: фермерлык, хуҗалыкны планлаштыру, ясле-бакча оештыру һ.б. Аяныч булса да танырга туры килә: экономикабыз чирле. Авыл хуҗалыгын тәкә күтәрү буенча КПСС, әнә, заманында 700 ләп карар кабул иткән. Күтәрелдеме соң? Юк. Без биш катлы торак йортлар салып ятканда, японнар инде бишәр катлы юллар салып куйдылар. Әллә соң Рәсәй халкы алгарышка, тәрәккыяткә сәләтсез микәнни, дип тә уйлап куям кайчак...

Күңел тагын Америкага әйләнеп кайта. Үзенең 200 елдан артыграк тарихында анда бит бер генә бомбаның да төшеп шартлаганы юк. Ә империячел Рәсәйнең бөтен күкрәге диярлек ядрә белән тишкәләнгән, бомба белән ермачланган. Һәр тарафында кан һәм сугыш эзләре... Мондый илдә икътисад сәламәт була алмый, әлбәттә. Менә шуңа да мөстәкыйль Татарстан, яңа шартларда яңача яшәр өчен, үзенең мөстәкыйль экономик программасын булдырырга тиеш. Миңа калса, кытайлар әнә капитализм белән социализмның иң әйбәт сыйфатларын бергә кушып, интеграция юлын сайлап, яңа бер җәмгыять системасын барлыкка китерделәр шикелле.

* * *

Җәмгыятебезнең әхлагын кайтару, аны сафландыру һәм көчәйтү өчен нишләргә соң? Бу, әлбәттә, беренче чиратта сәясәтчеләр, белгечләр, җитәкчеләр эше. Әмма үз фикерләрем белән уртаклашу бер дә гөнаһ эш түгелдер. Минем уемча, якындагы беренчел бурычлар дип түбәндәгеләрне күрсәтеп китәргә мөмкин:

— үткәндәге һәм бүгендәге гөнаһлар өчен, кан коюлы сугышлар һәм рәнҗетелгән халыклар өчен Рәсәй хөкүмәте тәүбә кылырга, киләчәктәге юнәлешләренә төзәтмә кертергә тиеш. Әхлакны төзәтү мәсьәләсен нәкъ менә дәүләт дәрәҗәсендә күтәрү, хәл итү зарур. Юкса Рәсәй башка халыклар өстеннән көч белән идарә итү вазифасыннан рәсми төстә ваз кичмичә торып, чын әхлакка ирешүебез бик тә бәхәсле;

— Россия Федерациясе күләмендә милли мәсьәләләрне кичекмәстән һәм гадел төстә тормышка ашыру. Һәр милләтнең үсеше, халыклар арасында чын мәгънәсендә дуслык-туганлык чәчәк атсын өчен күркәм шартлар тудыру;

— хокукый яктан көчле законнар системасын һәм аларны тормышка ашыруның ныклы механизмын булдыру. Законнар бакчасында коррупция, мафия, рэкет һәм җинаятьчел төркемнәргә каршы аерым маддәләр дә чагылыш табарга тиеш. Бакчачы бит әнә корыган, зәгыйфь ботакларны кисеп ташлый һәм шуның белән агачларның алга таба сәламәт үсешенә ирешә;

— динне иҗтимагый тормышка якынайту, аны әхлакый сакчы итеп файдалану. Табигый буларак, Ислам дине татар халкын да рухи туплап тора, сафлык һәм яхшылыкка чакыра, әдәпле һәм иманлы булырга өйрәтә;

— милли мәктәп һәм гимназияләрдә дин, әхлак, эстетика дәресләрен предмет буларак укыта башлау;

— туган телебезне чын мәгънәсендә дәүләт теле итү, аның абруе өчен көрәшү;

— Татарстан Республикасының мөстәкыйльлегенә ирешү, аны нейтраль дәүләт дәрәҗәсенә күтәрү һ.б.

Күрәсездер, җәмгыятебезнең әхлагын тазарту дигәндә, бик күп эшләр башкарасыбыз бар икән әле. Моның өчен дистә еллар кирәк булачак, билгеле. Без, татар халкы, моңа һәрвакыт әзер булыйк. Эшебез, уебыз, гамәлебез белән шушы олуг максатларга хезмәт итик. Бу — безгә генә түгел, башка милләтләр кавеменә дә файдага булачак.

Белдерү

Федерация Советы Рәисе В.Шумейко-ның Грузиядә әйткән фикерләре уңаеннан

Билгеле булганча, Федерация Советы Рәисе В.Шумейко Грузиядә булуы вакытында Абхазия Президенты Владислав Ардзинба адресына әдәпсез белдерү белән чыкты. Шул уңайдан, 20 июльдә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Мәскәүдә Федерация Советы утырышында белдерү белән чыгыш ясады һәм аны Советның күп кенә депутатлары яклады. Түбәндә әлеге белдерүнең тексты басыла.

Россия һәм төрле халыкара оешмалар, барыннан да бигрәк БМО һәм ОБСЕ Грузия—Абхазия низагын хәл итү юлларын табарга инде ничә еллар омтылалар. Чечен Ичкериясе, Грузия һәм Абхазия чикләре буендагы хәл этник, территориаль һәм дәүләтара мөнфәгатьләрнең үзара четерекле бәйләнеше аркасында аеруча куркыныч, һәм ул сәяси лидерлардан халык алдында ясаган чыгышларында аеруча әдәплелек, һәрьяктан уйлап сөйләүне таләп итә. Федерация Советы Рәисе В.Шумейконың Владислав Ардзинба адресына мыскыллы белдерүен һәм аның аша абхаз халкына ихтирамсыз мөнәсәбәтен провокацион адым дип бәяләргә кирәк, чөнки ул нәкъ менә Грузия—Абхазия һәм Чечен Ичкериясе низагларын җайга салу юллары табыла башлаган вакытта яңгырады. Кешене «күп кешеләрне үтерү»дә бары тик суд кына гаепли һәм аны җинаятьче дип атый ала. В.Шумейконың белдерүе тагын шуның өчен дә урынсыз, ул Кавказга Россия Федерациясе Президенты яклавы астында Кавказдагы низагларны җайга салу буенча Сочида конференция үткәрү тәкъдиме белән барган иде.

В.Шумейко бит рәсми кеше. Аның белдерүе Россия—Грузия мөнәсәбәтләрен катлауландыра. Мондый белдерү, әлеге низагта тынычлык урнаштыручы як буларак, Россиянең абруена күләгә төшерә, Кавказдагы бөтен хәлгә зыян китерә. Без В.Шумейконың тулаем Федерация Советының фикерен чагылдырмый торган һәм Россия мәнфәгатьләренә туры килми торган белдерүенә кушылмыйбыз.

Сөенә беләбез икән...

Күптән көтелгән «Мәдәни җомга» атналык газетасының 1 нче тарихи саны чыгу уңаеннан җөмһүриятебез җитәкчелеге вәкилләреннән, аерым оешмалардан, әдәбият һәм сәнгать әһелләреннән, укучыларыбыздан күп кенә котлаулар алынды. Яңа басманың төп химаячеләре — Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары җитәкчеләре Ислам Әхмәтҗанов белән Марсель Таишев хезмәткәрләребезне, иртүк редакциягә килеп, кайнар тәбрикләделәр. Шулай ук безгә «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Известия Татарстана» газеталары, «Казан утлары», «Салават күпере» журналлары, башка матбугат басмалары, «Мәгариф» милли нәшрияты, «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе, Татарстан китап нәшрияты, аерым шәхесләр — халык язучысы Гариф Ахунов, халык шагыйре Илдар Юзеев, Гөлшат Зәйнашева, Рабит Батулла һ.б. күренекле иҗатчылар, Татарстанның халык депутаты Фәндәс Сафиуллин, күп санлы журналистлар, газета укучылар ихлас сөенүләрен белдерделәр. Бүгенге катлаулы чорда туган махсус мәдәни газетаның күңелләрегезгә хуш килүе, аның озын-озак сәфәргә чыгуына хәерхаһ булуыгыз иңнәребезгә канатлар үстерә, кадерле дуслар! Изгелек теләвегез өчен рәхмәтнең иң зурысы сезгә. Ышанычыгызны акларга тырышырбыз. Бергә булыйк!

«Мәдәни җомга» газетасы редакциясе.

«Ватаным Татарстан»:

«Мәдәни җомга» — сөбханалла!

Мең еллык әдәби мирасы булган халыкка әдәби-мәдәни газета кирәкме, дигән сорау, ниһаять, әндәү билгесенә алышынды. Кирәк! Вак инешләрнең агып төшәр диңгезе, бихисап йолдызларның бер бөтен күк гөмбәзе булган кебек, күп санлы каләм, пумала әһлиясенең дә түбәсе, бу очракта үз матбагасы булырга тиеш иде. Һәм ул бар, җөмәгать, бар!

Мөхтәрәм Президентыбыз андый газетаны гамәлгә кую хакындагы Указга кул куйганнан һәм «күп гасырлык мәдәниятебез күгендә тагын бер йолдыз кабыну мөмкинчелеге туган икән, аны чыннан да йолдыз итү сездән тора», дип фатихасын биргәннән соң да күңелләрдә шик-шөбһә яши иде. Бик зәвыклы, зыялы, тирән фикерле булса гына алдырып китә алыр андый махсус газета, дигән уйда идек.

21 нче июль иртәсе бүләк иткән 24 битле өр-яңа газетаны кулга алгач, күңел түрендә бары бер өн ярылды: «Сөбханалла!» Беренче коймак төрле була, дигән мәкаль бу юлы яңгыраш тапмады. Яңа газетаның әле ныклап тупланып та өлгермәгән коллективы авторлар даирәсен туплый һәм булачак укучысына үзенең мәслегән ирештерә алган.

Иркен мәйдан иркен шул. Бирәдә, ихтимал, һәркем үзе яраткан почмакка сыена алыр. Шигърият битенә әләгү өчен дә чират көтәсе булмастыр. Бер санда ике сәхифә — әйбәт инде ул. Язучы сүзе өчен дә мәйдан киң. Ниһаять, артист голәмасы да законлы урынга тиенгән кебек. «Мәдәни җомга»ны бер актарып чыгу да шактый гомерне алды. Һич ахырсы битенә җитә алмыйм. Әле бер сәхифәне туктап укыйсы килә, әле икенчесен. «Башның таҗы гыйлемдер» — шөп куйганнар башны. Яле, укып карыйм әле, эчтәлеге дә шөпмә икән? «Нишләвегез бу, егетләр?» Яле, яле. Кояш Тимбикова — затлы каләм, үткен фикер иясе, әмма газеталарга сирәк яза. Бу юлы каләм алдырган сәбәп ни икән? Әнә шулай туктальшлар белән 24 нче биткә җиткәндә мин шактый мәгълүмат җыйган, сөенгән, көенгән, хисләнгән, газетаның мөхәррире Зиннур Мансуровның «куенында таш булса, аны яңа туган газетаның нигезенә салу хәерлерәк», — дигән фикере белән тәмам килешкән укучы идем инде.

Газетаның зәвыклы бизәлеше бик сөендерде. Беренче санның эшләнешендә үк бернинди өйрәнчеклек тамгасы сизелми. Киресенчә, күңелдә соклану һәм... үзебезнең «Ватаным Татарстан» газетасы өчен дә горурлану. Ни дисәң дә, дистә еллар чыгып килгән «Әллүки» сәхифәсе бүген мәдәни газета башлау өчен алшартларны әзерли, авторлар даирәсен үз тирәсендә туплап, бер юнәлештә фикерләтеп тота алды, халыкны зыялылар тормышы, иҗаты, татар тарихы, дин дөньясы белән таныштырып торды.

Озын гомер сиңа, «Мәдәни җомга!»

Асия ЮНЫСОВА.

Язучы, драматург Рабит БАТУЛЛА:

„Җомга"-ул саф хыялны да, әдәбиятны да, мәдәниятны да, фәлсәфәне дә, ял-истирахәт вакытын да үз эченә алган. Язучылар, әдипләр өчен ачылган бу яңа мәйдан буш булмас, аңа тамашачы да, әдәбият сөючеләр дә тугырым торыр булыр, иншаллаһ; мәйданга каһарман артыннан каһарман пәйда булсын, корыч арты бәрәзе дәвам итсен! Әмин!

Р. Батулла 19.06.95

Гомәр САТТАР-МУЛИЛЛЕ

(Гомәр САТТАРОВ, Казан дәүләт университеты профессоры, татар теле кафедрасы мөдире)

Куәт бир туган телгә

Мәдәни дә җомга син,
Әдәби дә җомга син,
Сәнгати дә җомга син,
Синдер вә фәнни җомга;
Бергә туплап татарны,
Милләтне әйдә алга,
Халкымны әйдә таңга;
Ак юл, «Мәдәни җомга»,
Хак юл, «Мәдәни җомга»!

Җомга — җыелу коне,
Изге көн мөселманга,
Куәт бир туган телгә,
Иминлек — туган илгә;
Эшең күмелсен данга,
Шатлык китер һәр җанга!

Рухи кояш-ай булып
Язсын сиңа балкырга;
Балкы, «Мәдәни җомга»,
Яшә, «Мәдәни җомга»,
Бул татарның йолдызы,
Үз итсен егет-кызы;
Алып чык туры юлга,
Тотып татар кулыннан,
Илт азатлык юлыннан.

Бул син халык шигаре —
Алтын җептән чигәрә;
Рухи юлъязмабыз бул,
Чын милли басмабыз бул,
Алып бар алгарышка,
Заманчыл яңарышка!

Яшьнә, «Мәдәни җомга»,
Тәрәз уй һәрбер җанга,
Аң-акыл вә вөҗданга,
Һәм китер син иманга
Безнең барыбызны да.

21 июль 1995 ел.

ҖИДЕГӘН ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР
5 6 7 1 2 3 4

Җиде кат тир түккәннән соң... Голландиягә

Җәй ял вакыты гына түгел, гастрольләр чоры да ул. Хәер, элек шулай иде. Каһәр суккан базар бу өлкәдә дә эшләрне бутап ташлады. Элгәре, җәй җиттеме, авыл клублары, мәдәният йортлары концерт-спектакльдән шау килеп торыр иде. Ә хәзер... Ә хәзер исә артистлар гастрольләр урынына бакчаларына китәләр — ял итәргә. Бүгенге көндә камаллылар да, кačаловлылар да, бакчада булмаса, пляжда арка кыздыра. Татар дәүләт академия опера һәм балет театры труппасы артистлары гына, җиде кат тиргә батып, репетицияләр үткәрә. Алар көзен, Казанда театр сезоны ачылгач, тагын Голландиягә китәләр икән. Театрның исемен Татарстан-Голландия уртак опера һәм балет театры дип үзгәртергә вакыт җитмәдеме икән инде?!

Киндерләрдә татар фаҗигасе чагыла

Мәскәүдәге Украина илчелегендә Кырым татар рәссамнары — Зөләйха Бакирова, Ихмәт Шаһзадә һәм Нурия Якупова әсәрләреннән тупланган күргәзмә ачылды. Әлеге әсәрләрдә Кырым татарлары фаҗигасе, кан кардәшләребезнең тарихы сурәтләнгән.

Эш хакы өчен генә түгел

Мондый кыен заманда, эш хакы бирергә генә түгел, мәдәниятне үстерү өчен дә акча табыла икән. Тырышсаң, әлбәттә. Әнә, Октябрь районының Заречный авылында яңа мәдәният йорты ачканнар. Гомумән, бу районда мәдәният өчен акча җәлләмиләр. Әле күптән түгел генә Норлатта балалар музыка мәктәбе төзи башлаганнар.

«Йолдыз»лардан күзләр камаша

Менә инде ике атна буена Башкортстан җирендә ике тугандаш халык яшьләренең «Җыен»ы бара. «Җидегән йолдыз» акционерлык җәмгыяте ярдәме белән оештырылган бу тамашаларда сәхнә «йолдыз»ларыннан күзләр камаша — Фәрит Бикбулатов, Венер Мостафин, Идрис Газиев һ.б. Яшьләр бәйрәмендә Татарстаннан да җырчылар катнаша.

Нәбилне карарга килделәр

Оренбургта рәссам Нәбил Илимөхәммәтовның шәхси күргәзмәсе булып үтте. Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы булган Нәбил әфәнде — рәссам гына түгел, сынчы да. Графика жанрында да иҗат итә ул. Шәһәрдәге зур күргәзмә залларының берсендә тупланган әсәрләрне меңәрләгән тамашачы карады. Биредә, шулай ук, Оренбургта герой-шагыйрь Муса Җәлилгә куелачак һәйкәлнең эскиз-схемасы да тәкъдим ителгән иде.

«Җомга» туды Уралда

«Мәдәни җомга» газетасының беренче саны дөньяга килү алдыннан җиһанда тагын бер «Җомга» туды. Әлбәттә, бу мөстәкыйль газета түгел, ә «Магнитогорский рабочий»га айга бер тапкыр чыга торган кушымта гына. Шулай да бу хәл игътибарны җәлеп итәрлек вакыйга дип каралырга тиештер, чөнки Магнитогорскида татарларга матбугат битләренә чыгу җиңел бирелми. Сәбәбен аңлатып тору кирәкмидер.

Беренче сәхифәдә (ә ул урысча чыккан, чөнки татарча укый алучылар аз) Ислам дине турында язмалар, Хәдисләрдән өзекләр урын алган. Мөселман дине белән урысның бөек язучысы Лев Толстой да кызыксынган . «Җомга» шул хакта яза. Толстой хәтта «Изречения Магомета, не вошедшие в Коран» дигән китапчык та чыгарган. Әлеге басма үз вакытында оч тапкыр нәшер ителә.

Эш һәм төш

Мәскәүдәге Петр капкалары янында Владимир Высоцкийга һәйкәл ачылды. Бу инде атаклы сәнгать әһеленең Россия башкаласында куелган сыннарының икенчесе бугай. Әүвәлгесе Таганкадагы театр ишек алдында тора.

Күпсенмибез дә, көнләшмибез дә, әмма әлеге яңалык ирексездән уйга калдыра. Ничә еллар сөйләшсәк тә, Казанда мәшһүр моң иясе Салих Сәйдәшевның һәйкәлен әлегәчә күрә алмыйбыз. Ни хикмәттер, милли-милли миллионер егетләребез дә саллы маяларын салырга ашыкмыйлар. Югыйсә Сәйдәшебез тереклек булган әллә нинди ерак планеталарда татарның асылын бер үзе ачып бирә алырлык кабатланмас шәхес үзе.

Шулай инде, шагыйрьгә ияреп, көрсенергә генә кала: «Руслар эш күрәләр, мөселманнар төш күрәләр...»

«Тере шәм»

Латвиянең Даугавпилс шәһәрендә яшәүче 56 яшьлек Равил Яһудин үз-үзен яндырды. Хакимиятнең аңа гаиләсе белән бергә яшәргә мөмкинлек бирмәвенә протест йөзеннән, ул үз йорты ишегалдында өстенә бензин сибә һәм...

Бала чагыннан бирле шушы шәһәрдә яшәп, моннан ике ел чамасы элек эшсез калгач, ул пропискадан төшеп, Татарстанга акча эшләргә китә. Быелның язында ул үз гаиләсе янына бары тик кунак булarak кына килә ала, башкасына хакимиятнең ризалыгы булмый. Латвиядә даими яшәү хокукы алырга тырышу уңай нәтиҗә бирми. Хәтта суд та аны якламый.

Империянең таркалуы сәясәттә, икътисадта гына түгел, аерым кеше язмышында да әнә нинди аяныч вакыйгалар китереп чыгара.

Хәбәрләрне
Наил ФӘЙЗЕТДИНОВ
туплады.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Фәнни-педагогик эшчәнлек өчен **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:

Гарипова Фирдәвес Гариф кызы — Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты профессоры;

Теншиев Әдһәм Рәхим улы — Мәскәү шәһәре Россия Фәннәр академиясе Тел белеме институтының торки һәм монгол телләре секторы мөдире.

ТСС!.. ИМТИХАН БАРА

Узган елгылары көчлерәк иде

Югары уку йортларында имтиханнар бара. Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә абитуриентлар гөрләгән чак. Без театр сәнгате факультетының татар бүлегендә имтихан алды өңгәмәләре вакытына туры килдек. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры, СССРның халык артисты М.Сәлимҗанов, театр директоры Ш.Закиров, артист И.Мөхәммәтгалиев, декан Ф.Исмәгыйлова, режиссер Ф.Бикчәнтәев һ.б.лар укырга теләүчеләр белән әңгәмә үткәрәләр.

— Артист, режиссер булырга хыялланучы абитуриентлар күпме, аларның әзерлеге ничек? — дигән сорау белән без Ф.Исмәгыйловага мөрәҗәгать иттек.

— Татар артистлары һәм режиссерлар әзерләү бүлегенә һәр ел 10-13 әр егет һәм кызны алабыз. Урыс бүлекләренә дә шул кадәр үк. 13 урынга 30 лап гариза керде. Режиссерлар әзерләү бүлегендә дә шундый нисбәт. Безгә килүчеләр арасында кызлар күбрәк. Ә безгә егетләр дә кирәк...

Әйтми булдыра алмыйм, абитуриентларыбызның гомуми әзерлеге түбән. Әдәбият һәм сәнгать буенча мәгълүматы булмаган кешенең югары уку йортына килүе аңлашылмый. Ә имтиханнарда (театр бүлегендә) яшьләрнең татар һәм урыс язучыларын, аларның әсәрләрен, драматургларны, артистларны, спектакльләрне белмәве төмам аптыратты. Күңелдә — бүгенге яшьләребез китап та укымыйлар булса кирәк, дигән фикер туды. Узган елгы абитуриентларыбыз ул яктан көчлерәк иде. Чит өлкәләрдән килүчеләр турында сөйләп тә торасы юк. Әле генә Оренбургтан килгән өч кызны тыңладык. Кызганыч, алар безне куандырмады. Шунысын гына әйтәм, студент итеп кабул ителгән яшьләребезгә дә уку дәверендә татарча чиста, дөрес, матур итеп сөйләшергә өйрәнү бурычы куела.

Бүгенге имтиханны уңышлы үткән абитуриентлар керү имтиханнарын дәвам итәчәкләр. Без аларга уңышлар телибез.

Салисә ГӘРӘЕВА.

● **Имтихан алу вакыты. Сулдан уңга: Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Ш.Закиров, баш режиссер М.Сәлимҗанов, артист И.Мөхәммәтгалиев һәм имтихан тотучы.**

ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

● Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев республика Дәүләт Советы җитәкчеләрен һәм даими комиссия рәисләрен кабул итте.

● Россиянең Стратегик анализ һәм фаразлау үзәге, Vox Populi җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү хезмәте төбәк җитәкчеләренең июль аендагы фьючерс рейтингын игълан итте; Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев исемлектә Лужков, Дудаев һәм Немцевтан соң, 4 нче урынны алып тора.

● Татарстан Россия галимнәре тарафыннан эшләнә торган ерак араларга очучы югары тизлектәге аз сыйдырышлы самолет проектын гамәлгә ашыруда катнашу мөмкинлеген тикшерергә әзер булуын белдерде.

● Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев Люксембург Бөек Герцоглыгы илчесе Жан Остарт белән очрашты.

● Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Премьер-министр урынбасары Владимир Швецовка Гадәттән тыш хәлләр буенча дәүләт комитеты рәисе вазифаларын йөкләү турындагы Указга кул куйды.

● Татарстаннан Россия Дәүләт Думасына сайланган депутат Габделвахит Баһаветдинов үзенең ПРЕС фракциясеннән чыгуын белдерде.

● Татарстан Премьер-министрының беренче урынбасары Фәрит Газизуллин җитәкчелегендә республика энергетика комиссиясенең утырышы булды.

● Татарстанга Россия ягулык-энергетика промышленность министрының беренче урынбасары Анатолий Фомин (сүз уңаеннан — якташыбыз, Югары Ослан егете) килде.

● Татар иҗтимагый үзәгенең Чаллы идарәсе Татарстан Республикасы гражданлыгы булдыру турында Татарстан халкына мөрәҗәгать белән чыкты.

● Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев Әлмәт шәһәрендә, Лениногорск һәм Бөгелмә районнарында булды.

● Татарстанның мөстәкыйльлек турында Декларация кабул итүенә биш ел тулу уңаеннан, «Суверенитет» комитеты 30 августта Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры каршындагы мәйданда митинг-концерт үткәрергә җыена.

Бездә Болдинолар бармы?

Кызыл Байрак авылы Иделнең уң як ярына — бакыр көүсәле биек наратлар үскән яшел әрымтылар, хәтфәдәй үлән белән капланган үрләр җәйрәп яткан бер урынга, табигатьнең иң гүзәл җиренә урнашкан. Бу төбәк турында күпләр ишетеп кенә белә, ә инде тирә-ягы «Татар Швейцариясе» дип аталган Кызыл Байрак авылының тарихы турында уйлаучылар бөтенләй аздыр. Искә алынган шагыйранә исемне бу төбәккә татарның танылган әдибе Галимҗан Ибраһимов биргән, диләр. Элекке ханнар яшәгән бу гүзәл җиргә язучы еш килә торган булган, ул биредә уйланырга, эшләргә, язарга яраткан.

Кызыл Байрак авылына мәгълүм шәхес Сәхипгәрәй Сәетгалиев һәм шул чордагы ТатҮБК рәисе Ганиевләрнең җиңел кулы белән 1924 елда нигез салынган. Гали Ганиев, ТатҮБКта эшләү дәверендә, Идел буендагы элекке алпавыт җирләренең буш ятуын яхшы белгән. 1917 елгы революциягә кадәр Иделнең уң як ярындагы җирләр италияле бер маркиз җирләре исәпләнгән. Алпавытның буш җирләрендә элек эш башкаручы булган Моратовның («Морат тавы» — шуннан) һәм Гребенщиковларның (хәзерге Гребени бистәсе) йорт-каралтылары гына торган. Якын-тирәдәге Шеланга, Теньки дигән берничә урыс авылы бер-берсеннән шактый ерак булган. Ә татар авыллары бөтенләй юк: Казанны Явыз Иван басып алганнан соң, татарларга шәһәр тирәсенә якын яшәү тыелган.

Югарыда телгә алынган Ганиев белән Сәетгалиев; шул еллардагы күренекле шәхесләр — дәүләт җитәкчеләре белән киңәшеп, ерактан, җиргә саран булган авыллардан татар гаиләләрен Иделнең уң як ярына күчереп утыртуны оештыралар. Нәкъ менә шушы елларда Берек, Кызыл Байрак, Нариман. Бакчасарай авыллары калкып чыга да инде.

Кызыл Байрак авылын оештыруда Гали Ганиевнең иң якын ярдәмчесе — танылган мәгърифәтче, нәшир, боек композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең җизнәсе һәм тәрбиячесе Шиһаб Әхмәров бик актив эшли. Бу вакытта Шиһаб Әхмәров үзара кредит бирү җәмгыяте идарәсе әгъзасы була. Авылга күченеп килүче татар гаиләләренә ул саллы гына матди ярдәм күрсәтә, мәктәп төзү өчен җәмгыять аркылы акча юллый. Аның чакыруы буенча, авылга күренекле укытучы Сонгать Биктимеров килә. Ерохин атлы оста бакчачы ярдәмендә мәктәп тирәли җимеш бакчасы утыртыла, кое казыла, авыл хуҗалыгы эшләре өчен трактор сатып алына. Бераздан мәктәп янына клуб та салына, әмма ул, ут чыгып, янып бетә. Шулай итеп, җирсезлектән интеккән, ерак төбәкләрдән җыелган игенче гаиләләре бергәләп күмәк тормыш башлап җибәрәләр.

Социаль үзгәрешләр белән беррәттән, авыл кешеләренең рухи дөньясы да байый бара. Моның үзенә күрә сәбәпләре дә бар: Татарстанның күпчелек иҗат әһелләре, мәгариф һәм мәдәният эшлеклеләре җәйге айларын шушы авылда үткәрә башлыйлар. Шиһаб Әхмәров Кызыл Байракка Чүпрәле районында яшәгән туганы Хәйрулла Әхмәровны күчереп утырта. Хәйрулла бик тә кешелекле, эшчән кеше була һәм авыл активистларының берсенә әверелә. Аның йорты гөжләп тора: кунакчыл гаиләгә, гадәттә, җәйге Г.Ибраһимов кайта, аның янына бик күп башка язучылар, җәмәгать эшлеклеләре, дәүләт җитәкчеләре һ.б.лар килә. Соңыннан, бу йортка терәп, тагы бер йорт салына. Анда Шиһаб Әхмәров гаиләсе яши. Ел саен аларга Салих Сәйдәшев кайта. Шиһаб Әхмәров — аның җизнәсе, Салихның апасы Әминә — анда кияүдә. Бу йортка артистлар, музыкантлар, язучылар гаиләләре белән кунакка киләләр. Шулай итеп, җәйге айларда Кызыл Байрак татар зыялыларының үзәгенә әверелеп кала... Кызыл Байракта Ш.Камал (Гарәфи Хәсәнов йортында), Г.Кутуй (Сафиннарда), М.Корбангалиев (З.Галиәскәревләрдә), Ф.Туишев (Я.Борһанов йортында), Х.Ямашева — Хәсәен Ямашев хатыны (М.Галиуллиннарда), һ.Такташ һ.б.лар озак-озак кунак булып, ял итеп китәләр. Әлбәттә, иҗат әһелләре үзара гына түгел, авыл кешеләре белән дә якыннан аралашып яшиләр. Бу мөнәсәбәтләр еш кына кайбер авыл кешеләре язмышына да уңай тәэсир итә.

Шундый хатирәләрнең берсен беренче колхоз бригадиры Г.Сафинның кызы Шәмседоха сөйли: «Мин җиде сыйныфны тәмамлагач, врач булырга карар иттем. Казанга медицина училищесына җыенам. Ул җәйдә бездә Г.Кутуйлар гаиләсе яшәгән иде. Гаделша абый минем кая барырга теләвемне белгәч, «Юк, сиңа врач булырга ярамый, сиңа укытучы булырга кирәк», диде. Мин үзем дә шулай уйлыйм, дидем, тик Казанда педагогия училищесы булмавын әйттем. Ул минем кәгазьләремне Спас педучилищесына үзе илтеп бирде. Шулай итеп, мин укытучы булып киттем. Һәм гомерем буе Г.Кутуйга рәхмәтлемен...

И, ул чактагы тормышның кызыклыгы! Өй саен кунак, авыл тормышына алар актив катнаша, дус-тату булып, гөрләшеп яшибез. Урманда берничә урында дәстәрхан җәелгән, самоварлар кайнап тора. Кунаклар да, авыл кешеләре дә бергә утырып, көлешә-көлешә, күмәкләшеп чәй эчәләр. Шунда ук җанлы әңгәмә башлана, уен-көлке, музыка-җыр. Кичләрен урман аланына яше-карты уенга чыга. Үзәктә — Салих ага Сәйдәшев. Бөтенесе аңа тартыла, мәзәкләр сөйләү, ихлас көлешүләр... Ул Кызыл Байрактан ял итеп, илһамланып Казанга кайта, иҗат итә, бу иҗат театрларны, спектакльләрне җанландыра, чишмә суы кебек, аның иҗатын сугара...»

Әхлак нигезләрен яшьләр күңеленә сеңдергән өчен иң беренче җылы сүз укытучы Сонгать Биктимеров турында булырга тиеш. Авыл халкы арасында аның абруе зур иде. Ул Кызыл Байракта 1926-1929 елларда, аннан соң 1942-1952 елларда эшләде, берничә буын авыл кешеләрен укытты, аларның рухи җитәкчесе, тәрбиячесе булды. Авылда Кайбыч ягыннан килгән укытучылар — Гәрәй Саттаров һәм Ибраһим Тимергазиевларны да яратып искә алалар. Алар Сонгать абзый белән бергә Аратказый мәдрәсәсендә укыганнар. Дөрес, совет власте дингә каныккан елларда мәчетләр бетерелде, ләкин бу кешеләр үз иманнарын нык сакладылар һәм авыл өчен алар сүзе — абруйлы сүз иде. Кызганыч, 30-40 нчы елларда илдә барган фаҗигале хәлләр Кызыл Байрак өчен дә эзсез узмады. Авылга кайтып ял итеп йөргән кешеләрнең бөтенесе диярлек, милләтчелектә һәм башка уйдырма җинаятьләрдә гаепләнеп, Сталин репрессиясе корбаннары булдылар. Гали Ганиев та, Шиһаб Әхмәров та шул корбаннар арасында...

Еллар үтә торды. Куркыныч давыл булып, ил өстенә сугыш килде. Авылның асыл ирләре сугышка алынды, сугыш һәм тыл йөгенең бөтен авырлыгы, фаҗигасе картлар, хатын-кызлар, балалар җилкәсенә төште. Авыл бушап, сүнеп калды. Шулай да халык элекке традицияләрне югалтмаска тырышты. Эштән арып кайткан яшьләр элек әтиләре, абыйлары, татарның олы шәхесләре ял иткән урман аланына чыгып, еш кына күңел ачу оештырды. Бу үткән бәхетле коннәрнең соңгы чаткысы булды шикелле...

Сугыштан бик аз кеше исән кайтты. Муса бабайның ике улы — Хәсән һәм Мөбарәкша да сугышта корбан булды, беренче колхоз рәисе Г.Исмәгыйлевнең бердәнбер улы да кайтмады. Муса бабай үзен Г.Ибраһимовның ярдәмчесе дип әйтергә ярата иде, чөнки Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәре күпмедер дәрәҗәдә ул сөйләгән гыйбрәтле вакыйгага нигезләнгән. Әсәрдә Кызыл Байракның матур табигате дә сурәтләнгән.

Сугыштан соңгы елларда — 60 нчы елларга кадәр — Кызыл Байрак тормышында яңа үзгәрешләр барды. Авыр еллар иде. Хәерчелек, илдә барган сәясәт кешеләрне бер-берсеннән аера, ераклаштыра торды. Авыл халкы үз бәрәңге бакчасына гына өметләнеп яшәде. Әлбәттә, бу елларда да авылга ял итүчеләр килә торды, биредә аларны тәрбия итү кәсебе җуелмады, әмма бу мөшкәтьләр инде игенче хуҗалыгына икътисади өстәмә бирә алмый иде. Авыл кешеләре җәй көне йортларын кунакларга тапшырып, үзләре сарай, келәт ише хуҗалык каралтыларына күчеп яшәде. Ял итүчеләр дә «сыйфат ягыннан» инде икенче төрле иде... Элекке зыялы затлар урынына кибетчеләр, сәүдә хезмәткәрләре, кайчагында галимнәр, профессорлар килә башлады. Биредә профессор Ясницкий, Малкин, Камай, Норден, Лаптев, Әминев, Застело, Усманов, Әхмәров һәм башкалар озаклап ял итте. Әмма халык белән элеккечә самими аралашулар, ихлас мөнәсәбәтләрнең эзе дә калмады...

Бай тарихлы, гүзәл табигатьле Кызыл Байрак авылы бүген ни хәлдә соң? Бу авылның һәр өенә истәлек тактасы куярга булыр иде, чөнки биргә йөзләгән күренекле шәхесләр килеп киткән. Шул ук үлемсез композиторыбыз Салих Сәйдәшев яшәгән йортка да... Бу йортка ул соңгы тапкыр 1954 елда — Мәскәүгә китәр алдыннан ялга кайткан иде. Һәм шуннан соң Кызыл Байрак авылы Сәйдәшсез калды...

Соңгы елларда авыл катлаулы тормыш кичерә. Авылга күмәк бакчалар бердәмлекләре һөҗүм итә. Яшьләр шәһәргә китә тора. Йортларның тәрәзәләре кадакланган. Гүзәл үрләр, ерымтылар, яшел үзәннәр чүплеккә әйләндерелгән. Йөз яшәр наратлар — бөек кунакларыбызның шаһитлары — дача төзүчеләр тарафыннан аяусыз киселә бара.

Татарстанның бу әкияти төбәген коткару өчен нишләргә соң?! Кызыл Байрак проблемасы — юкка чыгарылган меңләгән авыллар проблемасы ул. Әмма Кызыл Байрак — гади авыл түгел, ул — Татарстан тарихының онытылмас, газиз бер тарихи өлеше! Шуңа күрә республика җитәкчеләре бу авыл проблемасына йөзләре белән борылсыннар иде, авыл тирәсе табигать тыюлыгы итеп сакка алынсын иде!

Русиянең дә, Переделкино кебек, рәссам Репин яшәгән урыннары — дәүләт карамагында тора торган урыннар бар бит. Нигә соң әле шундый оҗмах шикелле төбәкләрне Татарстан дәүләте үз канаты астына алмаска тиеш?! Бәлки авылга, элекке чорлардагыча, староста сайларгадыр һәм авыл турында кайгырту мәсьәләләрен авылның үзенә, староста җаваплылыгына тапшырыргадыр?!

1990 елда Кызыл Байракта С.Сәйдәшев мемориалын эшләү турында карар кабул ителгән иде. Ләкин аны чынга ашыру өчен зур тырышлык кирәк. Мемориал ачылса, Кызыл Байрак авылы С.Сәйдәшев музее оештырган «Сәйдәш эзләре буйлап» дигән экскурсия маршрутына кертелер иде. Менә шунда инде Татарстан табигатенең матурлыгын, байлыгын үзебезнең халыкка гына түгел, чит ил кунакларына да зур горурлык белән күрсәтеп булыр иде.

Бер-ике атна элек кенә Кызыл Байрак уртасында калкып чыгачак мәчеткә нигез салынды. Мәчет тирәсе дә С.Сәйдәшев мемориалы зонасына кертелә, чөнки боек композиторыбыз җәй коннәрендә яшәгән өй дә мәчеткә якын гына.

Бу олы эшләрне башкаруда «Оргсинтез» акционерлар җәмгыяте (директоры Н.Х.Йосыпов) матди ярдәм күрсәтергә вәгъдә итә. Хыялларыбыз чынга аша күрсен!

Дилбәр САИНОВА,
Салих Сәйдәшев музееның олкән фәнни хезмәткәре.

Гурий ТАВЛИН

Тәгәрәпме тәгәрибез түбәнгә...

Памфлет

Бар иде безнең тормыш-көнкүрештә, АКШны күпкә узып, гасырыбызның 80 нче елларында ук инде коммунизмда яшәргә хыялланган заманнар. Шул татлы омтылыш-теләкләр дәверендә тирән мәгънәле, зәһәр кинаяле мәзәк туган иде: юк, безгә АКШны узып алга чыгарга ярамый, без ыштансыз бит, шәрә артыбызны американлыларга ялтыратып, алда чабу уңайсыз булыр, янәсе... Үз сөйләве буенча, бала чагында дуңгыз көткән, үсмер елларында Донбасстагы ниндидер мифик бер шахтада, җан тирләрен түгеп, чит ил капиталистларына күмер чапкан үтә үзсүзле дәүләт башлыгыбызның аяк өсте күргән төшен өнгә әйләндерергә чамалап саташуы иртәрәк булды. Хәер, авылларында ата казлар кыйнап, шалкан урлап үскән классик шагыйребез, «Хыял безнең өчен чит бер нәрсә, һәрбер теләк — якын киләчәк!» дигән. Әмма хөрмәтле Никита Сергеевич Хрущев ымсындырган максатка — АКШны узып китүгә дә, коммунизмда яшәүгә дә без ирешә алмадык. Ул вакытларда илдә ярыйсы ук каты тәртип, җаваплылык хисе булды, халык та тормышка шактый аек күз белән карый иде. Бәлки, шулар да саташуның чынбарлыкка әйләнүенә комачаулаганнардыр. Фәкыйрь, ыштансыз илдә нибары егерме ел эчендә коммунизм төзү хыялының акылы камил кешенең башына килүе дә икеле.

Ә менә бүген без кайбер тармакларда: фәхишәлектә, наркоманлыкта һәм Рәсәебездәге миллионерлар саны буенча АКШны күпкә артта калдырдык. Рәсәй фәхишәләре хәзер үзебездә генә түгел, Җир шарының кешеләр яши торган барлык кыйтгаларында да бар. Наркоманлыкка да ныклы киртәләр куелмый. Әйтерсең, балаларыбыз туганда ук авызларында тәмәке пыскытып туалар. Бераз үсә төшкәч, аларга киндер, мәк үстерү чүп тә тормый. Миллионерларны да көндез чыра яндырып эзлисе түгел, ачуым килмәгәе, Рәсәйдәге һәр биш кешенең берсе — агач акчалы миллионер. Эчкечеләр, анык торак урыннары билгесез кешеләр (бомжлар), почмак саен кулларын сузып хәер эстәп утыручы саилчеләр, шакшы сүзләр тезеп, катлы-катлы итеп сүгенүдән хозурлык табучылар, чәчләрне үрә торгызырлык котырынган бәяләр, өметсез тормыш, гаилә таркалулар, бурлык-караклыклар, хулиганлык, алдашулар һәм исәпсез-хисапсыз бүтән пычраклык-чатаклыклар буенча да күкрәк кагып мактана алабыз, без Гиннесс китабында урын алырлык биеклек яуладык инде.

Торгынлык елларында, ирешелгәннәр белән канәгатьләнү совет халкына ят күренеш, диләр иде. Язмыш шуклыгы нәтиҗәсендә, рәсәйлеләр саналучы без дә, аз гына да шикләнмәскә мөмкин, ирешкәннәребез белән чикләнмәбез, түбәнгә тәгәрәвебезне алда да дәвам итәрбез, ахры. Моның өчен бездә мөмкинлекләр дә, шартлар да җитәрлек. Һәркөн телевизордан үбеш-кочыш, секс, күңел тетрәткеч садистлыклар, рәхим-шәфкатьнең эзе дә калмаган кыйнаш-тәпәләшләр, иң оятсыз уйнашлык итүләр, атышлар, җимерешләр, үтерешләр карыйбыз, аты-юлы белән катлы-катлы мәсхәрәле сүгенүләр ишетәбез, кулларына озын шәмнәр, ялтыравыклы хачлар тоткан попларның улауларын, доң-доң чиркәү чаңнары кагуны тыңлыйбыз. Газеталарда атнаның биш көнендә сәламәт бәндәнең төшенә дә кермәслек үтерешләр, кеше ашаучылар, талаулар, хезмәт белән төзәтү урыннарындагы ир-атлар, шулай ук хатын-кызлар арасында кылына торган җенси бозыклыклар, үзара никахлашучы «зәңгәр» ирләр, бер-берләрен ирләр кулына керми генә канәгатьләндергән Лесбос утравы хатыннарының бүгенге дәвамчылары, сабыйларны көчләүләр, әтиләренең — кызлары, әниләренең уллары белән ирле-хатынлы, хатынлы-ирле яшәүләре турында укыйбыз. Алар безгә сенсация төсендә тәкъдим ителәләр. Тышлыкларына зур зәвык белән әдәпсез, кыланчык позаларда анадан тума шәрә хатыннар төшерелгән китаплар ташкындай агыла. Күбесенең эчтәлекләре косарлык. Алар тулаем секс, төрле маньяклар, мафиячеләр, монстрлар, вурдалаклар, өрәкләр һ.б. турында гына.

Илдә «яңа кешеләр» тәрбияләү бара. Без, татарлар, өр-яңа «яшәү рәвеше»нә ияреп, һәр адымыбызда маймылланганнан-маймылланабыз. Милли традицияләребез хурлана. Эстрада артистларыбызның кайберләре инде оят җирләрен аннан-моннан каплаштырып кына сәхнәгә чыга башласалар да гаҗәп булмас. Андыйлар түшләреннән кендекләренәчә ачык, итәкләре билләреннән чак кына түбән тәти күлмәкләр кия башладылар бит инде.

Җөмһүриятебездә өлкәннәргә, ата-аналарыбызга хөрмәт түкәнгәннән-түкәнә бара. Узган тарихыбыз белән без бик аз кызыксынабыз. Татар китапларын уку, алар белән кызыксыну кимегәннән-кими. Милли басмаларыбыз бармак белән санарлык кына калган китап кибетләрендә, хәтта бер кап шырпы хакы торганнары да (мәсәлән, Гаяз Исхакыйның «Зиндан»ы), сатылмыйча тузан җыеп яталар.

Зур бүксәле буржуй Мистер Твистер яшәгән АКШны, алда сөйләнгәнчә, без күп кенә тармакларда куып җитеп, еракта калдырдык инде. Хәзер алар безне куып җитсеннәр. Тик американлыларда андый теләк туармы икән?!

Шулай, җәмәгать, безгә ирешкәннәребезне югалтудан курыкмаска, үзебезне яңадан таш гасырына илтә торган такыр юлдан тайпылмаска кирәк!

САЛИХ БАТТАЛНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Локман БАДЫЙКШАН

Сугышта ул лачындай очучы иде, Җирдә дә ул аякта нык торды...

Аңа быелның август аенда 90 яшь тулган булыр иде. Хәер, «тулган булыр иде», дип әйтү дә бик үк килешеп бетмәс кебек. Чын иҗатта, чын олы шәхесләр иҗатында шулай бит ул: гомерләр киселсә дә, иҗат гомере өзелми, дәвам итә, халык күңелендә саклана. Гасыр башында туып, заманыбызның олы бер шәхесе булып өверелгән, катлаулы язмыш юлы узган өлкән әдибебез Салих Баттал турындагы истәлекләр исә аны күз алдыбызда тагын бер кат яңарту, искә төшерү, хәтеребезне барлау ул.

Быел 12 мартта бик кызганыч рәвештә вафат булды өлкән шагыйребез Салих Баттал. Казанның Яңа бистә зиратына җирләдек без аны. Туксанны тутырырга дүрт кенә ай калган иде. Сугыш елларында хәвефле күктә очып та янмаган бөркет иде бит ул.

Мин Салих Баттал белән алтмыш елга якын аралашып яшәдем. Икебез дә Тын океанда хәрби хезмәттә булдык. Аерма шунда гына: ул — авиациядә, мин — хәрби флотта идем. Ерак Көнчыгышта ничек яшәвебез, япон самурайларының «кылычларын сындыру»га катнашуларыбызны язып тормыйм, сугыштан соң аралашып яшәү елларындагы кайбер көннәрне искә төшереп, күз алдына китерәсем килә.

1962 ел иде. 19 августта Салих Баттал хәбәр бирде. «Килеп чык», — диде. Янына юл тоттым. Гагарин урамыннан борылып кереп киткән урамдагы биш катлы йортта иде аның фатиры. Ишеген Салих Баттал үзе ачты. Артык зур булмаган бүлмә икенче катта гына. Мин аңа һәрчакны «абый» дип дәшәм, ул миннән егерме яшьләргә өлкәнрәк. Җәмәгате — уртадан калкурак, карачкылрак йөзле, сылу гына ханым. Аның опера театрында җырчы булып эшләгәнен ишетеп белә идем. Ул да ачык йөз белән каршылады. Өс-башымны салып, түргә уздым. Стенада — матур гына рамда — Салих Батталның Муса Җәлил белән яшь чакларында бергә төшкән зур гына фоторәсеме. Бу фотоны әле беренче мәртәбә күрүем иде.

Шул фотога җентекләп каравымны сизгәч, Салих абый әйтте:

— Кечерәйтелгәне дә бар, сиңа да бүләк итми булмас, — диде. Әңгәмә барышында телевизорда минем чыгышымны күргәнлеген дә әйтеп үтте. Күптән түгел генә «Ялкын» журналында «Җилкәннәр» дип аталган хикәям басылып чыккан иде. Шагыйрьгә ул ошаган, күңелем күтәрелеп китте. Ә аның «Совет әдәбияты» журналында «Сигезенчесе кем?» исемле повесте чыкты ул елны. Фикеремне әйттем. Шагыйрьнең күңеленә хуш килде. Аннары үткән атнада Васильеводагы дачасында булганда караватына калын җеп белән асылынып торган агач кашыкка исем китүем хәтергә төште. Чәй янында гына булса да, шуның серен белергә теләп, кызыксынып сорадым.

— Кайчакны аркам кычытып китә, Идел буе бит, черкиләр күп, аркама куналар, шуларны әлегә кашык белән дөмектерәм, савыт-саба бүлмәсенә чыгып эзләп торасы юк, — дип җавап бирде ул. Җор телле иде шул Салих абый.

Сүзебез күбрәк әдәбият турында барды. Аның кемнәр кулында икәнлегенә басым ясап:

— Кемнәргәдер минем әдәбиятка килүем ошап бетми, — дидем.

— Яз, Локман, язуыңны гына бел, заманалар һаман болай гына бармас, ул кешеләр дә урыннарында мәңге утырмаслар, — диде әдип.

Усал телле иде шул Салих абый.

Татарстан язучылары съездына бардым. Кайсысы икәнлеген хәтерләмим инде. Ләкин вакыйга буларак, күңелгә бик нык сеңеп калган ул съезд. Кайтышлый Салих Батталга киттем. Чөнки ул съездга килмәгән иде. Эчем бик тә пошты. Бәлки авырып киткәндер. Ачык күңел белән каршылады ул мине. Аның съездга бармавының сәбәбе бик гади икән.

— Анда обком түрәләре булмый калмый, йә яңадан аларның күңелләренә ошамаган сүз әйтеп ташлармын дип курыктым, — диде ул.

Аннары:

— Әдәби мирасыбыз турында сүз булмадымы? — дип сорады.

— Булды, Әмирхан Еники бу хакта сүз кузгатты. Ләкин күтәреп алучылар күренмәде.

Каләмдәшемне бигрәк тә «Идегәй» эпосының бүгенге көнгә кадәр китап булып чыкмавы борчый икән.

— Яшьләргә әдәби журнал чыгару турында сүз кузгатучы булмадымы? — дип сорап куйды ул янә.

— Булды, Ибрай Гази бу хакта чыгыш ясады, — дидем.

1965 елның октябрь ае. Салих Батталның төпчек энесе Фуат фатирына эштән кайтышлый сугылырга булдым. Салих Батталның энесе дә бик тә укымышлы, тормышка гашыйк кеше. Ул миңа әле моңарчы бер дә күрмәгән китап сузды. Үзе дикъкать белән генә мине күзәтә. Китап, Ш.Әхмәдиев тарафыннан язылып, 1928 елда Ташкент шәһәрендә басылып чыккан икән. Галимҗан Ибраһимовка багышланган. Сирәк китаплар күп була иде Батталларда.

...Кайтырга чамалап кына торганда ишектә кыңгырау шалтырады. Хуҗа ишекне ачарга ашыкты. Ни күрәм: Салих Баттал җәмәгате Мәдинә ханым белән килеп керде. Шагыйрьнең күңеле күтәренке, елмая. Ул безгә «Казан утлары» журналының унынчы санын сузды.

Салих Батталның Муса Җәлил белән төшкән фотосурәте. 1928 ел. Фоторәсем Л.Бадыйкшан архивыннан алынды.

Битләрен ачам. Анда «Чирмешән буйларында» исемендәге шигъри романының беренче бүлекләре басылган. Кычкырып укыдым мин аны. Мин арыгач, автор журналны үз кулына алды, мин туктаган җирдән ахырына кадәр дәвам итеп, салмак кына укып бетерде.

(Ахыры 11 нче биттә).

Атнаның һәр җомгасында халкыбыз иманын яңарта. «Мәдәни җомга»га тәкъдим иткән беренче туплавым «Иман» шигыреннән башлансын. Мәчет манарасы булып иман күтәрелгән еллар. Рухи, әхлакый манараларны имансызлык какшаткан чор... Яңа газетаның фәлсәфи, гамәли эшчәнлеге күңелләргә терәк булсын, милләт язмышы хакына карашларны бердәм итсен иде. Мәгънәле озын гомер телим сиңа, «Мәдәни җомга».

Шәүкәт ГАЛИЕВ,
Татарстанның
халык шагыйре

Иман

Бер карасаң, бу дөньялар
Кызганыч, кызык кына;
Иман сүзе дә яшәде
Сүзлеккә посып кына.

Ахры, «имамнар калдыгы»
Булып күренгәндер ул,
Тере телдән заманында
Шуңа сөрелгәндер ул...

Җанны әрнетеп күп еллар
Вөҗданда иман сызлар —
Үрчеде буш йөрәклеләр,
Ишәйде имансызлар.

«Башын киссәң, тагы үсә...»,
— дип,
Өметләрен өзмәгән,
Тугры уллар тайпылмаган
Тарих салган эзләрдән.

Халкың өскә калкасына
Инанганнар үзләре.
Саф күңелләрдә сау калган
Халыкның рух үзәге.

Гасыр чирләрен җиңәрлек
Савыктыргыч им анда —
Туфаннар гүзәл гамендә —
Кешелекле иманда!

Шамаилдә яңа дога —
Җырлап торган «Туган тел»,
Яшәвебез, саулыгыбыз,
Иманыбыз булган тел.

Әйе, җирдә халыкларның
Саны — миллионнарда,
Әмма сыйфат рәвешләре,
Җаны — милли улларда.

Мин ышанам могҗизага:
Халык булдыра килә —
Үзен мәңге яшәртерлек
Дәвам тудыра килә.

Мин ышанам: гасырларда
Бар безгә дә урыннар —
Вәкаләтле илче булыр
Оныклар һәм туруннар!

Әйләнер дөнья-куласа,
Киләчәккә күчәр гел;
Иман булсын да уң булсын —
Иман булсын күчәре!

* * *

И туган телем, туган тел,
Сүзең алтын сүзле тел,
Син татар баласы, диеп
Сайрап торган изге тел!

Татарның бар — татар теле,
Урысның бар — рус теле:
Һәркайсының үз анасы,
Һәр ананың үз теле.

Русчалатып сөйләгәндә
Татарчалап кычкырма,
Рус сүзен дә татарчага
Шүрәледәй кыстырма...

Юкса, кайчакта кайсыбыз
Арттырып куя бигрәк —
Татарны татар аңларга
Булышчы-тылмач кирәк...

Без бит — Тукай оныклары,
«Туган тел» оныклары,
Оныкларның үз нәселен
Кирәк бит онытмавы!

Ана телем — анам булып
Мөлаем эндәшәсең.
Әнием дә, туган тел дә
Сау-сәламәт яшәсен!

Хәтер иясе

Миркасыйм Госмановка, «Каурый каләм эзеннән» китабы чыгу уңаеннан.

Татар барда — хәтәр бар, дип,
Кемнәрдер сүз тарата.
Татар барда — хәтер бар, дип
Әйтәм сиңа карата.

Хәтер барда — татар булыр,
Хәтер саклар улы син,
Гасырларны урап чыккан
Каурый каләм — кулы син.

Татар барда — хәстәр бар, дим,
Бу сүз бик кулай икән —
Әүвәл генәме, хәзер дә
Бөекләр була икән.

Бу гасырның аръягында,
Яшең йөзләрне үтеп,
Укырсың бу мәдхияне
Борынгы язма итеп!

Якташларга әйтер сүзем

И, Тау ягым, туган ягым,
Әрнегән, туңган ягым,
Гомерлеккә илһам булып
Күңелгә тулган ягым.
Нужа — мине, мин — нужаны
Ничә ел куган чагым.
Ачык басу капкасыннан
Шәһәргә шуган чагым...

И, минем Олы Бакырчым,
Ата-бабам нигезе,
Сагынсак, чабудан тартып
Кайтарасың син безне.
Түздең эзләр өзелгәндә —
Колакларны бормадың,
Төшләремә кереп тордың,
Истән чыгып тормадың.

Рәхмәт сезгә, читкә китми
Төп йортта яшәүчеләр,
Без йоклаган таңнарда да
Җигелеп эшләүчеләр,
Рәхмәт сезгә, ил табынын
Кайгырткан игенчеләр,
Җир-Ана кадерен белеп,
Игелек игүчеләр!

И, кардәшләр, авылдашлар,
Кай якка, кайчан очсак,
Җиде бабам шәҗәрәсен
Тәсбихтәй тартам һәрчак:
Һидият,
Хәмит,
Хантимер,
Хәбибулла,
Ислам,
Исхак,
Иң түрдәгесе — Чучак —

Сүнмәсен безнең учак!
Болганадыр заманалар,
Тулгана заманалар,
Әлек тә булган ла алар,
Әлек тә узган алар —
Дөнья дигәнең куласа,
Әйләнә дә бер баса:
Таяныч та, ышаныч та
Үзебездә ләбаса!

Кемнәрдер әйтсә, әйтсеннәр,
Караңгы як, дисеннәр...
Яктырта безнең тарихны
Нуры сүнмәс исемнәр:
Чор-дәверләр алмашынып,
Мәйданнарга килсеннәр —
Һәйкәлдәге шәһитләргә
Уйланып баш исеннәр.

Без килербез дә китәрбез,
Туган як мәңге булсын,
Каенсар түбәләрендә
Гел якты таңнар тусын.
Дымбылатым гөрләп аксын,
Кыйбладан борылмасын,
Чирмешәнем саекмасын,
Тамырым корымасын.

И, Тау ягы, туган туфрак —
Иделнең уң канаты,
Илемнең уң канаты, —
Син минем дә канатым!
Шушы җирне сайлап тудым,
Шушы җирне яраттым,
Шушы җир салды күңелгә
Илһамын-мәхәббәтен.
Гомер буе язганнарым
Ул бит сиңа рәхмәтем,
Ул бит минем рәхмәтем!

Поезд киткән...

Кат-кат күрәм,
Бер төш керә
Инде күптән:
Гел соңарам,
Җитми калам —
Поезд киткән...

Баксаң, өндә,
Юраганда
Бу әйбәт фал:
Димәк, әле
Яшәрсең син —
Гомерең бар.

Төштә, өндә...
Юанырга
Әзер кем дә.
Сабыр-салмак
Оеп торам
Якты көндә:

«Киткән, киткән...
Ә бит анда —
Яшьлек киткән!
Өнемдә дә
Гомер-поезд
Выжлап үткән».

Тукай рәсеме

Сынап тора сизгер күңел
Безне ерак көннәрдән,
Гүя шагыйрь беркайчан да
Елмаймаган, көлмәгән.

Күзләрендә бәгырьләрне
Үксетерлек моң тулы,
Милләт язмышын сагышлап
Сискәндергән шом тулы.

Йотылып текәлгән саен
Җаным белән сиземен —
Әйтелмәгән әрнүләре
Үзәкләрне өзгәнен.

Елмаймый борчулы күзләр,
Мәэюс карый сызланып —
Үткәннәрдән карый Тукай
Киләчәкне кызганып...

Туганнар табынга җыелдык...

Фарук, Фәрит, Рәшиткә

Туганнар табынга җыелдык,
Җыелдык без төрле тарафтан,
Сынамак булыптыр, язмышлар
Бигрәкләр тырышып тараткан.

Туганнар табынга җыелдык,
Күңелләр күңелгә сыендык,
Иңнәрдән төште йөк-авырлык,
Онтылды дөньяви кыенлык.

Сөйләшеп сүзләр гел бетмәслек,
Яңара күп уртак истәлек,
Әткәйләр утырган түр, диеп,
Куябыз сагышлап-искәреп...

Табынга җыелдык туганнар,
Күзләргә сагыну тулышкан,
Иң якын, иң газиз кешеләр
Үз бит сез, безнеке тумыштан!

Заманнар киләсе-китәсе,
Бик-бик күп туганнар туасы,
Мин беләм, алар да сезнең күк
Сынатмас ир-егет буласы!

...Җан тарткан, кан тарткан —
очраткан,
Күңелләр сые бу табында.
Гасырлар чик түгел, өзелмик —
Туганнар җыелыйк тагын да!

Фоат ГАЛИМУЛЛИН

ТАТАРНЫҢ ТАҢЫ АТАРМЫ?

Татар мәдәниятенең бик катлаулы күренеш булуы күпләргә мәгълүм. Аның үсеш тарихы, камилләшү юллары бик тә сикәлтәле һәм бормалы. Ул, үзе дә башкаларга мул өлеш чыгарып, шул ук вакытта йогынты алуны да түбәнлек санамыйча, күп гасырлык тарихында зур казанышларга иреште. Әмма шунысын да истән чыгарырга ярамый: нәкъ менә татарның мәдәни яктан алга китүе кайберәүләрне нык куркытты, алар бу юлда киртә коруны үзләренең дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрделәр. Җитмәсә, татарның соңгы дүрт йөз кырык өч елда бу мәсьәләдә нык артка калуын аның үзенең сыйфатларыннан күреп аңлатып килделәр. Әмма немец галиме К.Фукс, урыс тарихчысы М.Худяков, нәсел тамырлары татарларга барып тоташкан бөек галим Л.Гумилев, кайбер башка ачык һәм гадел фикерле шәхесләр моның алай түгеллеген дәлилле аңлатып күрсәттеләр.

Милләттәшләребезгә исә бу турыда авыз ачып әйтергә дә мөмкинлек бирелмәде. Ләкин татар каләм әһелләре арасында турысын ярып салучылар булмады түгел. Шуларның берсе, әлбәттә, Сәгыйть Рәмиев иде. Ул «Таң вакыты»(1907) шигырендә татар халкының 1552 елдан соңгы аянычлы хәлен чынбарлыктагыча бәяләде, шул дәвер эчендә аның күңел дөньясында, фикерләвендә булган үзгәрешләрне күрсәтеп бирергә омтылды. Әлбәттә, моны ул ачыктан-ачык түгел, бәлки юл араларында гына, яшерен-кинаяле итеп кенә әйтә алды.

Илдә бөек кузгалышлар чоры (Г.Тукай, Г.Ибраһимовлар да 1905 елларны «таң вакыты» дип атаганнар иде), ләкин татар һаман да йоклый. Шагыйрьнең лирик герое уйларга, үткәннәр һәм бүгенге турында төпченергә сәләтле булып күзаллана. Башкалардан ул шуның белән аерыла да. Тынгысыз уйлар аның йокысын качыра. Ләкин ул да әлегә урында яткан килеш кенә, ягъни хәрәкәтләрдә катнашмыйча гына борчыла. Татарны йокыдан уяту гамәленә керешер иде дә бит, ләкин аталардан калган хатасы чабуыннан тарта. «Хатам тирән, тамыры ерак», ди шигырь герое. Татарның куркучан булып калуының берничә гасырлык тарихы барлыгын ул яхшы белә. Аның каравы, Сәгыйть Рәмиев каһарманы әйткән: «Теге, ләгънәт, үсә, зурая әле һаман да...» «Теге» дигәне — Рәсәй империясе.

— Татарның хатасы нидән гыйбарәт? — дигән сорау туа. Ул — хәлиткеч вакытларда татарның бердәм булмавы, Казан ханлыгының бөйсезлеген юкка чыгаруда байтак кына милләттәшләребезнең катнашы барлыгы. Моның тарихын колакка тукыйлар, тик үзгәртеп, бозып аңлаталар, төбен тикшерергә кушмыйлар. Балалар, яшь буыннар боларны тыңлавын тыңлыйлар, ләкин сөйләгәннәргә ышанмыйлар. Ник дисәң, рәсми пропаганда тәкрарлаган нәрсәләр чынбарлыктан ерак тора. Алар, Казан ханлыгының басып алынуы, имеш, татарлар өчен файдалы булды, аларның мәдәниятен үсүгә китерде, дип аңлатырга тырышалар. Ялган бервакытта да очны очка ялгый алмый, ул каяндыр бер урыныннан барыбер бүселеп чыга. Шуңа күрә яшьләр мондый аңлатуларга һәрвакыт шикләнеп карадылар. Сәгыйть Рәмиевнең лирик герое — шул күпләрнең берсе.

Моңа кадәр «Таң вакыты» шигырен «татар халкының Ислам тәэсирендә артта калып килүен әрнүле кичереш белән тасвирлый» кебегрәк итеп аңлатып килделәр. Болай дияргә нигез дә бар кебек. Чөнки бер строфа менә нинди фикерләрне үз эченә ала:

Башларын ваткан татарларның
Тик шул бер Алла!
Бетәрләр микән татарлар, Алла, ди-ди?
Әллә белерләр микән хаталарын бер алда?



Шагыйрь С.Рәмиев иҗатын җентекләп тикшергән галим Ш.Садретдинов язуына караганда, автор үзе төзегән кулъязма җыентыгында тексттагы «Алла» сүзләре урынына җөя эчендә күп нокталар куйган. Шулай итеп, укучыга әсәрдән килеп чыга торган дөрес фикерне төшенү мөмкинлеге бирелә. С.Рәмиевнең фикер сөрешеннән шул ачык аңлашыла: «Алла» сүзе биредә «Рәсәй» дигәнне аңлата.

Бу хәл шулай мәңгегә барырмы икәнни? Юк, ди, лирик герой. Моннан котылуның юлы бар. Бу аның татарга мөрәҗәгатендә күренә:

Туг яңадан мәгърифәтле анадан!
Югыйсә син, әй, татар,
Бел, бетәсең! — ди, — надан.
Бетмә надан, туг яңадан
Мәгърифәтле анадан!
Бул кеше, үзең тырыш, өмид итмә,
Хата ул өмид Алладан!

Әгәр соңгы юлны: «Хата ул өмид хаким милләттән», дип укысаң, өстәмә шәрехләүләрнең кирәге калмый. Менә ни өчен егерменче гасыр башындагы рәсми хакимият бу шигырьне сәяси әсәр буларак бәяли, дәфтәрләренә әлеге әсәрне күчереп язган шәкертләрне эзәрлекли. Әгәр шигырь Аллага каршы язылган булса, жандармнарның аңа артык исләре китмәс иде.

Мәгълүм ки, С.Рәмиев, гадәттән тыш куе буяулар кулланып эш итүче, үзенең героен хәтта «Алла» белән тиңләүче романтик шагыйрь булса да, Ислам диненә тирән хөрмәт белән караган шәхес. Башкача була да алмый. Ул — Г.Исхакыйның фикердәше, мәсләктәше. Г.Исхакый, билгеле булганча, милләтнең, аның яшәешендәге алшартларын, мәдәниятнең асыл нигезләрен әхлак һәм дин белән бәйләп аңлаткан иде. Милләтне күтәреп торучы көчләр булган әхлак белән дин юкка чыкса, аның киләчәге өметсез икәнлеге турында әдип һәрдаим кисәтте. «Әүвәл әхлак бозыла, икенчедән, дин бетә, өченчедән, ул халык үзе бетә», — диде ул.

Г.Исхакый хаклы. Чыннан да, татар милләтен юк итәргә тырышучылар һәрвакыт шушы ике иң газиз нәрсәгә — әхлак белән дингә кизәнделәр. Дөрес, биредә милли мәдәниятнең нигез ташларыннан берсе булган тел турында онытырга ярамый. Чөнки телсез милләтнең бүгенгесе дә, киләчәге дә юк.

Милли әхлагыбыз Ислам дине канунларына нигезләнгән. Исламның затлылыгы хакында бөек шәхесләрнең байтак фикерләрен китерергә мөмкин булыр иде. Бу урында шуларның икесе белән генә канәгать итик. «Әгәр кешегә ике диннән берсен сайлау хокукы бирелсә, һәр акыллы кеше Мөхәммәд диненә өстенлек бирер иде» (Л.Толстой). «Күп гасырлар ярым йокы халәтендә булган гарәпләр көтмәгәндә йокыдан уяндылар һәм үзләрендә олы көч һәм ышаныч барлыгын күрсәттеләр. Ул көч — Ислам булды. Бу дин, бөтен дөнья халыкларын гаҗәпкә калдырып, гарәпләрне зур мәдәнияткә һәм тәраккыяткә китерде» (Д.Неру).

Бу сүзләр татар милләтенә дә карый. Чөнки бары тик дин, аның таләпләренә нигезләнгән әхлак кануннары, аларга тугрылык кына безне милләт буларак саклап кала алды. Димәк, динебезгә нигезләнгән мәдәниятебезне саклау һәм үстерү генә милләтебез язмышының киләчәген тәэмин итүгә китерәчәк. Дөрес, совет хакимияте елларында татарларның да дөньяви мәдәнияте нык үсеш алуын һич шикләнмичә билгеләп үтәргә кирәк. Моны инкарь итүчеләр — хакыйкатькә хилафлык кылучылар. Ләкин шунда ук бер үкенү хисе барлыкка килә: их, бу пролетариат диктатурасы дингә үчлек итмәсә, аз санлы милләтләрнең теленә, рухына кизәнмәсә, аларга милли-мәдәни үсеш өчен чын ирек бирсә, бәлки, аны берәү дә инкарь итмәс иде. Ә чынлыкта гайка белән була торган хәл килеп чыкты. Билгеле булганча, гайканы чамадан артык тыгызлап борсаң, аның сырлары зарарлана, ул инде бөтенләй тотанаксыз хәлгә килә. Коммунистлар фиркасе белән дә шулайрак булды: җәмгыятьтәге бөтен хакимиятне үз карамагына җыеп бетергәч, үзе үк гамәлдән төшеп калды. «Муса Бигиев, Зәки Вәлиди, Гаяз Исхаков ише «милли каһарманнар»: пролетариат диктатурасы милләтләрне, аларның гореф-гадәтләрен, диннәрен, телләрен, культураларын бетерә, дип күрсәтмәкче булдылар», — диюче К.Фасеевлар, ягъни фирканең бу өлкәдәге мәсләген бүтәнчә итеп күрсәтергә тырышучылар да ярдәм итә алмадылар. Бу сүзләр язылган елда (кара: «Казан утлары», 1967, № 3, 96 бит) инде шәһәрләрдәге мәктәпләрдән, башка уку йортларыннан татар теле кысрыклап чыгарылган, бөтен Казанына эшләүче бер мәчет калган иде. Хәтта саф татар авылларында да балаларны башка милләт телендә укырга мәҗбүр итә башлаганнар иде.

Идеология хәтта өйләнешү кебек үтә интим өлкәгә дә үтеп керде. Катнаш никахларны хуплау совет чоры идеологиясенең төп юнәлешләреннән берсе булды. Чөнки ул «вак» милләтләрнең зурысы тарафыннан йотыла баруларын тәэмин итүнең иң нәтиҗәле юлларыннан берсе саналды. Язучылардан да моны уңай күренеш итеп сурәтләү таләп ителде. Мәсәлән, Б.Кербабаев «Су тамчысы — алтын бөртеге» романында төрекмән егете белән урыс кызының өйләнешүләрен тасвирлый. Дөрес, башта егетнең әнисе Бостанның моңа нык каршы булуы күрсәтелә. Ләкин тора-бара автор ананың җиңелүен, бу хәл белән килешергә мәҗбүр булуын сурәтли. Р.Солнцевның (Р.Суфиев) «Яшел калкулыкта кызыл ат» повестенда да Путятин фамилияле урыс егете татар кызы Аза Кәримовага өйләнә. Туйны татар йолаларын да кушып уздыралар. Ләкин тормыш тәҗрибәсе мондый ясалма «интернациональләшү»нең уңышлы эш булмавын хисапсыз күп мисалларда раслап килә. Андый гаиләләрдә балалар бер телле — урыс телендә сөйләшүче булып үсәләр, татар милләтенең үтә газиз мәдәни кыйммәтләре алар өчен чит-ят булып кала.

Саф татар гаиләләрендә милли-мәдәни нигезләрнең өкренләп җуела баруының сәбәпләрен дә җәмгыятьтәге хәлләрдән эзләргә кирәк. Татар теле өйгә куып кертелде, дибез. Әмма байтак илләрдә үз милләтебездән булган ир белән хатынның да бер кәлимә татарча сүз әйтмәүләре сирәк күренеш түгел. Андыйлар иҗади зыялылар арасында да байтак, монысы аеруча борчый. Исем китте, хәтта Һ.Такташ та улының «папа» дип сөйләшүенә килешеп караган икән. «Мин күптән инде аның «папа» дигән сүзен ишеткәнем юк. Миңа бик авыр, ул, бәлки, инде ул сүзне әйтергә дә оныткандыр», дип яза.

Бездә ир белән хатынның бер-берсен «ирем», «хатыным» дип атавы табигый яңгырый. Бу шулай булырга тиеш. Әмма моннан алтмыш-җитмеш еллар элек шушы гадәти һәм дөрес сүзләр урынына «иптәшем» дип әйтүне гамәлгә керттеләр. Җыелышларда, рәсми шартларда телдән төшми торган бу сүз, әрсезләнеп гаиләне дә яулап алды. Югыйсә, ир белән хатын мөнәсәбәте җыелышлардагы иптәшләрнекеннән бик нык аерыла бит, аны нинди дә рәсми «иптәш» сүзе ачып бетерә алмый. Иптәшләр күп була, ир яки хатын — берәнбер. Аларның мөнәсәбәте дә мәхәббәт көче белән билгеләнә. Шул «иптәш» сүзен гаилә мохитенә кертеп җибәрүгә, гаҗәпкә каршы, язучылар да өлеш керткәннәр. Г.Толымбай, мәсәлән, «Кызыл армиядән кайткач» (1925) исемле хикәядә Җиһангәрәй исемле егетнең өйләнүен болай тасвирлый:

«Әти-әни! Менә инде мин иптәшләндем. Сез моңар иптәшем дип карагыз, — ди Җиһангәрәй. Кыз да бер дә оялып тормый:

— Мин Җиһангәрәйгә иптәшлеккә килдем».

Бу мәсьәләдә татар тагын арттырып җибәрә. Минем, мәсәлән, урысларның хатынына яки иренә «товарищ» дип эндәшкәнен яки атаганын ишеткәнем юк. Алар мондый нәрсәләрдә күпкә «консервативрак». Һәм дөрес итәләр. Ә без, әйтеп торганны да көтмәстән, алдан йөгерергә тырышабыз. Мәктәптә татар телен бетерү дигәндә сәгатенә «йөз чакрым» тизлек белән чапсак, туган телебезне сабыйларыбызга, мәктәпләребезгә кире кайтару дигәндә, бер алга, биш артка карыйбыз. Аз санлы милләтләрне юкка чыгаруны яшәү максаты итеп алган Н.Ильменский кебекләрнең эшен җиңеләйтергә генә торабыз. Ул 1892 елда болай дип язган иде: «Урыс мәгарифенең төп максаты — башка халыкларны урыслаштыру, аларның телләрен, диннәрен урыслар белән бергә кушу булырга тиеш». Пролетариат диктатурасы чорында да шулай эшләнмәдемени? Сезнең татар балаларына татар теле һәм әдәбиятын укытучы берәр кешегә Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелгәнлеген ишеткәнегез бармы? Юктыр. Минем дә юк. Ә менә татар балаларына урыс телен һәм әдәбиятын укытучы андый Герой бездә булды. Минем бу хөрмәтлебезгә берниндди дә дәгъвам юк, ул — әйбәт укытучы, моңа лаек. Әмма шуның янында, үлчәү теләнкәләре тигезлеген саклау өчен генә булса да, бер татар теле укытучысы да Каһарман булса, кемгә нинди зыян булыр иде? Югыйсә, андый фидакарь укытучыларны мин үзем генә дә берничә дистә саный алам.

Татарстанны хәзер мөстәкыйль җөмһүрият, диләр. Милләтебезнең бер бик яхшы гадәте бар. Ул түбәндәгегә кайтып кала: «татар тотып карамыйча ышанмас». Димәк, Татарстан мөстәкыйль дәүләт икән, бу аның мәдәни үсештә иректә эш итүендә дә күренергә тиеш. Әмма дәүләт үзе генә бу мәсьәләләрне хәл итүдә өлләни уңышка ирешә алмас. Хәлиткеч көч — без, ягъни халык. Татар мәдәниятен әр-яңадан аякка бастыру, халкыбызның кемлеген дөньяга мәдәни казанышлары белән таныту өчен бүген һәркем армый-талмый кулыннан килгәнне эшләргә тиеш. «Мәдәни җомга» шушы олы юлда әйдәүче, туплаучы көч булыр дип өметләник. Әмин!

ҖЫРЧЫ СӨЛӘЙМАН ЙОСЫПОВКА 70 ЯШЬ

ҖЫРЛАМЫЙ МӨМКИН ТҮГЕЛ

— Сөләйман ага, олы сәнгатькә юл салганда Сез кайсы җырчыны өлге итеп куйдыгыз, гомумән, җыр дөньясына килергә, сәхнәгә күтәрелергә нинди көчләр этәргеч бирде?

— Гөлсем Сөләйманова һәм Рәшит Ваһапов. Алар миңа өлге дә, яктылык, нур бирүче изге көч тә булдылар.

Туган авылым Алан бик матур җирдә урнашкан, аның болыннарында йөргәндә күңелдә шатлык, якты хисләр туа, кычкырып җырлап җибәрәсе килә иде.

Иртә язларда, матур җәйләрдә атна саен егетләр һәм кызлар Мишә буена күңел ачарга җыела иде. Таң әтәчләре кычкырганчы тальян тавышы, җыр яңгырап тора. Малай чак, үсмер еллар әнә шул гүзәл мизгелләре белән хәтергә уелды.

Бай табигать, авылдашларымның шул күркәмлеккә җыр, биюе белән килеп кушылуы миңа да музыканы яратырга һәм җырчы булырга ярдәм иткәндер дип уйлыйм.

Соңыннан, мәктәптә укыганда, Совет армиясе сафларында хезмәт иткәндә дә үзешчән сәнгать түгәрәкләренә йөрдем.

1948 елда конкурс аша Белоруссия хәрби округының җыр һәм бию ансамбленә җырчы булып алындым. Бу бик көчле профессиональ ансамбль иде. 1950 елны Казанга кайттым, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә җырчы булып эшкә кердем.

Рәйсә Яппарова, ансамбль солисты, хәзерге вакытта шушы коллективның администраторы:
— Мин үзем Башкортстаннан. Музыка училищесыннан бик яшьли шушы ансамбльгә килеп кердем. Өлкән артистлар яшьләрне үз итеп, балаларыдай якын күреп эшләделәр. Зәп-зәңгәр күзле, күркәм кыяфәтле Сөләйман Йосыпов белән бергә байтак концертларда, ансамбль чыгышларында катнаштым, җырладым, концертлар алып бардым. Кытайда узган өч ай ярымлык гастрольләрдән соң без аның белән бергә лекция-концертлар оештырдык. Сөләйман абый (мин аны чын мәгънәсендә абыем кебек күрәм), йомшак күңелле, ачык кеше иде. Ул пенсия яшенә җитсә дә, һаман яшь булып калды. Гомер юлымдагы иң җылы, якты мизгелләр җырчы Сөләйман Йосыпов белән эшләгән чорга туры килә. Рәхмәт аңа! Хезмәттәшемне 70 еллыгы белән котлыйм!

— Иҗат еллары истәлекләре белән уртаклашсагыз иде.

— Минем иҗат елларымның күбесе Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле белән бәйле. Анда гади хор җырчысыннан төп солист дәрәҗәсенә үстем. 1960 елда Татарстанның атказанган артисты дигән исем бирделәр. 1964 елда эстрадага күчтем һәм үземнең бригада белән эшли башладым.

Ул елларда авылларда гастрольдә йөрүләре бик авыр иде. Клублар бик кечкенә, электр лампочкалары юк. Түшәмгә берничә керосин лампасы эленгән булыр. Кышын исә клуб артистлар килгәч кенә ягыла. Мондый җылыту сәхнә почмакларындагы бозны эретеп тә бетерми. Халык белән шыгрым тулган клуб түшәменнән идәнгә тамчы тама да, сәхнәдә боз тәерчекләре хасил була. Артист шул суык сәхнәдә туфлидән, җиңел киемнән яртышар сәгать җырлый, бии. Ә җәйге эссе көндә сәхнәгә костюмнан чыгасың, арка буйлап тир бөртекләре тәгәри.

Минем тавыш — татар халкында сирәк очрый торган бас. Татарлар калын тавышны бик яратып бетерми иде. Беренче концертларда җырлаганда Галиәсгар Камал театрының галеркасыннан: «Бигрәк җуан җырлыйсың, нечкәрәк итеп суз», — дип кычкырган тавышларны да ишеттем. Соңыннан җырлавыма да, тавышыма да халык ияләнде. Яратты.

Мөҗип Садыйков, Татарстанның атказанган артисты:
— Сөләйман абый белән мин ике ел бергә эшләдем. Ул гаҗәп тыйнак, әмма шат күңелле, төшенкелеккә бирелми торган кеше иде. Гастрольләр вакытында ат-арбада, бик үк йомшак булмаган вагоннарда йөргәндә дә шаян сүзләре белән кешеләрнең кәефен күрде, саф күңелле үрнәк кеше булды. Хәзер дә радиодан аның тавышы яңгырап, кешеләрнең җанын җылытып, рухландырып тора.
Мин егерме сигез ел сәхнәдә җырлап та, Сөләйман Йосыпов кебек бас белән җырлаучыны хәзергә кадәр очрата алганым юк. Ул милли сәнгатьне үстерүдә яратып, бирелеп эшләде. Җырчылар Сөләйман Йосыпов, Разия Тимерханова, Зәйтүнә Әхтәмова бүгенгә көнгә кадәр минем өчен илһам чыганагы булып калалар. Алар гомер буена татар сәнгате өчен янып яшәделәр һәм башкаларны да үзләре артыннан әйдәделәр. Өлегә җырчылар белән эшләү минем өчен зур бәхет булды.

Иҗат юлымда миңа татар халкының данлыклы җырчылары Әлфия Авзалова, Венера Шәрипова, Габдулла Рәхимкулов, Рәйсә Билалова һәм башкалар белән эшләргә туры килде.

Композитор, скрипкачы Заһид Хәбибуллин белән иҗат, тормыш юлларыбыз дустанә үрелеп барды. Тормыш иптәшләребез — үзебез кебек сәнгать кешеләре, Заһидныкы — биюче, минем Рәйсә — җырчы. Шуңа күрә сәхнәдә дә, тормышта да дус, тату, аралашып яшәдек.

— Артистлар тормышында кызык һәм хәтта кызганыч хәлләр дә очрап тора...

— Тетрәндергән бер хәл турында гына сөйлим. Качалов исемендәге Рус зур драма театрында концерт бара. Программада минем чыгыштан алда бию куелган. Аны Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры биючесе Рөстәм Сафин башкара. Бу чыгышта артист, биюен бетереп, сәхнә артына кереп җитә алмады, егылды. Аны бизәнү бүлмәсенә күтәреп кертеп салдылар да, ул шунда җан бирде. Мин сәхнәгә чыктым, җырладым (тамашачының гаебе юк, җырламый мөмкин түгел). Тик ул кичтә ни җырлаганымны, ничек башкарганымны хәтерләмим. Сәхнә артына кергәч: «Син ап-ак булып агаргансың», — диделәр. Әнә шулай артист сәхнәдә соңгы сулышын алды.

— Муса Җәлил: «Гомерем минем моңлы бер җыр иде», — дип язган. Сез җырлый-җырлый халыкның мәхәббәтен яулаган моң иясе бу сүзләрне ничек бәялисез? Һәм үзегезгә карата ничек әйтер идегез?

— Җырчы кешә — хыялый кешә. Әкәмәт, сәер, җыр белән җенләнгән, дисәң дә ярый. Кая барсаң да, ни генә эшләсәң дә, күңелдә җыр, ул һаман да яңгырый. Җырчы сәнгатьне яратмаса, гаиләсен, балаларын калдырып, өчәр ай гастрольләрдә йөри алмас иде. Мин үзем җырга мөкиббән киткән әкәмәт кеше идем. Тормыш иптәшем Рәйсә дә ансамбльдә җырлады. Кызыбыз, улыбыз туды. Ана булса да җәмгыятем сәхнәдән китә алмады. Балалар әби-бабай кулында үсте. Гастрольгә киткәндә елашып аерылабыз, кайткач та күз яшьләре аша күрешәбез. Шөкер, гаиләбез татулык кичерде, кырык дүрт ел бергә яшибез. Кыз һәм улыбызның да балалары үсеп җитте. Оныкларның балаларын күрү бәхетенә ирештек.

Мәгълүм булганча, 1957 елда Мәскәүдә Татарстан әдәбияты һәм сәнгате декадасы узды. Без анда өчәү бардык: иптәшем Рәйсә, кызым Ләлә, мин. Концерт

башында сәхнәгә балалар биеп керә, ике бала иң түргә зур күкәй күтәреп килә һәм аннан Ләлә елмаеп килеп чыга да, шуннан «Сабантуй» музыкаль композициясе башланып китә. Ләлә матур җырласа да, җырчы һөнәрен сайламады. Улыбыз Шамил музыка училищесын, консерваторияне тәмамлады. Хәзер ул Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында эшли, ирләр академик хорына җитәкчелек итә. Кияү дә шушы театрда эшләп, ялга чыкты.

— Сөләйман ага, Сез: «Җыр мине бәхетле итте!» — дип әйтә аласызмы?

— Чынлап та: «Җыр мине бәхетле итте!» — дип аяк терәп әйтә алам. «Гомерем җыр белән узды!» — дип горурланам.

— Илленче-алтмышынчы еллар җырлары, башкаручылар белән бүгенге көн иҗатчылары арасындагы уртаклык һәм үзгәлек бармы?

— Безнең чордашлар сәхнәгә җан таләбе буенча күтәрелде һәм күбесе зур иҗат мирасы калдырды. Элек радио тапшыруларында да бер көнлек шау-шуга корылган, күңелдә калмый торган җыр яңгырамады. Анда эшләүче Зәйнәп Хәйруллина бик таләпчән кеше, музыка дөньясын яхшы белә иде. Җырларны чын шагыйрьләр һәм композиторлар язды. Ә ул әсәрләрне профессиональ артистлар башкарды.

— Тормышыгызда, иҗатыгызда иң кадерле кешегез бармы?

— Иң кадерлеләрем минем тормыш иптәшем Рәйсә һәм дустым композитор Исмай Шәмсетдинов.

— Егерме биш ел дәвамында халыкның милли горурлыгы, сәнгатьнең йөзек кашына әверелгән кешегә тыныч картлык, оныклар сөенече, мөгаен, ул яшьлеккә кире кайтуны хәтерләтәдер.

— Өч оныгым, онытымның бер баласы бар. Мин аларны бик яратам, бергә-бергә вакытның үткәнен сизми дә калам. Сөенечле еллар кичерәм.

— Сез бакча яратучы да бит әле. Бу эшкә күптән алындыгызмы? Табигать кочагында җырлап җибәреп, сандугачларны көнләштерәсездер.

— 1982 елда үземнең сөекле Мишә буенда җир алып, йорт, мунча салдым, бакча утырттым. Хәзер һәр иртә яздан кара көзгә кадәр Рәйсә, онытым Адел белән шунда яшибез. Кәеф барда җырлап та җибәрәм, ләкин сандугачлар миннән көнләшми. Гомер буе мин алардан көнләшәм.

Лима Кустабаева, Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе:
— Егерме биш ел ансамбльдә эшләү дәверендә җырчы Сөләйман Йосыпов коллектив өчен сәнгать йолдызы һәм кеше буларак үрнәк булып тора. Аның белән эшли башлаган кешеләрнең кайберләре инде пенсия яшенә җиттеләр. Әмма чын остаз йогынтысы ансамбль эшчәнлегендә бүген дә дәвам итә. Татарстан сәнгатендә шундый якты йолдызларның балкып торуы зур байлык та, милли горурлык та. ...Хөрмәтле Сөләйман ага! Татарстанның дөнья күләмендә танылган җыр һәм бию ансамбле Сезне олы юбилеегыз белән котлый, иҗат уңышлары тели, Сез катнашкан «Йолдызлар сүнми әле» программасындагы кебек, һәрвакыт якты йолдыз сыман балкып, талантлы яшьләргә юл күрсәтеп торуыгызны тели. Туган көнегез мөбарәк булсын!

— Бүгенге сәнгатьнең кайсы якларын кабул итә алмыйсыз?

— Тормыш авыр, әлбәттә. Ә сәнгатькә акча, исем өчен генә килгән кешеләр байтак. Сай мәгънәле, тозсыз җырлар җанны өрнетә. Ни генә булмасын, чын сәнгать барыбер өстенлеккә тотачак.

— Әгәр Сөләйман Йосыпов исемендәге премия булдырылса, Сез аны хәзерге көн җырчыларыннан кемгә тапшырыр идегез һәм ни өчен?

— Хөкүмәтебез Рәшит Ваһапов исемендә премия булдырса, мин бу бүләкне Зәйнәп Фәрхетдинова белән Зөфәр Билаловка бирүләрен телә идем. Аларның башкалардан үзгә тавышлары, моңнары, репертуары, профессиональ осталыклары бар.

— Яраткан шагыйрьләрегез һәм күңелегезгә аерата хуш килгән җыр бармы?

— Гөлшат Зәйнашева, Мансур Шиһапов, Шәмсия Җиһангирова... Күңелне дулкынландырган җыр — «Умырзая».

— Шаян җырлар, юмор һәм сатира белән дуслашу яшәешегезгә җиңеллек бирдеме?

— Юмор-сатира үзе үк күңелне күтәреп, дәртләндереп җибәрә. Ә шаян җырлар яшәртә, тормыш авырлыкларын җиңәргә ярдәм итә.

— Иҗат кешеләрендә нинди сыйфатларны югары бәялисез?

— Талант, тырышлык, яхшы мәгънәдәге әрсезлек.

— Гомер юлын кабат башлап китү мөмкин булса, Сез аны үзгәртер идегезме?

— Хәзергә тәҗрибә белән кайбер ялгышларны төзәтеп, шул ук юлдан китәр идем.

Әңгәмәне
Сәрмәдия СӨЛӘЙМАН
оештырды.

Гарифҗан Әмирҗанов, Татарстанның атказанган артисты:
— Беренче тапкыр Сөләйман абыйның тавышын безнең Бикбау-Куян авылына эстрада концерты белән килгәч ишеттем. Клубта басып торырга да урын юк, авылдашлар стена буйлап тезелгән, минем ише бала-чага урамнан клуб тәрәзәсенә капланган. Дөньямны онытып тыңладым мин ул концертны. Җырчының осталыгына соклану, илһам алу шушы кичәдән башланды һәм мәңге онытылмаслык итеп хәтергә уелып калды.

● 60 нчы елларда С.Йосыпов җырчы М.Вилданова белән чыгыш ясый.

СИРАТ КҮПЕРЕН КИЧКӘНДӘ

Булат СОЛТАНБЕКОВ

СЕРЕҢ АЧ, СИРИН!..

(Ахыры. Башы 1 нче санда).

Советка каршы язылган әсәрләренең иң югары «ноктасы» итеп шагыйрьнең Сталинга эпиграммасы алына. Дөрес, анда, Мандельштамның мәгълүм эпиграммасындагы кебек, шәхескә карата кимсетүле бәяләмә юк, «тараканныкы кебек» мыек та, «киң осетин күкрәге» дә искә алынмый. Әмма бу шигырь тагын да зуррак сарказм көченә ия. Менә аның эчтәлеге: Сандугач, син ташла гел бер төрле сайравыңны, Сталинны гына макта. Шуннан сине күреп алырлар һәм СССРның халык сандугачы итәрләр. Каты әйтелгән. Ул чаклардагы кайбер шагыйрьләргә, шул исәптән, татарныкыларга да атап әйтелгән кебек.

Шагыйрьнең түрәләргә бирелгән өстенлекләр, халыкны коммунизм дип алдап йөртүләр турындагы кыю шигырьләре дә советка аршылар рәтенә кертелә. Вакыт-вакыт Сирин эзоп теленә дә мөрәҗәгать итә. Халыкара конференциядә фашизмга каршы «чыгыш» ясавы турындагы шигырендә ул, башка илне тәнкыйтьләгән булып, шул илнең тәртипләре, сыйфатлары аша Советлар Союзын тәсмерли торган итеп язган. Иҗтимагый тормышның җимерелүе, коллективлаштыру һәм индустрияләштерүнең бөтен авырлыгы шагыйрь йөрәге аша уза, күп хезмәттәшләренең яраклашуын намусы кабул итми. Шуннан инде аның әңгәмәдәшенә юнәлдерелгән «мине шагыйрь дип атама. Халыкны алдау — хурлык» дигән нәфрәтле юллары килеп туа.

Советка каршы язылган әсәрләренең иң югары «ноктасы» итеп шагыйрьнең Сталинга эпиграммасы алына. Дөрес, анда, Мандельштамның мәгълүм эпиграммасындагы кебек, шәхескә карата кимсетүле бәяләмә юк, «тараканныкы кебек» мыек та, «киң осетин күкрәге» дә искә алынмый. Әмма бу шигырь тагын да зуррак сарказм көченә ия. Менә аның эчтәлеге: Сандугач, син ташла гел бертөрле сайравыңны, Сталинны гына макта. Шуннан сине күреп алырлар һәм СССРның халык сандугачы итәрләр. Каты әйтелгән. Ул чаклардагы кайбер шагыйрьләргә, шул исәптән татарныкыларга да, атап әйтелгән кебек.

Шагыйрьнең түрәләргә бирелгән өстенлекләр, халыкны коммунизм дип алдап йөртүләр турындагы кыю шигырьләре дә Советка каршылар рәтенә кертелә. Вакыт-вакыт Сирин Эзоп теленә дә мөрәҗәгать итә. Халыкара конференциядә фашизмга каршы «чыгыш» ясавы турындагы шигырендә ул, башка илне тәнкыйтьләгән булып, шул илнең тәртипләре, сыйфатлары аша Советлар Союзын тәсмерли торган итеп язган. Иҗтимагый тормышның җимерелүе, коллективлаштыру һәм индустрияләштерүнең бөтен авырлыгы шагыйрь йөрәге аша уза, күп хезмәттәшләренең яраклашуын намусы кабул итми. Шуннан инде аның әңгәмәдәшенә юнәлдерелгән «мине шагыйрь дип атама. Халыкны алдау — хурлык» дигән нәфрәтле юллары килеп туа.

Югарыда әйтелгәннәрдән бу шагыйрь фаш итүче генә булган икән, дигән фикер кала күрмәсен. Аның Алла биргән чын талантын беркем дә шик астына алмыйдыр. Бик тә аңлаешлы сәбәпләр аркасында бу кадәресе ОГПУны тамчы да кызыксындырмый, әлбәттә... Һәртөрле гап-гади әләккә охшаган ашыгыч мәгълүматларга карасаң, Сирин тарафыннан совет чынбарлыгына ачыктан-ачык бәя бирүләр дә булган. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: коллективлашу кирәгеннән алда башланды һәм начар үткәрелде; Кировны үтерү ул — ОГПУның Сталин боерыгы белән башкарылган астыртын эше; хакимиятнең социаль заказын үтәүче әдәбият — әхлаксыз әдәбият; социаль гаделлек вәгъдә иткән совет власте чынында исә түрәләр сыйныфы хөкем сөргән яңа капиталистик стройны аякка бастырды.

Агымдгы көндәлек вакыйгаларга шулкадәр намуслы һәм куркусыз рәвештә бәя биргән әдипләр бездә һәм хәтта элекке Союз күләмендә күп булганмы? Хәбәрдарлыкка күнеккән бүгенге укучының, нәрсәсе бар инде моның, дип әйтүе мөмкин. Дөрес, үзебезнең хакимиятне без хәзер аннан да катырак тәнкыйтьлибез. Әмма утызынчы еллардагы тоталитар дәүләтнең халыкны дер селкетеп тотуга нигезләнгән булуын онытып җибәрмик. Хакимиятне ачыктан-ачык тәнкыйтьләгән өчен генә түгел, хәтта бөтенләй зарарсыз нәрсәләр өчен дә ул елларда «58 нче маддә»не эләктерергә мөмкин иде. Ә менә Сирин ул чорда кирәгеннән артык кыюлык күрсәтә. Атласов белән әңгәмәсе генә дә ни тора! Коллективлаштырабыз дигән булып, мужикның арт ягына имән чөй кактылар, ди Атласов; Сирин шуңа, мин ул чөйне күрдем, мужик аңа озак чыдамас — я болай, я тегеләй булыр, дип өстәп куя.

Төркемнең башка кешеләренә карата гаепләүләр бик күп булмый, шулай да саллы килеп чыга. Кайберләре каләмдәшләренең әләгенә нигезләнә. Бер генә мисал: «Татиздат директорына язучы (фәләннән)... Сезнең хезмәттәшегез Хәкимов Исмәгыйльнең иптәш Сталинны үтерү нияте **бар** икән. Шуны Сезгә җиткерүне **бурычым** дип санадым. 1935 **ел,** 3 май». Кулы куелган. Кара-**каршы** китереп сорау алганда **исә** язучы тегенең яласыннан **катгый** рәвештә баш тарта һәм аны ялганчы, адәм актыгы дип атый. Әмма инде эшләнәсе эшләнгән була: Хәкимовны террор гамәле эшләргә әзерләнүдә гаеплиләр.

Шул замандагы материаллар белән танышкач, озак вакытлар реабилитация барышына җитәкчелек иткән А.Яковлев сүзләрен яхшырак аңлый төшәсең: әхлак җәһәтеннән иң читене шул, — ди ул, — пычранмаган кешеләрнең образы югала бара, чөнки палач белән корбан арасы тотрыксыз булган. Еш кына кулы да калтырамыйча үзенең партиядәш, каләмдәш иптәшләрен, галимнәрне НКВД подвалларына озаткан, мөнбәрләрдән торып, аларның гаепләрен «ачып салган» кеше озак та үтми үзе дә шулар арасына килеп эләккән. Бу хакта Татарстанның кайбер партидеологлары һәм тарихчылары мисалында Казанның элеккеге мэры Павел Аксенов үзенең уникаль истәлекләрендә язып та чыкты. Күптән түгел шундый бер идеология фронты «боевигы»ның кызы үзенең чыгышында әтисе белән горурлануы турында әйткән иде. Киресенчә, «37 нче елга» идеологик нигез әзерләүдәге рольләре һәм алданган язмышлары өчен аларны кызганырга кирәк. Ә менә Сирин, Айдар кебек шәхесләрнең балалары һәм оныклары алар белән чын мәгънәсендә горурлана алалар. Чөнки бу кешеләр дәһшәтле елларда да чын дөресен кыю рәвештә сөйләүдән курыкмадылар.

Батыршин һәм башкаларның эше, октябрь ахырында тәгәлләнеп, 11 ноябрьдә документлары Мәскәүгә җибәрелә. Шулай итеп, Батыршин, Хәкимов, Ризванов, Кулиев, Айдаров совет властен бәреп төшерергә һәм контрреволюцион оешма оештырырга җыенуда гаепләнәләр. Ләкин декабрь башында Мәскәүдән килгән җавап аптырашта калдыра. Анда: «дело» бу хәлендә карап тикшерелә алмый, диелгән була. Җинаятьне — фашистик террорны оештыру өчен агитацияләүне раслый торган саллы дәлилләрнең юклыгы әйтелә. Шаһитләрдән янә сорау алырга боералар. Гади тел белән әйткәндә, эштә брак җибәрелә, тупланган «кәгазьләр» атарга дигән җәзаны күтәрә алмый. Кыскасы, тикшерү эшләре дәвам иттерелә, Татарстан НКВДсы исә начар эшләве өчен кисәтү ала.

● Сирин 1935 елның көзендә Казандагы Плетән төрмәсендә.

Декабрьнең буеннан-буена һәм 1936 ел гыйнварының беренче яртысына хәтле шаһитләрдән һәм гаепләнүчеләрнең хезмәттәшләреннән кат-кат сорау алына. Өр-яңадан егерме кеше сорауларга җавап бирә. Ләкин алар берninди яңа нәрсә өсти алмыйлар. Сталинны үтерү мәсьәләсе дә, баш күтәрүчеләр төркемен оештыру да — берсе дә расланмый. Тагын бер мәртәбә ассызыклап әйтәсе килә: бу әле чагыштырмача «йомшак» итеп сорау алулар вакыты була

1937 елда ерткычларча кыйналар һәм ашатмыйча-эчертмичә, йоклатмыйча аягүрә бастырып тотулар нәтиҗәсендә кешеләр әллә нинди гаепләрне дә танырга мәҗбүр булалар. «Гаебен» танымаучыларны үтергәнче кыйныйлар. Ә 1935 елда исә әле тикшерүчегә дә каршы әйтергә мөмкин була.

1936 елның февралендә Мәскәүдән Махсус киңәшмәнең карары килә. Анда болай диелә: әдәбият фронтында контрреволюцион көрәш оештырганнары өчен И.В.Кулиев (1885 елгы) Карагандадагы төзәтү-хезмәт лагерена 3 елга; Г.И.Ризванов (1892 елгы) — 3 елга; И-Э.Хәкимов (1906 елгы) — 5 елга, С.К.Батыршин (1896 елгы) Себердәге лагерьга — 5 елга; Ә.Х.Айдаров (1906 елгы) — 3 елга ябарга дип хөкем ителә. Шунда ук А.М.Якуповны (1911 елгы) контрреволюцион эшчәнлек турында тиешле органнарга хәбәр итмәгән өчен 1 елга ачык күзәтү астына алырга, диелә.

Заманасы өчен бу шактый йомшак хөкем була. Анда террор да, «баш күтәрүчеләр» дә күрсәтелми.

Батыршинның тоткындашлары язмышы төрлечә була. Кулиев 1937 елда Караганда янындагы Долинка лагеренда үлеп кала. Хәкимовны шунда ук 1940 елда туберкулез алып китә. Батыршин белән Айдаров, хөкем карары үтәлгәннән соң, Бөек Ватан сугышына катнашалар. Гәрчә кат-кат яраланып, контузияләр алсалар да, икесе дә исән калып, бүләкләргә дә лаек булалар. Аларның язмышы шактый бәхетле тәгәлләнә, дип санарга мөмкин — ике тапкыр сират күперен кичеп, «тәмуг базы»на төшеп һәлак булудан котылып калалар. Әмма Сириннең шагыйрьлек язмышы барыбер җимерелә. Ул әле озак яши, ләкин инде шагыйрь буларак сүрелә. Алтмышынчы елларда аны күргән Рафаэль Мостафин әйткәнчә, умартачы Батыршин кешеләрнең әле дә булса шагыйрь Сиринне хәтерләүләренә бик гаҗәпләнә. Әсгать Айдар исә сугыштан соң яңадан әдәбиятка әйләнеп кайта, шаянлыгын-җорлыгын югалтмый, әмма Караганда лагере сынавы һәм сугыш яралары үзенекен итә — ул 53 яшендә инде дөнья куя.

Югарыда сез укыганнар татар халкының сират күперен кичкән талантлы, кыю уллары истәлегенә тирән ихтирам билгесе генә түгел. Алар — киләчәк турында кисәтү дә. Без үзебезнең бүгенге катлаулы көннәребездән еш зарланабыз. Кайчак хәтта: «Их, менә элек тәртип шәп иде ул!» дигән сүзләр дә ишетелгәли. Әйе, шәп иде! Ләкин ул тәртипнең бәһасе нинди иде. Алай-болай диктатура яңадан торгызыла калса, Татарстанның суверенитеты бетерелсә (кайберәүләр эчтән генә шул турыда хыяллана), репрессия тегермәненең ташлары арасында сез үзегез дә, балаларыгыз да, оныкларыгыз да исән калыр дип өметләнмәгез. Һәртөрле Жириновскийлар, Зюгановлар һәм башка шуның ишеләр берәүгә дә мәрхәмәт күрсәтмәс. Киләчәктәге шундый «танкократия» һәм сугышчан шовинизм чалымнарын без инә Чечня фаҗигасендә дә күрәбез. Шуның өчен без, нихәтле генә катлаулы булмасын, бүгенге заманабызның кадерен, Татарстанда халкыбыз, Президентыбыз, депутатларыбыз тарафыннан эшләгәннәрнең кадерен белсәк иде.

(Ахыры. Башы 6 нчы биттә).

— Моннан ике ай элек чыгарга тиеш иде инде бу роман, тоткарлап килделәр. Бары тик Сибгат Хәким тырышлыгы аркасында гына басыла башлады, — диде Салих Баттал.

Шагыйрьнең иҗат юлында киртәләр дә күп иде шул. Шул ук вакытта, аның җыелышларда, утырышларда кисәк-кисәк әйтеп куйган тәнкыйть утыннан бик тә шүрлиләр иде...

Салих абыйның, егет булып үсеп килгән бер чагында, ачлык елны, Тигәнәле авылыннан китеп, Мәскәү тирәсендә көтүче ярдәмчесе булып эшләп йөргәнен белә идем мин. Шуны искә төшереп әйткәнен хәтерлим:

— Карт көтүчемне тәнкыйтьләп бер шигырь язган идем. Маллар җәйләүгә таралгач, аны үзенә укып күрсәттем, фикерен белергә теләдем. Героем, рәхәте килеп, шаркылдап көлде: «Молодец, с тебя Есенин получится, но больше обо мне ни гу-гу, башку оторву», — диде. Бу минем беренче шигырем иде. Аны мин ничек кирәк алай урысчага тәрҗемә итеп укыдым. Ачлык ел беткән иде инде. Карт көтүче миңа шәһәргә китәргә, берәр заводка эшкә керергә,

нгә кадәр беркайда да басылмаган сатирик әсәре — «Капчыктагы безләр»е турында сөйләп алды. Их, әнә шул пьесасын сәхнәдә күрәсе иде...

Бер дә юкка-барга зарлана белә торганнардан түгел иде ул. Хәтерлим әле, аның партиядән чыгарылган вакытлары иде. Партбилетын Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табеев, кулыннан алып, үз кесәсенә тыккан. Шагыйрьне Мәскәүгә КПСС Үзәк Комитетына чакырган булганнар. Аны Татарстан Язучылар берлегенең шул еллардагы партия оешмасы секретаре Абдулла Гомәр озата барган... Барып кергәч, шагыйрьне мөлаем генә бер хатын каршылый. Әңгәмә үткәрә. Сөйләшүдән соң әйтә:

— Очень плохо поработал с татарами Иван Грозный, — ди.

Үзенең кая килгәнен яхшы аңлаган Салих Баттал тешен кысып булса да түзә, эндәшми. Ул елларда шулай кирәк булгандыр шул...

... Салих Батталның автобиографик әсәре басылып чыккан ел иде.

— Безнең татар әдәбияты мемуарларга бик ярлы, Исмәгыйль Рәмиевнең миңа зарланып

Сугышта ул лачындай очучы иде, Җирдә дә ул аякта нык торды...

кичкә мәктәптә укырга киңәш бирде. Надан карт булса да, миңа акыллы киңәш бирә белде ул...

Акыллы киңәшне, аек-ачык фикерне ихтирам итә белә иде Салих абый. Булачак олы шагыйрь карт көтүчене гомере буена онытмагандыр.

Әйе, чыннан да, Мәскәүгә барып, ниндидер бер заводка өйрәнчек булып урнаша ул. Анда татарлар күп була. Стена газетасы да чыгаралар икән. Шулай бервакыт Салих та, шигырь язып, стена газетасына тапшыра.

Мәскәүдә татар телендә газета-журналлар чыккан еллар. Заводка язучы Мөхмүт Максуд килә. Салихның стена газетасындагы шигырен күреп ошата да, күчереп алып, күп тиражлы газетада бастырып чыгара. Салихка исә канатлар үсеп китә. Калганнарын инде язып тормыйм, алары аның автобиографик әсәрендә бар.

Бер очрашуыбызда шагыйрь әле бүгенге ко-

әйткәнә дә бар. Ә синең бу әсәрең, Салих абый, кызыксынып укылачак әле, — дидем мин шагыйрьгә. Бу сүзләремнән соң, ул елмаеп алды. Аннары, куен кесәсеннән калын гына блокнотын чыгарып, аны өстәлгә куйды да битләре арасыннан чыккан газета кисәген миңа сузды.

— Таныштыр бу сиңа, күз салып кара әле, — диде. Ерак Көнчыгышта Ватан сугышы елларында чыгып килгән «Тревога» газетасының бер кисәге иде ул. Анда — минем «Шагыйрь Салих Баттал белән очрашу» дигән язмам. Моннан илле ел элек басылган. Мәкаләмдә Салих Батталның, хәрби крейсерга килеп, диңгезчеләр белән очрашуы хакында язылган.

Әңгәмәдәшем сабыр, дикъкатьле, үзенә генә хас бер йомшак тавыш белән сөйләшә:

— Синең диңгезче язмаларыңны укыдым әле. Анда төрле милләт кешеләре — урыс, татар, украин, белорус егетләре турында язгансың. Бер җирендә исә мордва егетен «Бик тә ялкау, йокыны үлеп ярата, дөньяга йоклар өчен генә килгәндәр», — дип әйткәнсең. Уйлап кара әле, алай язарга кирәкми, ул бит милләтләрне кимсетү була. Син аның кайсы милләт кешесе икәнлеген әйтмә. Уйла, минем әйткәнем белән килешерсең. Кайчагында автор үзенә гаебен күрми, ә укучы аны бик тиз сизә. Аннары язмаңның бер җирендә «Вак шадра дулкыннар, дип язасың да, күп тә үтми, диңгездә давыл котыра иде», — дип язып китәсең. Моны, әлбәттә, гади укучы сизмәскә дә мөмкин, ә диңгезне күргән кешене алдый алмыйсың.

Менә шундый таләпчән, турысын әйтеп бирә торган кеше иде Салих абый.

— Татар язучыларының гаиләләрендә булганга туры килгәне бар, — диде шуннан соң Салих Баттал — кемнәр икәнен әйтмим, син аларны күреп беләсең булыр, өйләрендә балалары белән гел урысча гына сөйләшәләр.

— Минем дә балалар татарча аңлыйлар аңлавын, әмма ләкин, сөйләшмиләр. Сәбәбе — балалар бакчасында ук олы туганыбыз телендә тәрбияләнеп үсәләр, — дидем мин.

— Юк, алай гына түгел, хөкүмәтнең сәясәте бу. Урыслаштыру бара, әйе, бик яхшы юл тапканнар, баланы, сабый чагыннан ук ана телен оныттырып, урыс теленә өйрәтәләр, урыс культурасын миенә сеңдереп тәрбияләү максат итеп куелган. Обком түрәләребез Мәскәү күрсәтмәләрен җиренә җиткереп үтәргә, үз тирәләренә куштан татар зыялыларын җыеп, халкыбызның яшь буынын үз милләтеннән биздерүне максат итеп куйганнар, — дип авыр сулады Салих Баттал. Ана телебез өчен, киләчәк буын язмышы өчен чын йөрәктән борчылган бер кеше иде ул.

Аның фатиры һәрчак җыйнак, чиста булды, һәрбер җиһаз үз урынында. Бер бүлмәдә — китап шкафы, кәнәфи, шифоньер. Идәнгә бик матур келәм җәелгән. Каршыдагы стенада шагыйрьнең әнисе, әтисенең зурайтылган фоторәсемнәре дә бар. Аларның астына бәллүр савытта бүген генә өзелгән бакча чәчәкләре куелган. Инде күптән вафат булган ата-анасын нинди зур хөрмәт итүен күрдем мин аның. Боларны күргәч, ирексездән, зур әдибебез Галимҗан Ибраһимовның «Бишек тирбәтә алган ана, дөньяны да селкетә ала», — дип әйтеп калдырган канатлы сүзләре исемә төште. Беркемгә дә җайлашмады — иптәшләре арасында булсын, җыелышларда булсын — һәрвакыт үзенең төп фикерен әйтеп сала торган мөхтәрәм шәхес иде Салих Баттал.

Сугышта ул очучы иде. Иҗатта ул һич тә очынмады, җир сөреп, тырышып язды. Җиргә нык басып тора белүе нәтиҗәсендә генә ул үз иҗатын саклап калды, әдәбиятыбызда урын алды.

УТ ҺӘМ БОЗ

(Әсәрдән өзек)

Михаил КАМИНСКИЙның «Чукотка күгендә» («В небе Чукотки») исемле китабында мондый юллар бар. (Автор яшьлек елларында шагыйрь белән бер авиаберләшмәдә хезмәт иткән булган).

«... Татар Салих Батталовның характеры үзенә бер төрле. Эре гәүдәле, өлегә юанаерга өлгермәгән; шулай да, тыгыз тәнле һәм яшь имән кебек нык, хәрәкәтләре саран, киң. Яссы йөзле бу кеше бик аз елмая; шуңа күрә, ул үз эченә бикләнгән булып тоела һәм аның интеллектуальлеге бик үк сизелми иде. Әмма беренче тәэсир алдаучан булып чыкты. Озакламый мин Батталовның күп укыган кеше булуына һәм без яшәгән мохиттә грамотасы ягыннан да, гомумән, югары торуына ышандым. Кайберәүләр: «Ул хикәяләр, шигырьләр язгалый икән», — дип сөйлиләр иде, әмма үзенең мактанганы һичкайчан да булмады. Шулай да, аның әдәбиятка мөнәсәбәте барлыгы дуслары белән сөйләшкәндә сизелә иде. Аны «борын күтәрә» дип әйтүчеләр булгалады. Әмма ул андый түгел иде. Биредә сәбәп башкададыр. Ул үзе турындагы фикернең ялгыш икәнлеген аңлатырга ашыкмады. Очу эшен яхшы белә һәм ярата иде.

Батталов яхшы иптәш иде. Гәрчә аның бу сыйфатына тиз генә төшенү читен булды. Ул гаиләсе булган хезмәттәшләренең берәрсе урынына якшәмбе көнне дежурга теләп рибалаша. Һәр мәсьәлә буенча һәм һәр кеше турында аның үз фикере бар. Бу фикерен ул бер кешегә дә көчләп тагарга тырышмый. Без аның салкын канлылыгын һәм ашыкмаучанлыгын үзен мохитебезгә каршы кую ысулы итеп тоя идек, һәм аның тыштан караганда юри олы сымак булып күренүе кайчакта бездә пошыну уята иде. Барыбызны гаҗәпләндереп, 1935 елда Батталов безнең бюроның конструкторы Ольга туташка өйләнде. Бу хатын үзенең кечкенә буен ташып торган энергия, кайнар темперамент һәм батыр парашютчы булуы белән тутыра иде. Группа белән биектән сикерүдә катнашып рекорд куйганнары өчен ул, башка хатын-кыз парашютчылар белән бергә, хәтта Кызыл Йолдыз орденына да алды.

Батталов белән Ольга Яковлеваның никахы боз белән утны аралаштыру кебек булды...»

● Татарстанның халык артисты Миңгол Галиевның экслибрисы (китап тамгасы). Нәҗип НӘККАШ эше.

«Кызыл Ай», кәбестә һәм башкалар

Бөтентатар «Кызыл Ай» җәмгыяте Язучылар йортында урнашкан. Аның ишеге һәркөн ачык, үтенеч ясап моң-зар белән килгәннәрне даими кабул итеп торабыз.

Бу эш белән гадәттә Миңнур апа Зыятдинова белән Фатыйма Хәбибуллина шөгыльләнә. Әмма бүген бүлмәдә мин генә калдым — алар өйдә ятучы инвалидларга ярдәм итәргә, хәлләрен белешергә киттеләр.

Менә бер хатын килде, ярдәм сорый, ике баласы да, үзе дә инвалидлар икән. Безгә беренче генә килүе түгел — исәптә тора.

— Әнә, кәбестә алыгыз, — дим мин аңа.

Кәбестә — киемнәр элгән бүлмәнең бер ягында, тартмаларга тутырылган. Хатын ул якка күз генә сала да, йөзен җыера.

— Чери башлаган бит бу! Балаларымның ашказаны да, бавыры да сау түгел, мондый азык ярамый аларга!

Аның бу сүзләре бәгыремә барып кадала. Кичә генә күпме кеше алып китте бу кәбестәне, күпмесенең өенә илтеп тапшырдык. Рәхмәт укый-укый алдылар. Әйе, болай карап торуга, өскә яфраклары бераз каралып киткән шул, саклар урыныбыз юк. Ә май башында көннәр җылы торды. Төн чыкканчы күчәннәрнең төсе бозылып куя.

— Балаларыгызга яхшы ризык кирәк булгач, бу тирәдә йөрмәгез инде сез, — дим мин бу хатынга. — Без — ачлыктан, ялангачлыктан үлем куркынычы янаган кешеләргә ярдәм итә торган оешма. Ә сезгә, Аллаһыга шөкер, андый куркыныч янамый икән әле...

Хатын каршы әйтә, мин сукранам, ә үзем кәбестәне тазартырга керешәм. Ай, бик кыйбатка төште шул бу кәбестә безгә!

Узган көзне «Татплодоовощпром» концерны җитәкчеләре белән кат-кат сөйләшергә туры килде, җыйган уңыштан фәкыйрьләргә дә өлеш чыгарыгыз, дигән үтенеч белән берничә тапкыр хатлар яздым. Минем хат өстенә: «3 тонна кәбестә, 3 тонна чөгендер бирегез», — дип яздылар да, Казаннан бик үк ерак булмаган бер совхозга барырга куштылар. Үзебезнең «Кызыл Ай» сурәте төшерелгән «ГАЗ»ик машинасына утырып, киттек теге совхозга. Директор өйдә юк иде, берәр сәгать көтәргә туры килде. Ниһаять, кайтты директор. Аллаһыга шөкер, йөрүебез бушка китмәде болай булгач. Конторына кереп барган директорның юлына аркылы төштем. Кулымда әллә ничә рәсми кәгазь, шуларны суздым, үземнең кемлегемне әйттем. Директорның чырае бик кырыс иде. Ә мин коелып төшмәскә тырышам, билгеле, мине генә көтеп тормагандыр, эше күптер, дим.

— Бушкамы? — дип сорый миннән директор.

— Әйе, фәкыйрьләргә ярдәмгә...

— Бушка бирмим. Бирдем инде... — Ул ниндидер адресларны атый, әмма аның сүзләре минем башыма керми. Инде мин коелып төштем. Болай соранып йөрүнең гарьлеге эчне яндыра, аннан да бигрәк, бензин кызганыч. Машинасы да үзебезнеке, вакытны да жәлләмибез, әмма бензин кыйбат, аны ничек юнәтергә!

Директорга да үпкәләп булмый, сораучы күптер, бөтенесенә каян җиткерсен... Борылып кайтып китәбез шулай. Тагын «Татплодоовощпром»га барабыз.

Безне Лаеш районының «Хәерби» совхозына җибәрәләр. Аның басуларында карлы яңгыр ява. Кәбестә кырына барып җитә алмыйча, сазга кереп батабыз. Без генә түгел, алданрак барган «КамАЗ» да туктап калды әнә. Арырак бер машинаны трактор сөйрәп китте, хәрби киемдәге егетләр аңа кәбестә төйи башладылар.

Күшектергеч суык, күңелсез. Алдарак тагын берничә машина тора, безгә кайчан чират җитәр. Егетләрнең эше авыр, талчыктыргыч, барысына да төйи алырлармы? Мин машинадан төшәм дә, сазга бата-бата бригадирны эзләп китәм.

— Зинһар, трактор безне юлга гына чыгарып куйсын, безгә төяп азапланмассыз инде, — дим.

Бригадир, ир уртасы кеше, миңа көлемсерәп карый, әйтерсең лә, болытлар арасыннан фәкать аның йөзенә генә кояш нуры төшә.

— Кәбестәсез беркая да китмисез, — ди. — Хәзер сезгә чиратсыз төйибез.

Һәм шулай иттеләр дә. Трактор безнең «ГАЗ»икны басу буйлап сөйрәп бара, егетләр машина әрҗәсенә даң-доң кәбестә ыргыталар, үзара көлешкән-шаярышкан тавышлар ишетелә.

Кайтканда мин, күңелем нечкәреп, безгә бүген бушлай бирелгән байлыкның нинди зур хезмәт куеп, тир түгеп булдырылганын уйлыйм. Аны ничек тә кадерләп тотарга кирәк иде, дим. Бу ике айда без инде шактый күп нәрсә өләштек: Актаныш районыннан өч тонна суган, җиде районнан тугыз тапкыр бәрәңге, Зеленодол районының «Овощевод» совхозыннан кишер алып кайтып өләштек. Кәбестә дә булды — шул ук районның «Уразлы» совхозыннан өч тонна ярым алып кайтып, мохтаҗларга бушлай бирдек. Ә алда кыш тора, һаман болай мулдан кыланып булмас.

Һәм, чыннан да, бергәләп киңәшкәннән соң, «Хәерби»дән алып кайткан кәбестәнең яртысын базага сакларга тапшырдык без. Кыш узды, яз җитте, Җиңү бәйрәменә әзерлек башланды. Ә безнең мөмкинлекләр бик чикле калды, ярдәм өмет итеп килгән кешеләрне куандырырлык хәлебез юк. Әле дә ярый, теге кәбестәне саклаганбыз. Дөрес, базадагы склад мөдире бездән көлде: «Сезнең ул кәбестәгезнең яртысы да калмаган инде, череп беткән», — диде. Әмма бу якын итеп шаярту гына иде — кәбестәне күпме салсак, шул хәтле итеп кайтарып бирделәр. Чистартып, ап-ак итеп. Рәхмәт төшкерләре!

Шул кәбестәнең өсте бездә каралып ята менә. Дөрес, ул аз калган, шулай да кызганыч. Мин аны чистартам, сөрткәлим, тизрәк өләшеп бетерергә кирәк, дип үрсәләнәм, ә теге хатын колак төбемдә мырылдый:

— Инвалид дигәч тә, черек-чорык ашатырга телисезме? — ди. — Безнең балалар да кеше ләбаса!

«Түз, күңелем, түз, — дим үземә. — Сабыр бул!» дим.

— Башка әйберебез юк шул, — дидем теге хатынга. — Әнә, теләсәгез өс киемнәре, аяк киемнәре бар. Сайлап алыгыз.

Элгечләргә ымлыйм. Анда кешеләр китергән күлмәк, пальто, костюмнар эленеп тора. Комиссия кибетендәге кебек. Хатын киштәләргә таба юнәлә, ә мин икенче бүлмәгә керәм.

— Исәнмесез! — ди бер ир кеше тавышы. Тулган ай кебек балкып, ишек төбендә берәү басып тора. — Ә мин сезгә бүләк китердем!

Зеленодол шәһәреннән бу кеше безгә килгәләп йөри. Тугыз баласы бар, өлкән кызы унөч яшьтә, хатыны бала карап өйдә утыра, үзенә хезмәт хакын ике-өч ай инде түләмиләр. Бу юлы да гадәтенчә бәләкәй арба белән килгән. Хатыны безгә рәхмәт йөзеннән башмаклар чигеп җибәргән.

— Шул хәтле бала белән ничек өлгергән? — дим, гаҗәпләнеп.

— Сезнең өчен бөтенесен эшләргә була, — ди ир кеше. «Ә безнең бирерлек рәтле әйберебез юк!» — дип уйлыйм мин уфтанып. Кыенсынып кына теге кәбестәне күрсәтәм.

— Бик яхшы бит бу! — ди ир кеше. — Өстен юып җибәрәбез дә тозлап куябыз без аны! Менә шәп була!

Арбага кәбестә тутырабыз. Арба эчендә капчык та бар икән, аңа ярмалар салабыз — елга портының элеваторы хәер итеп берничә төрле ярма биргән иде, колхозлардан килгән борчак та ярап куя — арыш капчыгы тула диярлек. Аннары икәүләп кием-салым сайлыйбыз.

— Болай булгач яшәрбез! — дип куана өти кеше. Мин дә аны шатланып озатып калам.

Ул арада теге хатын минем янга килә.

— Менә, ике кием туфли сайладым, аягыма юк иде, — ди. Ә туфлие кызыгырлык. Бая әйткәләшкәнне онытам, капчык төбеннән солы ярмасы табыла: бу хатынның инвалид балалары да өлешсез калмый.

Вахитов районының социаль ярдәм бүлегеннән өч-дүрт хатын-кыз килеп керә.

— Кая, кәбестәгез бармыни? Кәбестә хәзер беркайда да юк бит! Искесе беткән, яңасы килеп җитмәгән. Үзебезнең ялгыз әби-бабайларны сөендерик әле, — дип, калган кәбестәне сумкаларына тутырып, алып та китәләр.

Миңнур апа белән Фатыйма кайтып җиткәнче, кәбестә кыйссасы тәмамланып куя.

— Моннан ары мине ялгыз калдырмагыз, — дим аларга. — Килгән-киткәнне үзегез кабул итегез.

Ә миңа, җиң сызганып, үз эшемне эшләргә кирәк: оешмаларга барырга, машиналарны ремонтлатырга, бензин юнәтергә, инвалид арбалары артыннан йөрергә, хәйрия ашханәсе ачуны тизләтергә...

Мин ике сәгать эчендә кеше кабул иткәнемне генә сөйләдем. Әмма безгә меңнәр килә, бик күбесе рәхмәтләр укып китә. Без исә шуны яхшы беләбез — бу рәхмәт сүзләре иң беренче чиратта башкаларга: үзләренең авыр хезмәте җимешеннән өлеш чыгарган авыл кешеләренә; безнең оешмага машиналар, аларга ягулык биргән җитәкчеләргә; шушы эшкә бүлмәсен, кием элү урынын түләүсез биргән, бәрәңгене, яшелчәне коридорга бушатып, шуннан өләшергә рөхсәт иткән Язучылар берлеге җитәкчеләренә; безгә кием-салым китерүчеләргә; үзләреннән арткан урын-җир әйберләрен безгә тапшыручы кунакханә хуҗаларына, тагын бик күп кешеләргә әйтелергә тиеш. Без шул изге күңелле кешеләр белән мохтаҗлар арасында арадашчы гына бит.

Безнең оешмабыз эшли башлаганга ике ел тулды. Һәммәбез күреп тора: заманалар авыр, юллар ябык. Каты күңелле, сытык чырайлы адәмнәр күп, дибез. Алда тагын ниләр күрербез икән, дип зарланышабыз.

Минем исә алдагы көннәргә өметем үсә бара. Чөнки һәркөн яхшы кешеләр белән очрашам. Эче тулы нур аларның, йөзләрендә — миһербан яктысы.

Әгәр дә бу эштә эшләмәгән булсам, яхшы кешеләрнең бу хәтле күплеген белмәс тә идем, бәлки.

Мәдинә МАЛИКОВА,
Бөтентатар «Кызыл Ай» җәмгыяте президенты, язучы.

Кол Галинең Татарстан китап нәшриятында чыгачак «Йосыф китабы»на Рушан Шәмсетдинов ясаган рәсемнәр.
- **Йосыф патшасы тәхеттә.**
- **Зөләйханең фәрештәләр белән очрашуы.**

УНӨЧЕНЧЕ БИТ

Радик ФӘИЗОВ

ХАЛЫК ДОШМАНЫ

Хикәя

Әллә мәҗлес, әллә җыелыш иде бу. Һәрхәлдә, егетләр-кызлар җыйнал[ган] урын. Хәзерге заманда мон[дый] җирдә сәясәтсез, бәхәссез [бу]ламы соң инде ул?! Монда да [б]ерсеннән-берсе үткер, зирәк фи[к]ерләр әйтелде, ярсулы, ачулы, [р]өнҗүле сүзләр сөйләнде. Капчы[г]ы-капчыгы белән, авыздан төке[р]екләрне чәчеп. Әлбәттә инде, ха[л]ыклар атасы Сталинны һәм аның [м]иллионлаган корбаннарын да [к]аберләреннән күтәреп алдылар. [Ш]унда инде мин дә түзмәдем. Үзе[м]чә бик акыллы, ярсулы сүзләр [с]өйләп ташладым.

— Һи, ул замандагы яшьләр, [к]омсомоллар... Шыр дурак бул[г]аннар бит алар! Мәми авыз бул[г]аннар. Соң шул Сталинга үзләрен [г]аепләргә, аннары халык дошма[н]ы ярлыгы белән чыгарып атарга [ю]л куеп торганнар бит. Шул өч [к]ласс белемле бер грузинга! —дидем мин. — Их, шул вакытта [м]ин булсам. Күрсәтер идем ул [җ]әлладларга кемнең халык до[ш]маны икәнен. Үз өстемә нахак [б]әла алып торыр идемме? Үзлә[р]енең халык дошманы икәнен ис[б]атлап бирер идем мин аларга. [Х]ет Сталинның үзенә!

[Ш]ярый, бетте бу җыелыш. Кай[т]ып киттем мин өйгә. Кичке кара[ң]гы урамнардан ялгызым гына ба[р]ганда күңелгә шик керде. Әллә [н]инди шом, куркыну кебек нәрсә [ш]унда... Әле өйгә кайтып урынга [я]ткач та тынычлана алмадым. Әл[л]ә ниләр уйланып, йокылы-уяулы [я]килеш ятам...

...Менә мин тагын караңгы, сал[к]ын, шыксыз урамда. Туңа-калты[р]ана өйгә ашыгам. Кинәт каршым[д]а ике «күләгә» калыкты. Икесе [д]ә кап-кара күн киемнән, икесе[н]ең дә билләрендә алтатар. Ки[л]еп тә чыктылар, үземне ике як[т]ан култыклап та алдылар. Сел[к]енеп тә булмый.

— Гражданин Саттаров! — диде аларның берсе.

— Әйе, мин Саттаров! Ә сезгә миннән ни кирәк? Бу ниткән башбаштаклык тагын? — дип кычкырып җибәрдем мин.

— Акрын, контра! Хезмәт ияләре йоклый. Ә безгә ни кирәк икәнен тиешле урынга баргач белерсең. Бик яхшы итеп аңлатырбыз без сиңа аны... — диде аларның икенчесе янаулы итеп.

Шунда мин имәнеп киттем. Урам чатында, гаять зур кара аюдай бөкреп, өсте ябулы кара машина тора иде. Мине, артыма берне тибеп, шул машинага ябып куйдылар. Күз ачып йомганчы.Тәмам аптырап, югалып, шашынып калдым. Нәрсә бу, өнемме,төшемме? Ул арада машина каядыр килеп тә туктады. Мине шакылдап торган таш баскычлардан каядыр түбәнгә алып төштеләр. Шагырдап тимер ишек ачылды. Иркен, яп-якты бүлмә, озынча тар өстәл, ике урындык. Мине өстәл янына утырттылар. Каршыма күн киемле, йөзенә кара бөрчекләр төшкән бер бәндә утырды.

— Хәзер инде сез гражданин Саттаров түгел! — диде ул агачтай коры, битараф тавыш белән. — Сез контра, троцкий-зиновьевчыларның партиягә каршы блогы әгъзасы. Сез — халык дошманы!

— Ни сөйлисез сез, иптәш начальник? Бу бит хәзерге заман. Сезнең ул Троцкий-Зиновьевларыгызны без китаплардан гына укып беләбез. Хәзер бит бөтенләй икенче төрле сәясәт. Мин нинди халык дошманы була алам инде?! — дип көлеп җибәрдем мин.

Моңа каршы күн киемле бәндә тар өстәл аша үрелде дә, минем йөземә сугып җибәрде. Шундый итеп сукты, күздән яшел утлар күренде. Эшнең һич тә уен түгел икәнен төшенеп, минем котым алынды. Әйтерсең, күн кием минем рухымны бәреп сындырды.

— Иптәш түгел мин сиңа, көчек! Ә гражданин начальник. Син — халык дошманы. Менә гаепләү акты. Шуңа хәзер үк кул куй. Мин халык дошманы, дип кул куй!

— Мин берни белмим... Мин халык дошманы түгел... — дип шыңшыдым мин.

— Син — халык дошманы. Куй имзаңны! — дип кабатлады күн кием, миңа сугарга дип кизәнде һәм... урыныннан сикереп торды да катып калды. Мин ишек ягына карадым һәм үзем дә нәкъ күн кием кебек үк сикереп тордым. Ишектән... Иосиф Виссарионович Сталин үзе килеп керде! Юлбашчы үзе! Өстендә теге рәсемнәрдәге кебек киң якалы пинҗәге, аякларында йомшак итекләр, авызында тәрәпкә. Ул, вәкарь белән атлап, өстәл янына килде, безгә утырырга рөхсәт иткәндәй ишарә ясады. Беraз шадра төшкән йөзендә, күзләрендә аталарча җылылык сирпелеп тора, үзе купшы мыеклары астыннан ягымлы елмая. Менә ул тәрәпкәсен, авызыннан алып, өстәлгә какты.

— Тә-өк! — диде юлбашчы, һаман да ягымлы елмая биреп. — Теге калай әтәч шушы буламы инде? Минем үземә дә кем икәнемне әйтеп бирәсе батыр.

— Нәкъ үзе, иптәш Сталин! — диде күн кием.

— Димәк, сез үзегезнең троцкий-зиновьевчы икәнегезне бездән яшерәсез, үскәнем. Димәк, сез халык дошманы түгел? — диде Сталин үзенең йомшак тавышы белән. Миңа текәлеп каравыннан аркаларым өшеп китте. Юлбашчының күзләрендә яшел чаткылар уйный иде. Үземне ниндидер коточкыч йөк, тау астында калгандай хис иттем.

— Иптәш Сталин! Безнең даһи юлбашчыбыз! — дидем мин аның аягындагы итеген кочып алырдай дәрәҗәгә җитеп. — Мин... юк! Мин троцкийчы түгел...

— Ну, чту же, — диде юлбашчы фәлсәфәчеләрчә. — Юкка — җавап та юк. Җавап булмагач, кеше үзе дә юк. Ә кеше үзе булмагач, бернинди проблема да калмый. Әгәр үзегезнең халык дошманы икәнегезне танымыйсыз икән, без сезне хәзер үк юк итәбез!

Һәм Сталин, кулын күтәреп, бармагын шартлатты. Ишектә икенче күн кием күренде. Аның кулында хәзерге Калашников автоматы чаклы алтатар иде.

— Кирәкми! Иптәш Сталин... Зинһар мине исән калдырыгыз. Мин — дошман. Мин — халык дошманы! — дип кычкырып җибәрдем мин.

...Шунда кемдер үзенең йомшак, шәфкатьле кулы белән маңгаемнан сыйпады. Күземне ачып җибәрсәм, караваТ янында әни басып тора. Ә мин тиргә батып, саташып ятам икән.

— Икенче ягыңа борылып ят, улым! Саташасың. «Мин — халык дошманы», дип, әллә ниләр сөйләнәсең...

Әнинең сүзләреннән соң, тәмам айнып киттем. Икенче ягыма борылып яткач, ниндидер әчке батыраю белән уйлап куйдым: «Фу, черт! Төш кенә булган икән. Әгәр өндә булсамы? Күрсәтер идем мин ул Сталинга кем икәнлеген!..»

Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

Чит ил матбугатыннан.

Акча янчыгы

Хуҗа Насретдин, автомобиль ...стьларын белергә теләп, зур бу...аган кара тартманың нәрсә ...ен сорагач, улы: «Аккумуля...р ул, әти, анда электр энергиясе туплана, ә ул энергия машинаны кабызып җибәрә дә, йөртә башлый», — дип аңлаткан. Моны тыңлаган Хуҗа: «Белдем, улым, белдем. Без синең белән икәү эшләп, әниеңә акча кайтарып бирәбез дә, ул сәгате-минуты белән базарга һәм кибетләргә чыгып йөгерә. Бу аккамилөтер дә шул әниеңнең акча янчыгы сыман бер нәрсә икән инде», — диген.

Киреләнгән чакта

Хуҗа шоферлыкка имтихан тота икән. Аңа: «Автомобильнең куәте нинди берәмлек белән үлчәнә?» — дигән сорау бирелгән.

— Ат һәм ишәк көче белән, — диген Хуҗа.

Җавапның дөреслегенә шикләнеп, комиссия әгъзалары аңлатыбрак сөйләргә кушканнар.

— Аны аңлатып торасы юк инде. Йөрген чакта ат көче белән үлчиләр, ә инде ватылып паркта тәзәткән чагында ишәк кирелеге белән үлчәсәң дә таманга туры килә, — дип җавап биргән Хуҗа.

Юморны аңлар өчен

— Сез минем бабамны алдагансыз, — диген күрше егете Хуҗа Насретдинга. — Моннан илле ел элек аңардан таба алгансыз да, ватканс‌ыз. Аннары, балаладЫ, дип, кертеп биргәнсез. Бабайлар надан булганнар, көлеп кенә куйганнар. Мине инде алдый алмассыз. Авиация институтын бетердем. Таба да, самолет та балалаамый...

— Аңладым, улым, — дип бүлдерген аны Хуҗа. — Белем алуың бик әйбәт булган аныСы. Тик менә, табаның балалый алуын белү өчен, сиңа тагын бер институт бетерергә кирәк түгелме икән? — диген.

Шагыйрь Хәниф ХӘСНУЛЛИН тупламасыннан.

Хикәят

(Каюм Насыйридан)

Бер көн бер патша бәгъзе кешеләре белән һава суларга чыккан иде. Бер җирдә, кешеләреннән аерылып, ялгыз калды. Шунда бер карт очрады. Ул картка әйтте: «И бабай, син кайдагы?» — диде. Карт: «Мин шул шәһәрдән», — диде. Патша әйтте: «Бу шәһәрнең хакимнәре ничек?» Карт әйтте: «Хакимнәребез бик кирәкмәгән усал, залим кешеләр», — диде. Патша әйтте: «Патша хакында ни әйтәсең?» — диде. Карт әйтте: «Шәһәребездә монының кебек кабахәт залим патша булганы юк иде, золымы белән көйдерде шәһәрне», — диде. Патша әйтте: «Мине таныймсың, мин кем?» — диде. Карт әйтте: «Юк, танымыйм, син кем?» — диде. Патша әйтте: «Бу шәһәрнең патшасы булырмын», — диде. Карт әйтте: «Мин кем, син мине таныймсың?» Патша әйтте: «Юк, танымыйм, гавам әчендәге халыкны кайдан танып бетерәсең», — диде. Карт әйтте: «Мин фәлән угылы фәлән мәҗнүн, кон саен ике мәртәбә шулай юләрләнеп саташып йөримен», — диде. Патша колде дә китте.

Мәгъсүм ХУҖИН

Хикәяләр

Ах-х, замана...

ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ:

Шактый санда хикәяләр язганмын икән фәләнчә-ә-ә еллар дәвамында. Шулай — хикәя язып көн күрергә тырышам мин. Һәм, шөкер, көнне күрәм, чөнки һәр ак таңда — төнне көн алыштырганда — шөкер, тәпи баскан булам.
АВТОР.

Дулкыннар талгын киерелеп уяналар. Болынны убып казылган тирән казан-чоңгыл төбенә яшеренеп йоклаганнар икән алар — Казансуның иркә дулкыннары. Тиздән алар җемелдәп йөгерешерләр, уйнаклап матавыкланырлар — юк, дулкыннар матавыкланмыйлар, алайса, котырынып сикерешерләр — монысы ихтимал. Әмма бүгенгә чырай бозып дуамалланмасыннар алар, сабыйларча онытылып уйнасыннар гына иде. Бүгенгә? Ә бүген ни көтелә соң — дулкыннарны алай тыярлык нинди сөенеч көтелә? Көтелми. Көн гадәти башланды, аз-маз мәшәкатьләре һәм иләнелгән ыгы-зыгылары белән гадәти узып та китәр ул...

Саяф язгы ташудан соң тонар-тонмас Казансу өстеннән шушы уйларны укыды. Юк, укымады, ә язды. Юк, язмады, ә йөгерек дулкыннарга әйтеп яздырды.

Саяф, уйланып та, ара-тирә онытылып та, суга озак карап утырды — моңарчы беленмәгән, бәлки, беркайчан да ачылмаячак серләр күп икән елга өстендә. Егет мавыктыргыч табышмакларны чишәргә җыенмый, сихриләкләрен җуймыйча кала бирсеннәр алар. Аңа су өстенә карап утыру хаҗәт. Шунысы җитә.

Ул, хәрәкәтсез утырудан гәүдәсе оеша башлагач, иртәнге дулкыннарга охшатып акрын гына киерелмәкче иде дә, җыелма урындыгының сулъяк аяклары комга тирәнрәк батты, һәм Саяф әле күперенергә өлгермәгән ком-мендәргә ауды. Шул вакытта аның яныннан ук кыз узды. Туташның килүен сизмәгән иде ул — комда аяк тавышы ишетелми ич. Өстәвенә кыз яланаяк икән.

«Яланаяк? — дип сискәнде Саяф. — Салкын тидерә ич! Ком кызынырлык булып җылынмаган әле. — Ул җәһәт торды. — Әй, чыныккан җандыр, кышын да су коенып йөрүчедер».

Саяф кыз киткән якка карамады, урындыгын көйләп утырды — су буенда кем йөрмәс, һәркайсына игътибар итә башласаң, күзең талыр, бу кыз әмма ки таңнан кузгалган.

«Күргәнем бар түгелме соң минем бу... халыкны?» — дип уйлады Саяф. Тик бөяләве кызны мыскыллау булып тоелды да үзалдына:

— Бу кызны, — дип әйтеп куйды.

Шуннан соң гына кыз ягына борылып карады. Ә кыз аңардан ун адымнар чамасында гына туктаган, оешып-бөрешеп чүгәләгән, Казансуга текәлгән иде. Яланбаш та икән ул, иңе тиңентен генә чәчләре тузгыган кебек, әллә үзе күперткәнме — аермассың хәзерге моданы. Өстенә дә яшел борчак бизәкле юка күлмәк кенә кигән. Саяф яныннан узганда, ул таза һәм олы гәүдәле кебек иде, хәзер кечкенә йомгакка охшап калган, буш чорналган, сүтелергә-чуалырга җиткән йомгак кебек.

«Күргәнем бар ич минем аны...»

Һәм Саяф тагын борылып карады.

Кыз аягүрә басты, күлмәгенең ян кесәләрен капшады. Күлмәген ашыкмыйча салды, аны, кесәләрен эчтә калдырып, пөхтәләп төрде, ян-ягына каранды да (башка әйберсе юклыгын абайлады бугай), баскан төшеннән кузгалмыйча, аяклары артына ук куйды. Аннары гәүдәсен тагын турайтты. Эчке күлмәген изүеннән як-якка тарткалады, аның читен чәйнәргә тотынды.

Саяф шул чакта гына куркыныч хәл буласын сизенде. Ул кызга таба йөгереп китә алмады — аяклары оеган икән. Кинәт кызның фамилиясе хәтеренә келт итеп төште.

— Әбҗәлимова! Туктагыз! Су салкын...

Кыз башын аңа таба вәкарь белән генә борды. Аның күзләрендәге зәһәрлекне, котырынганлыкны Саяф, күреп җиткермәсә дә, күңеле белән тойды.

Әбҗәлимова эчке күлмәген гәүдәсен-башын имичә җәһәт салды да суга селтәп ыргытты. Шыр ялангач калды ул. Тик баскан төшеннән кузгалмады.

— Туктагыз!..

Кызның исеме дә Саяфның хәтеренә келт итеп төште.

— Нишләвегез бу?! Фәрхунә...

Кыз, Саяф йөгереп килеп эләктерергә өлгергәнче, аз гына чүгәләде дә атылып суга сикерде. Гәүдәсе, ярдан суга очканда, ана карынында яткан баланыкы сыман иде... Саяф, киемнәрен дә салмыйча, Фәрхунә артыннан аяклары белән суга сикерде һәм кыз чумган урынның янәшәсенә үк диярлек барып төште. Ни хикмәттер — Фәрхунә йөзтүбән, аның башы әйләнәсендә күбекләр быгырдый — Казансуның кызны төпкә тартасы килми кебек. Саяф аның чәчләрен сул кулы белән кысып учлады, кызны ярга таба сөйрәп йөзде. Уң кулы төпкә тигәч, Фәрхунәне, култыкларыннан эләктереп, күтәреп чыкты. Кыз карышмады, аягына баскач, Саяфка күкрәге белән сыенды, аякларының хәле бетә бардымы — ул акрын гына сыгыла башлады. Саяф аны дерелдәтеп туры бастырды да яңагына чалтыратып җибәрде.

— Юләр!

Фәрхунә башын салмак кына күтәрде, аның күзләре аларган иде. Кыз Саяфның суга чыланып болай да начар күрсәтүче күзлеген ике куллап умырып алды, аны суга ыргытты.

— Аңгыра!! — Саяф Фәрхунәне көч белән этеп җибәрде, кыз күлмәге өстенә егылды. — Шыр тиле икәнсез. Сез бит минем күзлексез сукыр хәлендә калуымны беләсез... Киенегез!

Бу хәлләр — Фәрхунәнең суга сикерүе белән Саяфның кызны этеп егуы — бик тиз арада булды.

Егет киемнәрен сыгып киде, ә кыз күлмәге өстендә бөрешеп утыра бирә иде.

— Киенегез тизрәк! — дип кабатлады Саяф. — Оятны качты хәзер кызларның, шәрәтән йөрүгә күчтеләр. Ах, замана...

— Болайга карама...

— Карасам да, берни күрмим. Сез мине хәтерләмисез икән... Сезгә дәваланырга баргач, миңа, су өстенә карап утырудан файдалысы булмас, дигән идегез. Менә мин икенче ел инде сезнең киңәшне тотам. Файдасы бар кебек, һәрхәлдә сукыраю тыелып тора. Ә сез... мине күзлексез дә калдырдыгыз. Табибә ич сез — адәмгә, бер генә җан иясенә дә начарлык кылмаска тиешсез...

— Кылмаска, имеш! — дип тешләрен шыгырдатты Фәрхунә. — Башкалар мине туйганчы изсен... вәхшиләрчә көчләсен... мин... мин кул куушырып торыйммы?! Ю-ук инде! — Фәрхунә күлмәген киеп өлгергән иде, ул, сикереп торып, йодрыкларын уйната-болгый, Саяфка ташланды, аның күкрәгенә төяргә тотынды. Егет аның ике кулын да беләзекләреннән бергә эләктерде.

— Әбҗәлимова! Фәрхунә! Кайтыгыз сез, тынычланырга кирәк сезгә.

— Тынычланырга, имеш! Тынычланырсың... кызлыгыңны алгач... Үз өемдә бит... Башлап үз энем... аннары ике иптәше... Менә ул — замана!.. Мин суга батырга теләдем... Соңгы хатым кесәмдә... Нигә коткардың мине?!. Нигә...

Кыз Саяфның күкрәгенә тешләмәкче булды, әмма егет аны этәреп өлгерде, тик Фәрхунә аның кулына тешләре белән кадалды. Саяф дөү кулы белән кызның ботын кысты, сөякләре шытырдашты кебек хәтта.

— Ай-й! Авырта-а... — дип җан ачысына кычкырды кыз.

— Минем ни гаебем...

— Гаепле! Заманның ямьсезлегенә сез — ирләр гаепле... ай-й... Җибәр...

Саяф эндәшмәде, тешләрен шыгырдатып, бармакларын Фәрхунәнең ботына ныграк батырды. Кыз шыңшып җибәрде, кычкырып көлде, кинәт аяклары сыгылды, егет аны язгы комга яны белән яткырды, әмма кулларын ычкындырмады. Бераздан Фәрхунә:

— Җибәр инде... — дип тыныч кына әйтте. Аның котырыну көче беткән иде. — Җибәрә күр... Мин тимим сиңа... Мин тынычландым... Исемең ничек?..

— Хәтерең бармы?

Егет исемен әйтте һәм аны кыздан кабатлатты.

— Хәтерләрмен...

Иң кадерле әйберсе күзлек иде Саяфның. Маяга өч күзлек ясатып куйган иде ул. Өенә кайтуга ук шуның берсен өстәл тартмасыннан алып киде. Пыяласын карага манганы туры килде.

Иртәгесен Саяф Казансу буена гадәтләнгән вакытында барып утырды.

... Дулкыннар талгын киерелеп уяналар иде...

Аның яныннан ук кыз узды. Фәрхунә. Яланаяк түгел. Спорт чалбары кигән. Саяф аңа күтәрелеп карамады. Кыз, кире борылып, үзе килде. Саяф янына, тартмасын ачып, күзлек куйды.

— Рецептыңны табып ясаттым, — диде ул. — Саклаңган икән... Күзлекне ясатып була...

Саяф эндәшмәде.

— Ачуланма... Мин дә гаепсез бит...

Саяф эндәшмәде.

— Мин китимме?

Саяф эндәшмәде.

— Мин янәшәңдә утырыйммы?

Саяф эндәшмәде.

Шактый вакыт узгач кына, Саяф:

— Ах-х, замана... — дип тирән сулады.

Фәрхунә китәргә кузгалды.

... Казансу буенда боз катканчы һәр иртәдә ике кеше күренде. Берсе, уйланып та, ара-тирә онытылып та, су өстенә карап утыра. Ул йөгерек дулкыннарга нидер әйтеп яздыра кебек. Икенчесе, яр буйлап, карашын аяклары очларыннан алмыйча, салмак адымнары белән әрле-бирле йөренә. Ул күперенкә комга аяк очлары белән, ялгыш җибәрмәскә тырышып, нидер яза кебек.

Аларның, Казансу тонар-тонмас чактагы очрашуларыннан соң, сүз алышканнары юк.

1994.

Бер елда ике җәй булмый

Урам әйләнә егетләр...

Онытылган бу гадәтне яңарту кайсысының башына килде икән...

Биктимер булыр. Урам әйләнүне Дәлиягә ачу итеп башлагандыр ул. Дәлиянең сызган, боеккан йөрәген телемнәргә телгәләргә телидер. Дәлияне кара хәсрәт дәрьясына акрынлап батырудан җанына ләззәт табадыр...

Дәлия кече якка чыкты. Ут кабызмады. Тәрәзә кашагасының читен күтәрде. Егетләр Дәлияләр турысыннан узә иде. Гармунда Биктимер уйный. Ул бу кырыйда — әйбәт үк күрә аны Дәлия. Ай яктысы җитә булмаса да, Биктимерне аерыр иде ул, егетнең буе ук, менә мин, дип кычкырып тора ич — бүтәннәрдән бер башка озынрак Дәлиянең егете. Хәер, Биктимер аның сөйгәне түгел инде хәзер. Монысы да хаталанудыр, дөресе — Дәлия Биктимернең сөйгәне-сөеклесе түгелдер. Түгел...

Гармунчы үзе үк җыр башлады. Дәлиянең йөрәккәе вак-вак кисәкләргә турала иде, ахрысы. Шул газапланучы кыйпылчыкларны кабат бөтәйтеп җырга көч табылырмы?

Биктимер белән Дәлиянең арасы беркайчан да бозылмас кебек иде. Аларның бергәләп гаилә корачакларына шикләнүче булмады авылда. Егет армиядә хезмәт итеп кайтты, туй озак көттермәс кебек иде. Ләкин мәхәббәт кинәттән чәлпәрәмә килде.

Биктимер армиядә шәһәр егете Ирхәт белән бергә хезмәт итте. Авыл сабан туена, ике иптәшен ияртеп, шул Ирхәт яңа «Жигули»да кайтып төште.

— Бикти, сәлам үзеңә! — дип тәкәллефсез исәнләште Ирхәт. — Авыл сабан туе күрәсе килде дә, җыендык та чыгып киттек менә. Безнең сыйлар үзебез белән, барыбызга да җитәрлек.

Биктимер шәһәр егетләрен киң күңел белән каршылады, кунакларның төрледән-төрле шешәләренең берсен дә ачтырмады. Сабан туена, кунаклар кыбырсыса да, хәмер алып төшертмәде.

— Нишлисең, кунак — хуҗаның ишәге, — дип, кулларын җәеп, хокуксызлыгыннан мескенләнде Ирхәт.

— Әнә, табынны әни көнә буена әзер тота, — дип боргаланырга урын калдырмады Биктимер. — Мәйданнан менгәч, ачы бал белән сыйланырбыз. Сабан туена гына бал шундый булып әчи, Ирхәт!

— Нинди булып!

— Татып карагач, үзең бәяләрсең.

Сабан туе башланганчы, шәһәр егетләрен Биктимер дус-ишләре, үз әйләнәсе кызлар белән таныштырды. Ирхәт, Дәлия белән күрешкәндә, аңа шар күзләрен уйнаклатып карады, кызның кулын ныгытып кысты, әмма тәрләсән эшләп үскән Дәлиянең көчле кулын шәһәр тумасының сыек куәте чытырдата алмады. Ә Ирхәтнең сул кулы белән Дәлиянең тәрсәгенә кагылуы базарда малны капшап карау кебек тоелды.

Егетләр Биктимерләрдә

тон уртасынача сыйландылар, сабан туе балы аларны җиңелчә салмыш хәлдә тотты. Хәер, исерешмәүдә хуҗа егетнең мәҗлесне хәмергә кормавы да сәбәп иде. Ә машина йөртүче — төбәнәк буйлы, аз сүзле егет — өчегән балны ирененә дә тидермәде генә түгел, аңа кырын күзен дә төшермәде. Иртән юлга чыкканчы, исә дә, сөреме дә бәтәр, дип Ирхәт кыстый башлагач, машинасын карап керүне сылтау итеп, табын яныннан кузгалды. Ирхәт урамга чыгып йөрергә кат-кат тәкъдим итсә дә, Биктимер аңа беренче әйтүендә үк:

— Авыл салмыш хәлдә йөрүне өнәми, — дип кырт кисте, кабатлауларын исә колаклары яныннан уздырды.

Кунак-сый мәшәкате белән мәшгуль булып, Биктимер сабан туе кичендә сөйгәне Дәлия белән очрашмады. Ә мәҗлескә кызлар заты чакырылмаган иде. Ирхәт:

— Кызларсыз мәҗлес буламыни?! — дип кыбырсыса да, Биктимер:

— Була, — дип кенә куйды һәм, тукталып торгач: — Безнең тилелекләрне, күрмәсәләр дә, беләләрдер әле, — дип өстәде.

Аның йортында авыл гадәт-йоласын нык тоталар, шуңа күрә мондый кырт сүзләре шәһәр егетләре килүенә тар күңелләленүдән түгел иде.

... Дәлия авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укырга теләвен әйткәч, Биктимер, кашларын сикертеп, башын янтайтты да:

— Хуплыйм, — диде. Кызның кулларын учларына алды һәм: — Галимә булгач та, мине... иш итәрсең, яме, — дип шаяртты.

Дәлия моңа сүз белән җавап кайтармады, кулларын Биктимернең учларыннан чыгарып, егетенең кашларыннан сыйпады, сөйгәненең йомшак кына әйтелгән таләбенә вәгъдә билгесе идедер аның бу хәрәкәте.

— Кем булырга инде?

— Икътисад бүлегенә. Үз эшем буенча, — диде кыз. Ул колхозда шул эшләрне алып бара иде. — Белемсез авыр. Гаилә корылгач та, бу хезмәтемне ташларга исәбем юк. — Өйләнешү турында төгәен сөйләшү булмаса да, Дәлия моның хәл ителгән мәсьәлә икәнлегенә ышана иде. — Син, Биктимер, ихластан хуплыйсыңмы?

— Минем кайчан бер нәрсәне уйлап, бүтәнне сөйләгәнем бар?!. Тик мин, Дәлия, урта белемем белән калырмындыр. Түргә үрмәләү, башкаларга әмер бирү минем холыкта түгел.

— Минем дә укырга теләвем түрәлеккә омтылудан түгел лә инде.

— Синең һөнәрең бүтән, укымыйча ярамый. Миңа шофер булу бик ошый, машинаны тыңлатсам, шул бик тә җиткән. Кем әйтмешли, эчмим, тәмәке тартам тартуын. Исән-имин юл йөрергә язсын.

— Көн буена сине күрә дә алмассың икән. Әй лә, сагынуы үк рәхәт булыр әле.

Алар, олы урамнан барып, басу капкасына җиттеләр. Кемдер капканы ачык калдырган икән, Биктимер шуны япты, Дәлиядән читтә сигарет кабызып тартты, кыз аны ашыктырмыйча көтте. Аннары кайту уңаена кузгалдылар.

... Дәлия институттан йөгереп диярлек чыкты. Кайсы якка китәргә белмичә аптырап торды. Шатлыгы зур иде аның — студент итеп алдылар аны, моны ишеткәч, Биктимер сөенер дә соң инде... Кыз, институтның мәһабәт бинасына сокланып, аны буйдан-буйга күздән кичердә дә, Ирек мәйданына таба китте. Сөенечле уйларына чумган иде ул. Машина юлы кырыеннан ук бара икән, янәшәсендә үк кара машина кычкыртты — «Тойота» бугай, хәзер аларның төрләрен аерып бетермәләме соң. Дәлия читкә тайпылды. Ләкин машина тагын кычкыртты, арткы ишек ачылды, аннан берәү чыга башлады. Аның башы иелә төшкән булгач, йөзе күренеп җитмәде. Машинадан төшүче тураеп баскач, кыз гаҗәпсенеп калды. Дәлия каршында Ирхәт басып тора иде. Инәдән-җептән генә чыккан киемнәрдән Ирхәт, яман да фырт кыяфәте бөркелеп тора.

— Борын чөелгән синең, Дәлия, — дип кул сузып күреште Ирхәт. — Танымаган буласың, әй.

Егет, авылда күрешкәндәгечә, Дәлиянең терсәгенә кагылды, беренче тәэсир кабатланды — базар малының көрлеген чамалап капшаган кебек иде шәһәрнең тәкәллефсез егете. Кыз терсәген кырт тартып алды. Ирхәт моны сизмәгәнгә салышты, шулай да, яшен тизлегә белән, кулын Дәлиянең җилкәсеннән шудырып өлгерде, югалып калмады, сүзен әдәпсезлеген йомуга борды. — — Исән-сау яшисеңме? — диде.

— Әйбәт. Менә... — дип башлаган иде дә Дәлия, ләкин институтка читтән торып укырга керүен беренче булып Ирхәткә әйтергә теләмәде. — Шәһәр үзеген өйләнәсе иттем әле.

— Әйдә, машинага утырып өйлән. — Кыз, Ирхәтнең рульдә түгеллегенә һәм машина

йөртүченең авылга «Жигули»да кайткан егет булмавына игътибар итеп, аның үзен хуҗаларча тотуына гаҗәпсенде. Моны шәһәрнең җитез егете тиз сизде.

— Борчылма, машина минеке. Эшкә барышым.

— Шулай соңмы? Төш җитә ич инде.

— Бездә секунд-минутларны тикшермиләр, станок көтеп тормый, — диде Ирхәт һәм Дәлияне, инде терсәгеннән кысып тотып, машинага утыртты.

Казансу күперен чыгып, бистәдәге биек йорт янында тукталдылар.

— Әйдә, минем эшләгән урынны күреп чык, — диде Ирхәт.

Дәлия юл буена бер сүз дә эндәшмәде, институтка керү шатлыгы нигәдер битарафлыкка әйләнгән иде. Һәм ул Ирхәтнең тәкъдименә дә каруланмыйча ризалашты. Бүлмәгә дә битараф кына күз йөртеп чыкты — җиһазлар күп түгел, ике зур тумбалы карасу өстәл, аңа каршы якта аксыл калын тукыма белән тышланган урындыклар тезелгән, диварда күкеле һәм герле сәгать текелди. Ирхәт Дәлиягә утырырга ишарәләде. Аның, ишек янына барып, кечкенә төймәгә басуын кыз абайламады. Егет, өстәл тартмасыннан нечкә билле ике рюмка алып, аларны тәрәзә төбенә куйды, шул ук тартмадан озын муенлы шешә тартып чыгарды, бөкесен шытырдатып борып ачып, коньякны җәһәт кенә бүлде.

— Әйдә, Дәлия, очрашу хөрмәтенә сыйланып алыйк.

Кыз, хәзер генә аңы кайткандай:

— Минме? Мин аракы эчәмме?! — дип күзләрен акайтты.

— Дәрәҗәнә төшермә! Аракы түгел, коньяк! Һәм ниндие әле! Укып кара. Чит илнеке.

Ирхәт Дәлиянең кулына рюмканы тоттырды, төшереп җибәрмәсен, дигәндәй, кызның рюмкалы кулын учында тотты, аңа коньякны көчләп эчерде. Кыз, һич тә теләмәсә дә, рюмкадагы коньякның яртысы чамасын йотарга мәҗбүр булды, калганы авызы кырыйларыннан муенына акты. Ул тончыкты, кулларын бутап, иелә төште. Ә Ирхәт, берни булмагандай, рюмкаларны яңадан тутырды, кызга борылып карамыйча гына:

— Әнә, конфет кабып җибәр, — диде. — Тамакны көйдерүе үтә аның. Рәхәт кенә була аннары.

Дәлия эченә ят ризык керүенә өзгәләнергә өлгергәнче, егет аның авызына тагын рюмка китереп терәде һәм, кыз тирән итеп сулыш алганда, коньякны аның авызына койды. Бу юлы тончыкмады Дәлия, хәмер авызына салынган уңайга голт-голт йотыла барды. Ирхәт аңа конфетны да көчләп каптырды. Дәлия тәрәзә ягына авышты, гәүдәсен төз тотарга тырышып, урындыкка таянды. Ул хәтерен югалта барды, аның күзләрен дөм караңгылык каплады.

— Бигрәк җебегән икәнсең, — дип акрын гына сөйләвен белде Ирхәт һәм Дәлияне, таянган кулын ычкындырып, урындыкларга яткырды, аякларын да урындыкка күтәреп салды...

Шуннан соңгысын Дәлия бик тә томанлы хәтерли. Айнып киткәч, ул Ирхәтнең битен тырнады. Кычкырмакчы булып авызын ачуга ук, Ирхәт озын муенлы шешәдән аның авызына тагын коньяк коеп өлгерде...

Өстеннән Ирхәт торгач та, Дәлия, кычкырырлык та һәм сикенерлек тә хәлсез килеш, шул хәләтендә шактый озак ятты, күлмәген төшереп, ачык төшләрен капларлык та җегәре юк иде аның.

Көн үзәге җиткән икән, сәгатьтән күке чыкты, ләкин, кычкырмыйча, урынына кире кереп посты. Күкенең башы турысында ук шулай тавышсыз күренеп алуы Дәлиядән оялуы, әллә аны мыскыллавы булды инде шунда...

Ниһаять, ул торды, бөгерләнгән күлмәген сыпыргалады, тырналган битен каплап бүлмә буйлап йөренүче Ирхәтнең йөзенә төкерде дә ишеккә юнәлде, ишекне ача алмыйча азапланды. Коридорга чыккач, бөтен тәне тагын хәлсезләнде, бөрешеп, чүгәли башлады. Аның җилкәләренә мең тауны берьюлы өйгәннәр иде кебек. Джунглида павиан көчләгән хатын халәтендә иде ул — бу зур маймыл да хатын-кызны тәмам хәленнән тайдырганчы изә, имеш.

Диварга таянды Дәлия, аннары аңа бөтен гәүдәсе белән терәлде — егылудан дивар тотып калды аны. Йөрүчеләр күренмәде. Баскыч башына диварга тотынып, шулай да чайкалгалап барды. Урамда вак агачлар арасына кереп чүгәләгәч, күңелә болганды да косып җибәрде.

Тактасы кубып кыйшайган эскәмиядә сәгать чамасы утыргач, кинәт сикереп торды Дәлия һәм, карарга килеп, ашыгып китеп барды.

Дәлия ишекне киң ачып керде дә, черт итеп бикләде. Ирхәт моны көтмәгәндер, күзләре шараеп, телсез калды, тырналган битенә ябыштырган тасманы төзәткәләгән кулы һавага эленде.

— Ал кәгазь! — дип әмер бирде аңа Дәлия... — Яз! Мин Дәлияне көчләдем, диген. Ул судка бирмәсә, мин аңа өйләнергә риза, диген. Тиз яз! Югыйсә, мин сине төрмәдә черетәчәкмен! Югыйсә, мине ир хатыны булу, булып алу гына коткарачак!

Дәлиягә соңлап килгән катгыйлык Ирхәтне шүрләтергә җитте. Ул:

— Соң... — дип мөми авызланды.

— Соң түгел, ә көн үзәге! Яз! Югыйсә, хәзер үк кычкырам да кеше җыям! Дәлилләр җитәрлек, мин канга буялган килеш. Анысы гына җитмәсә, менә монысы да бар! — дип, өстәл башы белән тәрәзә арасына Ирхәт аякларын өскә каратып куйган аксыл тукымалы урындыкны тартып чыгарды.

— Соң... Биктиең сине шушыңарчы кыз килеш йөрткәнгә ышанырлык түгел, әй... — Ирхәт үзен тиз кулга алырга тырышты. — Койрык бозгаката икән... Кызлар янында мине бизгәк тотулар бетәр микәнни...

— Теләңә салынма! Яшисең килсә, тиз яз! Югыйсә, урындык белән башыңны ярам! Минем югалтасы нәрсәм юк! Иртәгә үк авылга язылышырга кайтасың! Юк, бүген үк алып кайтам мин сине!

... Алар язылыштылар. Әти-әнисе каршы төшсә дә, Дәлия аларның киңәшен тотмады. Туй ясарга әтисе килешмәде, бу очракта да аның сүзе «әйттем — бетте!» булды.

Ирхәт, ике көн өйдә бутапып йөргәч, эшләрем көтә, дип, шәһәргә китеп барды. Дәлия аңа иярмәде, гомумән, ул кияүгә чыгып алу тәртибен, үзе уйлавынча, әйбәт оештырды. Авылда үз кешеләр, авыл советы секретаре, Дәлиянең фаҗигасен аңлап, аларны кайткан көндә үк ирле-хатынлы итеп теркәде. Ирле-хатынлы саналган шушы ике көндә Дәлия Ирхәтне янына якын китермәде, табында бергә утырып ризык җыймады.

Бу хәлләргә инде ике айлап вакыт узды. Ирхәт кайтып күренмәде, Дәлия аны эзләп бармады — мондый өйләнешүнең ахыры шулай бетәчәге алдан ук мәгълүм иде, ләбаса. Кышын институтка баргач, аерылып та кайтырмын, дип үзен тынычландырырга тырышты Дәлия. Ләкин ул Биктимер белән кушылуга өмет итмәде, бу турыда уйларга да нигез юк иде.

Беркөнне Дәлия бергә эшләүчеләрнең чышын-пышын сөйләшүләрен ишетте.

— Дәлиябезнең оеткысы сыеграк булган шул, — диде баш хисапчы. Ул тормышта үзен дә, башкаларны да сынаган, илле яшенә якынайган, биш балалы апай иде. — Холкында-тәртибендә әтисе бөгелмәс кеше дә бит... Дәлиясенең үзенә тартымлыгы җитмәгән...

Хезмәттәшләре сүзләрен Дәлиянең ишетүен теләләр иде бугай. Бераздан менә шундый хәбәрне уртаклаштылар. Имеш, Биктимер, Дәлия теләсә, аңа өйләнергә риза икән. Аңардан башка мин яши алмаячакмын, диген, имеш. Бу хәбәр — хактырмы ул, әллә гайбәтме — Дәлиянең әти-әнисенә дә килеп ирешкән булса кирәк. Әтисенең, җае чыкса да, чыкмаса да, фәлсәфә коруы шул хәбәргә кинаяләве булыр. Кичә кичен әтисе:

— Өйләнеп, хатыннан уңмау, кияүгә чыгып, ирдән уңмау — сыңар аякта йөрергә маташу ул, — дип сөйләнеп утырды.

Бераздан:

— Үзгәрде замана, — дип тамак кыргалады. — Кияүгә чыгуга аерылалар да, — монысы, әлбәттә, кызы Дәлия бакчасына ташны төбәп ыргытуы иде, — гыйффәт айлары да сакламыйлар, аерылган көнне үк башкага чыгарга әзер торалар. Алучысы гына булсын. Хәер, алучысы да бар, чөнки анысы да ике көннән аерып җибәрәсен белә. Азгыннар әйтмешли, аш үзгәртеп кенә карыйлар.

«Биктимер андый түгел!» — дип кычкырып җибәрә язды Дәлия. Ярый ла, тыелып калды — әтисенең тагын да үтемлерәк, зәһәррәк сүзләре булган икән.

— Тик гап-гади нәрсәне белмиләр иртәнчәк өйләнешеп, көн үзәге узуга аерылышучылар — бер елда ике җәй булмый!

... Инде кар төште. Әлегә юка. Сай эзләрне генә каплады. Көзге пычракта машина тәгәрмәчләре котырынып казыган тирән яралы эзләр хәзергә явыз мыскыллап ыржаялар.

... Урам әйләнә егетләр.

Өзелә лә үзәккәй...

Йөрәккәй бериш кисәкләргә турала. Әрнүле ярчыкларны җыеп бөтенәйтергә нинди көч кирәк икән? Бармы андый көч?

Урам әйләнә егетләр...

1995.

Дамир ИСХАКОВ,
тарих фәннәре кандидаты

МИЛЛӘТМЕ, ХАЛЫКМЫ?

Татар тарихын булдыруның кайбер мәсьәләләре

> **Үткәнен белмәгән халык үзенең киләчәгенә хуҗа була алмый.**
>
> **Әйтем.**

Күптән түгел дәрәҗәле генә галимебез авызыннан фәнни мәҗлестә «Халык белән милләт бер инде ул, алар арасында аерма юк», — дигән фикер ишетергә туры килде. Тамырдан ялгыш караш бу! Шушы бәхәскә кагылышлы рәвештә, соңгы вакытта республика көндәлек матбугатында татар тарихы буенча дәреслекләр булдыру турында башланган дискуссиягә тукталып китүне кирәк дип саныйм.

Мәгълүм ки, теоретик яктан алганда, милләтнең халыктан берничә аермасы бар. Шуларның берсе — милләт дәрәҗәсенә ирешкән халыкның үз галимнәре язган тулы тарихы булуы һәм ул тарихның мәктәпләрдә укытылуы.

Шушы күзлектән караган вакытта без әле милләт түгел, чөнки бүген татар тарихы язылмаган, Татарстанда аны булдыруның стратегиясе дә билгеләнмәгән. Моннан бер ел элек мин әлеге тарихның кайчан, кем тарафыннан һәм нинди нигездә язылачы билгеле түгеллеге турында язып чыккан идем. Бу өлкәдә эшләр шул килеш кала бирә. Ләкин дөнья бер урында тормый һәм акрынлап булса да Татарстанда тарих буенча дәреслекләр чыга башладылар: 5-6 класслар өчен «Татарстан тарихы буенча хикәяләр» (авторлары: Г.Дәүләтшин, Ф.Хуҗин, И.Измайлов); урта мәктәпләр, гимназия-лицейлар өчен «Татарстан һәм татар халкы тарихы», I кисәк (авторлары: З.Мифтахов, Д.Мөхәммәдиева, II кисәк (авторы — К.Синицына); шул ук типтагы соңгы дәреслек — Р.Фәхретдинов тарафыннан язылган «Татар халкы һәм Татарстан тарихы», I кисәк (Борынгы чор һәм урта гасырлар дәвере).

Әлбәттә, берничә яңа дәреслекнең язылуы һәм аларның укучылар кулына керүе — шатлыклы хәл. Бу көннә без күптән көткән идек. Исегезгә төшерәм: элекке союздаш республикаларда, мондый дәреслекләр инде күптән булдырылып, төп халыкның тарихы шактый заманнардан ук аерым фән буларак мәктәпләрдә укытылып килде. Безгә исә алар элекмәдә — «автономияле» халыкларның ничек инде «үз тарихы» булсын! Татарстанда бер генә тарих — Советлар Союзы, ягъни Русия тарихы гына укытылды. Горбачев заманнары җиткәч, җөмһүриятебездә ниндидер бер яңа «фән», ярым төбәкчелек, ярым интернациональлек рухындагы «Мәдәният һәм Татарстан тарихы» укытыла башлады (билгеле, дәреслексез генә). Шөкер, ул заманнар да артта калды...

Әмма татар тарихы буенча дәреслекләрнең саны арта баруы белән күңелдә шөбһә һәм борчулар да үсә бара. Ни өчен, дисезме? Сәбәпләре байтак аның.

Әүвәл шуны әйтәсе килә: бездә татар тарихына багышланган монографик рухтагы китаплар шактый булса да, аларның берсе дә халкыбыз тарихы буенча гомуми хезмәткә тиңләшмиләр. Икенче төрле әйткәндә, бүгенгә хәтле татарның академик тарихы юк. Үз чиратында, бу китапның булмавы татар тарихына кагылган күп мәсьәләләрнең тиешенчә өйрәнелмәгәнлегенә бәйле. Башка милләтләрдә дә шул ук хәл. Мәсәлән, «Башкортстанның иң борынгы чорлардан алып XYI гасырга кадәр булган тарихы» (авторлары: Н.Мәҗитов, А.Солтанова) дигән хезмәттә урта гасыр дәвере башлыча тарих фәненең XIX йөз дәрәҗәсендә язылган. Югыйсә, бу китап әле күптән түгел генә басылып чыккан. Сәбәп уртак: Алтын Урда, татар ханлыклары чорлары буенча мөстәкыйль тикшерүләр үткәрелмәгән, аларга һәм башка мәсьәләләргә багышланып, чит илләрдә чыккан күпсанлы хезмәтләр безнең тарихчыларыбызга билгеле түгел. Ә тарих буенча гомуми (академик төрдәге) хезмәт язу өчен концептуаль проблемаларны уртага салып тикшерергә, бәхәс-дискуссияләр үткәрергә кирәк. Андый сөйләшү Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтында соңгы тапкыр моннан ун елдан артык элек булды. Ул татар халкы тарихы буенча язылачы китапның план-проспектын төзү белән бәйле иде. Проспект төзелде, хезмәт исә уйланылганча язылмады.

Ни өчен мин, үҗәтләнеп, фәнни «начальниклар»га бу фикерләрнең ошамаслыгын алдан ук белә торып, шушы мәсьәләләргә кат-кат тукталам соң?

Әфәнделәр! Без бер нәрсәне аңласак иде: концептуаль проблемаларны хәл итмичә һәм татар халкы тарихы буенча гомуми (академик) хезмәт булдырмыйча, дәреслекләр язып булмый. Дөресрәге, дәреслекләрне язып була, ләкин фәндә тулаем чишелмәгән мәсьәләләр аларда ярылып ятачак һәм укучыларның башларын бутап бетерәчәк. Әйтик, «болгармы, татармы» дигән мәсьәләне генә алып карагыз. Инде миңа ышанмыйсыз икән, күренекле тарихчыларыбыз Г.Гобәйдуллинның «Татарларның килеп чыгуы һәм Алтын Урда», «Татар тарихы» (1923-1924 еллар), Г.Ибраһимовның «Татарлар арасында 1905 елгы революция хәрәкәте» (1925), Ә.-З.Вәлидинең «Кыскача төрек-татар тарихы» (1917) китапларына, мәкаләләренә күз салыгыз. Аннан соң бит без монда мескен «АССР тарихлары» язып ятканда «империалистик» Көнбатыш та тик тормаган. Анда инглиз, төрек, урыс телләрендә татар тарихына кагылган уннан артык китап, тикшерүләр эшләнгән, шуларның ким дигәндә икесе академик хезмәтләр рәтенә кертелә ала (Т.Дәүләтшинның 1974 елны Лондонда урыс телендә чыккан «Совет Татарстаны. Ленинчыл милли политиканың теориясе һәм практикасы» һәм А.А.Рорлихның 1987 елны АКШта дөнья күргән «Идел буе татарлары. Милли бирешмәүчәнлек күренеше» монографияләре турында сүз бара). Татар тарихы концепциясен эшләгәндә аларны да истә тотарга кирәк. Бу — бер.

Икенчедән, Казанда, атап әйткәндә, Тел, әдәбият, тарих институтында соңгы елларда берничә әһәмиятле фәнни конференция үткәрелде. Аларда шактый гына яңа фикерләр дә әйтелде. Ни өчендер, шушы көнгәчә әлеге материаллар җыентык булып чыкмады. Сәмән юк дисәң, югары урыннарда утыручы фән «генераллары»на үз хезмәтләрен ялтыравыклы кәгазьдә китап итеп чыгару өчен акча табыла... Ә бит көн кебек ачык: әгәр бәхәсле мәсьәләләрне тикшергән фәнни форум нәтиҗәләре басылмый ята икән, фәндә торгынлык башланачак. Ул гына да түгел, фәнни конференцияләрне оештыра белергә дә кирәк. Уйлап утырам: татар халкының этник тарихына багышланган бердәнбер махсус конференция 1946 елда булган (Мәскәү кушуы буенча); Казан ханлыгы мәсьәләләрен үзәккә алган зур дәрәҗәле халыкара җыенның гомумән булганы юк. Бу — кабер тынлыгы түгелме соң, җәмәгать?

Өченчедән, үзебезнең хезмәтләрне бастыру турында ныклап уйланырга кирәк. Башта ук искәртим: акча юклыгы бик яхшы аңлашыла, ләкин ул, әйткәнемчә, кем өчендер юк, ә кемдер өчен бар. Белеп сөйлим, чөнки үз китапларымның язмышы аянычлы. Әйтик, фәндә бөтенләй эшләнмәгән тармак — татарларның соңгы 200 елдагы этник тарихы, демографиясе, шәһәрләшүенә багышланган зур хезмәтем (18 табак, исеме — «Татар халкының тарихи демографиясе. XYIII—XX йөз башлары») 300 данә күләмендә иганәлек акчасына, битнең бер ягына басылып, ярым китап булып чыкты. Инде аларның күбесе чит илгә таралып бетте. Икенче зур монографиям — «Татар халкының XYI—XX йөз башларында этнодемографик үсеше» (күләме — 700 бит) дигән китап. Ул да безнең тарихның катлаулы һәм әле чишелмәгән мәсьәләләрен эченә ала (шул исәптән, Казан һәм Касыйм ханлыкларында этник процессның барышын, димәк, татар халкы оешуын да кертеп). Менә инде шактый вакыт бу хезмәт Татарстан китап нәшриятында кузгалмыйча ята, ә мин китапны чыгару өчен кирәк булган 50 млн. сумны эзләп интегәм. Күп кенә башка тарихчылар да шундый хәлдә. Сорау туа: әллә фәнсез, китапсыз дәүләт булдырып була дип уйлыйлармы икән безнең сәясәтчеләр?

Югарыда язылганнар турыдан-туры бүгенге дәреслекләр проблемасына барып тоташа. Ә бу өлкәдә тарихны яктырту җәһәтеннән аянычлы хәлләр шактый. Аларны З.Мифтахов һәм Д.Мөхәммәдиева авторлыгында чыгарылган «Татарстан һәм татар халкы тарихы» исемле дәреслектән бик ачык күреп була. Әйтик, бу дәреслектә Казан ханлыгының сәяси төзелеше тулаем ялгыш тасвирлана (161 бит). Эш шунда ки, бу авторлар карача-бәкләр системасы дип исем алган, татар ханлыкларының сәяси нигезен тәшкил иткән һәм Алтын Урда чорыннан калган тәртипне бөтенләй күзаллый алмыйлар. Югыйсә, моның өчен хәзерге чит ил әдәбиятын белергә генә кирәк (Ю.Шамилоглы, В.Ф.Манз, А.Фишер, Х.Иналчик хезмәтләре). Шуннан инде аңлашыла, ни өчен авторлар Казан ханлыгындагы Кыпчак кланын бер урында нугай, икенче урында Мангыт дип билгелиләр. Чынлыкта исә, Мангытлар — мөстәкыйль клан һәм алар ханлыктагы 5 бiлекнең (кенәзлекнең) берсендә хуҗа булганнар (тарихи чыганакларда күрсәтелгән «Мангыт юрты»). Ә бу кенәзлекләрнең эзләрен XYI—XYII йөзләрдә Казан өязендә сакланган, «дорога» (даруга — өлкә, төбәк) дип аталган (Алат, Җөри, Галиц, Арча, Нугай «дорогалары») административ берәмлекләрдән эзләргә кирәк.

Шулай ук дәреслектә Олы-Мөхәммәт ханның шәҗәрәсе бозылып бирелә; ул Туктамыш ханның оныгы дип күрсәтелә (153 бит). Чынлыкта Олы-Мөхәммәт ханның атасы — Хәсән (Эчкеле Хәсән), ә бабасы Джинә (Хинe) исемле булган. Туктамыш хан исә — соңгысының туганнан туган агасы, яисә энесе. Ни өчен мин моны тәфсилләп торам? Чөнки чыганакларда Хәсәннең Болгар улысына бәйле булуы турында кайбер мәгълүматлар бар. Аннан соң әлеге мәсьәлә Болгар улысыннан Казан ханлыгы үсеп чыгу турындагы бик катлаулы проблемага барып тоташа (кара: Казан ханлыгы тарихының билгесез битләре — «Мирас» журналы, 1993, № 10).

Ә инде З.Мифтахов һәм Д.Мөхәммәдиева телгә алган (159 бит) Болгар улысындагы «Шонгут кенәзлеге» (XIY йөз) тарихта бөтенләй дә билгеле түгел һәм фактта археолог А.Халиковның фантазиясе җимеше булып кына тора. Шул ук вакытта Казан ханлыгы оешканчы, Болгар улысында аерым кенәзлекләр, һичшиксез, булган. Чыганаклардан без «Болгар» (еш кына «Казан» белән бутала), «Җүкәтау» һәм «Кирмәнчек» кенәзләрен беләбез. Бу Болгар улысының — ә ул Алтын Урда дәүләтенең бер кисәге (гарәпчә — «иклим») булган — үз эчке административ-политик структурасына ия булганлыгын күрсәтә.

Безнең игътибар үзәгендәге дәреслектә сез Касыйм ханлыгы турында берничә мәгълүмат та таба алмассыз. Ә бит ул дәүләттә татар халкының зур этник төркеме — мишәрләр төп урын тоткан. Бу хакта безнең тарихчылар аз яздылар. Дөрес, минем чыкмыйча ята торган китабымда әлеге мәсьәләгә 50 бит багышланган... Ләкин эш башкада: татар ханлыклары тарихын (Касыйм, Кырым, Әстерхан, Себер) бербөтен итеп карамасаң, ул тарихны аңлап һәм дөрес итеп язып булмый. Мәсәлән, мин бу ханлыклар арасында туктаусыз рәвештә феодаллар алмашу булганлыгын күрсәтә алдым. Ә бу исә шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: татар ханлыкларында феодаль катлам уртак булган, һәм ул катлам Алтын Урдадагы төркиләргә барып тоташа. Кара халык исә «җирле» төркемнәрдән торган: Казан ханлыгында — болгарлардан, Касыйм ханлыгында — бортаслардан. Мәсьәләне шушы рәвешчә куйганда, «болгармы», «татармы» дигән бәхәс бөтенләй икенче төс ала. Ә кайбер тарихчылар, әйтик, Б.Солтанбеков тарафыннан тәнкыйть ителгән караш — «Татар халкының XYI йөздә картаерга өлгерүе» турындагы мәгънәсез һәм буш тезис (З.Мифтахов һәм Д.Мөхәммәдиева) урынына этносның чынбарлыктагы үзгәрешләре проблемасын күрсәтү зарурлыгы килеп баса. Моңысы исә XYI—XYII йөзләрдә татар этносының нинди үзгәрешләргә дучар булуы хакындагы икенче бер зур фәнни мәсьәләне күтәрергә мөмкинлек бирә. Соңгы проблема, алда каралган дәреслекнең логик дәвамы булган хезмәттә, ягъни К.Синицына авторлыгындагы дәреслектә бөтенләй читтә калдырылган. Объектив фактлар исә шуны күрсәтә: Казан ханлыгын алганда һәм аннан соң булган азатлык сугышларында татарлар демографик фаҗигагә дучар ителә (халыкның өчтән бере юк ителә), шәһәр тормышы юк дәрәҗәсенә җиткерелә һ.б. Шушы һәм башка сәбәпләр нәтиҗәсендә татар этносы «яңадан туу» процессын кичерә. Ә бу инде XYI йөзнең беренче яртысында яшәгән татар этнослары урынына XYI—XYII йөзләрдә бердәм Идел-Урал татарларының алмашка килүен аңлата.

Аңлашыла ки, Татарстанда чыккан кайбер тарих дәреслекләренә бик сак карарга кирәк. Аерым алганда, З.Мифтахов һәм Д.Мөхәммәдиева тарафыннан эшләнгән дәреслекне тикшергәндә, мин авторларның хәзерлек дәрәҗәсенә шөбһә белдергән идем. Фикеремдә калам: тикшерелгән китапта ялгышлыклар тулып ята (аларның биш процентын да китермәдем әле). Ләкин бу күзәтүдән тагы бер сабак чыга: тиешле югары оешмалар бүгенгә кадәр татар халкының академик тарихы булдырылмавына игътибар итсеннәр иде. Тәкъдимем шул: Фәннәр академиясе каршында татар халкы тарихын язу өчен вакытлы ике төркем булдырырга кирәк (тиешле финанслау биреп). Ни өчен икеме? Чөнки хәзер галимнәр арасында ике тарихи «мәктәп» бар, алар күп мәсьәләләргә төрлечә карыйлар һәм сизелеп тора — бергә эшләмәячәкләр. Ә инде ике төрле концептуаль, әмма төгәл фәнни нигезгә корылган гомуми (академик) татар тарихы язылса, бу — зур казаныш, алга китеш булачак. Һәм шул нигездә мәктәп, югары уку йортлары өчен яңа буын дәреслекләр дә барлыкка килер иде.

Надир Дәвләт:

Татарга бүген үз мәдәнияте аша дөньяга чыгарга кирәк

Әңгәмәдәшебез белән таныштырып китү зарур булыр.

Надир Дәвләт — Истанбулдан, Мәрмәрә университеты профессоры, шушы уку йорты каршындагы төрки халыкларны өйрәнү институты директоры урынбасары.

Ул 1944 елда Кытайдагы Мукден шәһәрендә туган. Биш елдан соң аларның гаиләләре Төркиягә күчеп китә. Надир әфәнде югары белемне Мюнхенда алгач, 14 ел буена «Азатлык» радиостанциясендә эшли. 1984 елдан янә Төркиядә. Хатыны Теләк белән ике углан үстерәләр. Гәрәйгә — 22 яшь, ул — компьютерлар буенча белгеч, ә Юлайга әле быел гына 14 яшь тулган.

Надир әфәнде белән безнең әңгәмә Татарстан һәм Төркия арасындагы мәдәни багланышлар турында фикер алышу белән башланып китте.

— Элекке СССР биләмәләре булган төрки республикалар белән багланышлар 1991 елдан соң гына урнаштырылды, — диде ул. — Шул җәһәттән Татарстан, Башкортстан белән дә мәдәният, сәүдә өлкәләрендә сукмак салынды. Бу сукмак елдан-ел киңәя, үсә бара. Мәсәлән, татар язучысы Ринат Мөхәммәдиевнең «Сират күпере» исемле романының бездә дөнья күрүе — шуның бер дәлиле. Әсәрне төрекчәгә Эгей университеты галиме Мостафа Өнәр тәрҗемә итте. Мирсәет Солтангалиев, гомумән, Төркиядә зур кызыксыну тудырган шәхес. Чөнки мөһарчы да, әйтик, Франциядән А.Бенингинның һәм берничә төрек авторының бу каһарман турындагы китаплары нәшер ителгән иде. Башка төрле әсәрләрне төрек укучылары ничек кабул итәр, анысын төгәаен генә әйтә алмыйбыз. Мәсәлән, Әмирхан Еникинең хикәясе бер журналда басылып чыккан иде. Гомумән алганда, фәнни эчтәлектәге, Татарстан, татарлар тормышы турындагы язмалар, әдәби әсәрләргә караганда, күбрәк күренә.

— Безгә мәгълүм булганча, Төркиядә татарның атаклы шәхесләре Гаяз Исхакый, Садри Максуди һ.б.ларның тормышына, иҗатына бәйле архив материаллары шактый. Аларны бүген Татарстанга алып кайтырга мөмкинлек бармы?

— Дөньяда мөмкин булмаган эш юк, акчаң гына булсын. Әле телгә алынган материалларның күчермәсен алу да акча сорый бит. Тиешле кешеләрне табу өчен дә сәмәнне җәлләмәскә кирәк.

— Әлеге язмалар, документлар дәүләт архивында сакланмыймыни?

— Юк. Кулларында мондый документлар булган кешеләрне табу да җиңел түгел. Хәтта сезнең үзегезнең китапханәләрдә дә татарлар турында материаллар аз сакланган. Шулай булгач, Төркиядәге китап йортлары турында ни әйтәсең? Шулай да, Әнкарадагы Милли китапханәдә һәм башка урыннарда эзләнергә кирәк.

— Әгәр дә безнең җырчыларыбыз, театрларыбыз Төркиягә барса, алар анда татар тамашачысын җыя алырмы?

— Бер концертлык җыеп булыр. Төркиядә татарлар аз бит. Мәсьәлә башкачарак куелырга тиеш: Төркиядәге татарларга гына түгел, төрекләргә концерт бирергә, тамаша күрсәтергә кирәк. Татар халкы үз мәдәниятен чит илләрдә танытырга тиеш. Татарга бүген дөньяга үз мәдәнияте, үз сәнгате аша чыгарга, киң җәмәгатьчелектә Татарстан турында уй-фикер уятырга кирәк. Сәнгать, җыр — иң яхшы танылу ысулы инде ул.

— Кара диңгез артында милләттәшләребез ничек көн күрә, алар үз гореф-гадәтләрен саклап кала алганнармы?

— Инде монда, Рәсәйдә яшәүче татарларның яртысы урыслашкач, андагы милләттәшләр турында ни әйтергә була?! Бездәге өч бөртек татар ничек үз телен саклап кала алсын соң? Татар мәктәпләре, нәшриятлар юк. Шулай да татар үз телендә сөйләшә әле. Тик шунысын да истән чыгармаска кирәк: Төркия — зур ил, анда 60 миллион кеше яши, һәм татар теле, сездә ничек кухня теле булса, анда да шулай.

— Безнең бер хәбәрчебез Төркиядә бераз яшәп кайткан иде. Ул анда татарларның дус, бердәм булмаулары турында да әйтте...

— Дөрес. Чөнки алар төрлесе төрле якка сибелеп яши, беркадәр күләмдә моңа тормыш шартлары да этәрә. Аннары шунысын да искәртик: татарлык кына дуслашу өчен сәбәп була алмый әле.

— Ничек инде?! Ә татарны татар иткән гореф-гадәтләр, милли традицияләр һәм иң әһәмиятлесе — теле?

— Гореф-гадәттә төрекләр белән әлләни аермабыз юк. Шул ук мөселманнар без. Татармын дип кенә бер-берең белән дуслык корып булмый, иң элек уртак мәнфәгатьләр, уртак караш булырга тиеш. Тел мәсьәләсенә килгәндә, әйткәнемчә, ул сакланмый, үзебезчә сөйләшүчеләр саны кими бара.

— Сез аны үзегез дә саклап калырга омтылмыйсыз шикелле, чөнки аның өчен татар мохите кирәк...

— Элек, Төркиядә яшәүче татарларны бергә туплаучы оешма булганда, ул мохит үзен нык сиздерә иде. Ә хәзер, бу оешма таралгач, үзара аралашу да юк, шулай булгач, милли мохит тә яши алмый. Хәзер шундый берлек төзеделәр — «Идел-Урал төрекләре» дип атала, ләкин ул уңышсызлыкка дучар булыр дип саныйм. Чөнки берлеккә Төркиягә соңрак күчеп килгән татарлар йөрми. Аларның дөньяга карашы да, дингә мөнәсәбәте дә бу җиргә элегрәк килеп утырган милләттәшләребезнекеннән нык аерыла. Шуңа күрә дә татарлар арасында бердәмлек юк; яшьләр булмагач, бу эшнең киләчәге дә юк. Ә гомумән алганда, татар яшьләре гыйлемгә бик хирыс, алар югары белем алырга тырышалар.

— Гыйлем сүзен телгә алгач, Татарстан белән Төркиядә белем бирү тәртибе турында да берничә сүз әйтсәгез иде...

— Бу өлкәдә аерма күзгә нык ташлана. Безнең белем бирү тәртибе дөньяга киңрәк мәгълүм, дип әйтимме, галимнәребез чит илләрдәге фән әһелләре белән еш аралашып торалар. Ә сездә исә галимнәр бер бүлмәгә бикләнгән шикелле яшиләр. Мин тарихчы, әдәбият галиме буларак әйтәм. Башка фәннәргә кагылмыйм. Бездә, сездәге шикелле, фән академияләре юк. Фәнни эшләр дә, уку-укыту да университетларда алып барыла. Галимнәр студентлар белән аралашып эшлиләр, бу, үз чиратында, аларга үз-үзләрен «форма»да тотарга мөмкинлек бирә, дип уйлыйм.

— Сорауларыбызга җавап бирүегез өчен рәхмәт.

Әңгәмәне Наил ФӘЙЗЕТДИН оештырды.

Казанны яклап корбан булганнар рухына

Казансу уртасында агарып утырган төрбә — Казан ханлыгын җимергәндә һәлак булган урыс сугышчыларына куелган һәйкәлне һәркем беләдер. Ул казанлылар күңелендә төрле тойгылар уята. Дүрт йөз елдан артык дәүләтчелегебезне югалтып яшәгәнгәдер, татар бу һәйкәлгә шомланып, безнең җиребездә кирәксез, артык бер нәрсә итеп карый. Күңелгә шундый уйлар килә: ник соң әле үз дәүләтен, үз башкаласын саклап, газиз гомерләрен корбан иткән каһарман бабаларыбызга һәйкәл юк?! Инде тарихлар башкарак сукмакларга каерыла бара бит. Үз каһарманнарыбызның якты рухына багышлап Казан уртасында һәйкәл куярга татар халкы да хаклыдыр?

Бу турыда Бөтентатар иҗтимагый үзәге төзелгәннән соң шактый сүз булды. Корылтайларда кайнар чыгышлар яңгырады, һәйкәл салу өчен акча җыю фонды ачарга тәкъдим ителде. Ул фондта бераз акча да тупланды бугай... Әмма эш сүздән ары китә алмый йөдәде. Югыйсә, рәссамнарыбыз да, архитекторларыбыз да җитәрлек.

«Тамчы тама-тама таш тишә», ди халык. Танылган рәссамыбыз Канәфи Нәфыйков 1552 елда һәм аннан соңгы елларда дәүләтебезнең мөстәкыйльлеге өчен көрәштә һәлак булган бабаларыбызга истәлек-һәйкәл булдыру кирәклеге турында узган ел ахырында матбугатта тәкъдим белән чыккан иде. Рәссамның сүзе эштән аерылмый икән. Ул тәкъдим белән генә калмаган, әлеге һәйкәлнең проектын да әзерләгән. Рәссамның бу игелекле омтылышы Президентыбыз тарафыннан да яклау тапты.

Июль башында республика Мәдәният министрлыгында бер төркем рәссамнар, архитекторлар, тарихчылар, язучылар, сәясәтчеләр рәссам К.Нәфыйковның әлеге һәйкәл проекты буенча фикер алышуга җыелдылар. Истәлек-һәйкәлнең проекты һәркем күрерлек итеп беркетеп куелган. Рәссам күзаллавынча, һәйкәл борынгы болгар традицияләренә нигезләнгән кебек. Болгар каберлекләрендәгечә очлы гөмбәз белән ябылган таш. Ул Казан Кремле стенасына якын җирдә, Сөембикә манарасына каршы якта урыслар Кремль диварын шартлаткан урында куелыр дип фараз ителә. Истәлек таш артында кара мәрмәр белән «шартлау шәүләсе», янында гыйбадәт кылу өчен мәйданчык, шул мәйданчыкка һәм һәйкәл-ташка кадәр түбәннән киң кара баскыч алып менә. Баскыч буена берничә эреле-ваклы гөмбәзле ташлар куелып, аларга ил азатлыгын яклап корбан булган каһарманнарның исемнәре, икенчесенә — шәһитләр, көчләп чукындырылганнар саны, азатлык өчен оештырылган фетнәләрнең даталары, шулай ук татар милләтеннән чыгып, урыс дәүләтенең күренекле шәхесләренә әйләнгән кешеләр исемлеге язылган... Читтәрәк илен саткан Шаһгали, Камай шикелләләрнең исемнәрен кара мәрмәргә язу да күздә тотыла. Рәссам К.Нәфыйков фикеренчә, бу һәйкәл-таш артык чыгымнар да сорамый...

Проект буенча фикер алышу вакытында төрле фикерләр, тәкъдимнәр әйтелде, ә гомумән, рәссам проекты күпчелек тарафыннан яклау тапты, татар халкы традицияләренә туры килә дип табылды.

Татар иҗтимагый үзәге рәисе М.Мөлеков үз чыгышында проектны хуплавын белдерде. «Өлкән тугannarга» бәлки бу һәйкәл-таш ошап та бетмәс, әмма күп гасырлар буе халыкның хыялында йөргән каһарманнарыбыз рухына бу истәлек тиешле дәрәҗәдә булып, ил сукмагы аңа өзелмәслек булсын иде, дигән фикерне әйтте. Татарстан хөкүмәте дә бу эшкә йөз белән борыла башлады. Дәүләт тә һәйкәл салуда чыгымнардан курыкмасын иде, әнә Свияжск дини һәйкәлен торгызу эшләренә ничек дәррәү тотындылар. Ә безгә үз Кремлебезгә милли рухны кайтарасы иде, дип төгәлләде М.Мөлеков чыгышын.

Язучы Марсель Галиев үз чыгышында Казан каласының милли йөзе көннән-көн югала, урыслаша баруына борчылу белдерде. Архитекторларыбызны Ташкент, Баку, Алматы архитекторлары белән чагыштырып та булмый: безнекеләр кыюсыз, һаман «өлкән абзый» ни әйтер икән дип шикләнеп иҗат итә, бу һәйкәл-таш һәр чат саен калыккан үле, төссез-хиссез сыннарны хәтерләтмәсен иде — мескенлектән качарга иде, диде Марсель Галиев.

Мәдәният министрлыгының төзелеш эшләре буенча урынбасары Г.Мөхәммәтшин:

— Проектны тормышка ашыруны тизләтәсе иде, — диде. — Без проект турында бик озак бәхәсләшәбез, ә төзелеш эшләренә килгәндә, алары унар елга сузыла. Безгә бу һәйкәлне бер-ике ел эчендә төзеп бетерәсе иде. Барыбызга да битарафлыктан чыгып, җиң сызганып эшкә керешергә кирәк...

Фикер алышуларда архитекторлардан С.Ситдыйков, Ә.Мөхәммәдиев, М.Максудов, рәссамнардан А.Абзгильдин, Р.Вахитов, археолог Г.Хуҗин, язучы К.Миңлебаев катнашты.

Инде сүздән эшкә күчәргә вакыттыр. Халкыбыз язмышы өчен шәһит киткән каһарманнарыбыз рухы бездән шуны таләп итә.

Салисә ГӘРӘЕВА.

ЭШЛЕКЛЕ МӘҖЛЕС

«Татар теле һәм урыс теле тигез хокуклы дәүләт телләре итеп кабул ителде. Барлык милли мәдәниятләрнең үсеш хокукы гарантияләнә. Халыкларның тигез хокуклылыгын тәэмин итү дәүләт бурычына әйләнде».

(Татарстан Республикасы Премьер-министры Фәрит МӨХӘММӘТШИН чыгышыннан).

ТЕЛЕ БАРНЫҢ

Татарстан халыкларының телләре турындагы закон, авыр булса да, гамәлгә кереп бара. Татар мәктәпләрен, гимназия, лицейларны тәмамлаган укучылар бүген кабул итү комиссияләренә килә, һәм аларның туган телләрендә белем алырга омтылышы бик табигый. Югары уку йортларында татар телендә уку һәм укыту, ике дәүләт телендә эш алып барырдай белгечләр әзерләү — Татарстан Республикасы Конституциясенең 4 нче маддәсен гамәлгә ашыруда төп нигезләрнең берсе. Бүгенге көндә вузлар татарча югары белем алырга теләгән балаларны укытуга әзерме? Бу өлкәдә нинди кыенлыклар бар? Кадрлар мәсьәләсе ничек хәл ителә? Әнә шундый сорауларны ачыклар өчен «Мәдәни җомга» республикада беренчеләрдән булып шушы эшкә керешкән бер төркем галимне редакциягә чакырды. Алар:

— Даутов Гали Юныс улы — Туполев исемендәге Казан дәүләт техник университеты (КДТУ) профессоры, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы;

— Фәтхуллин Вәгыйз Шәйхулла улы — Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясенең (КДАТА) төзелеш факультеты деканы, профессор;

— Юлдашев Алмаз Юныс улы — Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе (КДАХА) профессоры, Татарстанның атказанган механизаторы;

— Садриева Фирдания Исмәгыйль кызы — Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясенең театр факультеты деканы, доцент;

— Җомагылов Әнәс Хафиз улы — КДАХА доценты, Татарстанның атказанган уйлап табучысы.

З.Мансуров. Хөрмәтле галимнәр! Сез безнең редакциянең беренче мөхтәрәм кунаклары. Аягыгыз җиңел булсын! Белгәнегезчә, татар дөньясында һәм күрше милли республикаларда беренче буларак, җөмһүриятебездә әдәбият-сәнгать атналыгы чыга башлады. «Эшлекле мәҗлес» рубрикасын киләчәктә дә дәвам итеп, без анда татар дөньясын, татар халкын кызыксындырган мәсьәләләрне яктыртырга уйлыйбыз. Дин, әхлак, тәрбия, уку-укыту, мәгариф проблемалары — барысы да газета битләрендә урын алыр. Ә сез даими авторларыбыз булырсыз, дип ышанабыз.

Бүгенге «Эшлекле мәҗлес»не нинди темага багышлыйк икән, дип, озак уйлаштык һәм мәгариф мәсьәләләренә тукталырга булдык. Шулар арасында югары уку йортларында балаларыбызны ана телендә укыту — гаять мөһим, котылгысыз мәсьәлә, дип уйлыйм... Моннан берничә ел элек мин Тарту университетында гаҗәпкә калып, чын-чыннан көнләшеп кайткан идем. Анда ничә дистә еллар буена балалар үз телләрендә белем алалар. Инглизләр — инглизчә, французлар — французча, төрекләр төрекчә укый, ә нигә безгә дә тәрәккый илләрдәгечә белем бирмәскә!

Ниһаять, авырлык белән булса да, бездә дә боз кузгалды.

Г.Даутов. Сүзне тәкъдимнән башлыйсы килә: сез, әдәбият һәм сәнгать атналыгы, дидегез. Әдәбиятның, гомумән, мәдәниятнең чишмә башы — мәгариф. Шуңа күрә газетаның юнәлешенә мәгариф тә керсә, бик табигый һәм уңышлы булыр иде.

З.Мансуров. Сез, әлбәттә, хаклы. Татар халкы — китаплы халык. Әгәр мәҗүсилеккә кире кайтылса, татарлар китапка табыныр иде.

Г.Даутов. Милли мәгариф эшен без моннан берничә ел элек «Мәрҗани» җәмгыятендә, аннан «Мәгариф» комитетында башлап җибәргән идек. Ниһаять, «Мәгариф» ассоциациясе төзелде. Бүгенге мәҗлестә катнашучы галимнәр барысы да — Казан «Мәгариф» комитеты әгъзалары. «Мәгариф» ассоциациясенең төп бурычы балалар бакчаларында, мәктәпләр, югары мәктәпләр, аспирантура, докторантурада татарча белем бирү мәсьәләләрен хәл итүдән гыйбарәт. Әгәр бу чылбырның бер генә буыны эшләмәсә дә, система туктап кала. Хәзерге вакытта татар балалар бакчаларын ачу өлкәсендә ярыйсы гына уңышлар бар. Әйтик, Казанда татар балаларының 25 процентка якыны туган телендә белем ала. Киләчәктә бу күрсәткеч артыр, дип ышанырга кирәк.

З.Мансуров. Хәзер иң актуаль проблема — югары уку йортларында татар балаларын ана телендә укытуны оештыру. Гаять катлаулы бу проблеманы югары мәктәпләрдә ничегрәк хәл итәргә уйлыйсыз?

В.Фәтхуллин. Бүген мәктәптән килгән балаларны иртәгә югары уку йортында татарча укыта башлау мөмкин хәл түгел. Шулай да, эчтән куркып, без моны булдыра алмыйбыз, дип кул селтәргә ярамый. Без бу эшне моннан 4 ел элек башлап җибәрдек. Бүгенге көндә дүрт бүлектә 80 нән артык егет һәм кыз укый. Башта без аларны беренчедән алып бишенче курска кадәр татарча укытып чыгарырбыз, дип уйлаган идек. Тора-бара фикер үзгәрде. Ни өчен? Төзелеш факультеты туплаган тәҗрибә шуны күрсәтә: беренчедән, дәреслекләр юк, аларны чыгару 4-5 елга сузыла. Акча юклык мәсьәләне тагын да кискенләштерә. Икенчедән, бүгенге көндә ата-аналар арасында шундыйрак курку яши: балам татарча белем алса, нинди белгеч булыр да, кайда гына эшли алыр икән, янәсе. Әмма бу фактор белән исәпләшмичә булмый. Өченчедән, кадрлар мәсьәләсе. Бүгенге көндә техник вузлар арасында бу мәсьәлә белән җитди рәвештә нибары өч югары мәктәп шөгыльләнә: авыл хуҗалыгы академиясе, без, ягъни архитектура-төзелеш академиясе һәм КамПИ. Башка вузларны төгәл белмим. Ректордан акча сорасаң, җавап бер: хөкүмәт сөмән бирсә, мин каршы түгел. Әле акча булган очракта да бу эшне башларга теләмәүче ректорлар бар, минемчә. Министрлар Кабинеты акча бирергә каршы түгел, әмма Телләр турындагы законның эшләнеп җитмәгән урыннары бар. Әйтик, бик тырышканда акчаны табарга, аны татар телендә укытуга тотарга да була, ә нинди статьяга нигезләп?

З.Мансуров. Шушы өч мәсьәләнең иң мөһиме, минемчә, китаплар чыгарудыр.

«Шөкер булсын, хәзер алдымда бер нурлы хәят инде,
Теге мәзкүр пот алдында табынганнан оят инде».

Г.Тукай.

В.Фәтхуллин. Сез дөрес әйтәсез, бу — бик кискен мәсьәлә. Дәреслекләр язу мәшәкатьле булса да, моны эшләргә теләүчеләр бар. Теоретик механика, гомуми химия буенча дәреслекләр язылган. Аларны үзебезнең академиядә эшлибез. Шактый тир түккәч, «Мәгариф» милли нәшрияты быел китабыбызны чыгарырга әзер инде. Ләкин акча юк. Әмма бу эшне барыбер туктатырга ярамый. Бер генә мисал. Хәзер безгә 2 нче гимназияне тәмамлаган берничә бала укырга керде. Әгәр бер-ике ел аларны укырга кабул итмәсәк, мәктәпләрдән татар группаларына килмәячәкләр. Шуны булдырмас өчен хөкүмәттән, бигрәк тә Президент аппаратыннан ярдәм кирәк. Моннан берничә ел элек бер җитәкченең: «Сопроматны татарча укыту нигә кирәк?» дигән сүзе безнең эшкә аяк чалу кебек булды. Кая гына барсаң да, сүзне шуннан башлыйлар.

А.Юлдашев. Өстәвенә, химияне яисә югары математиканы татарча укытырга кирәкме, дигән сүзләрне галимнәр дә әйткәли. Безнең академиядә укучыларның 80-85 проценты — татарча укып килгән авыл балалары. Татарча укыта башлагач, доцентыбыз Әнәс Хафизович Җомагылов нинди генә каршылыкларга очрамады! Аны хәтта милләтче дип атадылар.

Ә хакыйкать үзенекен эшли. Инде 900 абитуриентның 400 е: академиядә татарча укырга телибез, дип гариза язган. Бу — студентлар арасында татар теленең дәрәҗәсе арта, дигән сүз. Гомумән алганда, 400 баланың 138 е имтихан биреп укырга керде. Ә безбары тик 60 кешене генә татар группасына ала алдык. Быел ике факультетта тагын татар группасы ачарга ниятлибез.

Шунысын да әйтим: без милли мәгариф концепциясен төзедек. Аның төп максаты — телне үстерү, милләтне саклау. Һәммәбезгә мәгълүм, татар егетләре физика, химия фәннәрен «5»кә бирәләр дә, урыс теленнән имтихан биргәндә «коелып» калалар. Ә «3»кә укып килгән урыс телле балалар институтка җиңел керәләр. Аннан-моннан укып чыгалар да, ни Аллага, ни муллага, дигәндәй, уртакул белгечләр булып калалар. Ә татар группасы ачылгач, декан әйтә: беренче курста мондый югары өлгереш булганы юк иде әле, ди. Димәк, белем алу сыйфаты үсә. Мин үзем беренчедән бишенче курскача татарча укытып, диплом бирү ягында. Әмма бүгенгә әле без моны эшли алмыйбыз.

Ә.Җомагылов. Ректорат белән ара бозылудан курыкмаска кирәк. Хәзер факультет советлары безгә карата хәерхаһ эшебезне хуплыйлар, ярдәм итәргә теләүчеләр арта. Уңай эш нәтиҗәләребез Дәүләт Советына, Президентка карарлар кабул итү өчен нигез дә була алады.

Агрофак, мехфак һәм экономфакта укытуның торышын анализлау бу факультетларда татар телендә белем бирү мөмкинлеген күрсәтте. Инде хәзер эш татар телендә укыта торган укытучыларны табу, әзерләүгә килеп төртелә. Бу мәсьәләдә ректоратның зур ярдәме кирәк — татар теле кафедрасы укытучыларын бу эшкә тарту бик мөһим. Ә безнең академиядә әлеге факультетларда студентларны татарча укыта алырдай галимнәр бар. Яшьләрнең туган телдә белем алуга теләкләре түбәндәгечә: 1994 елда туган телендә укырга теләүчеле-

Гали Даутов.

Фирдания Садриева.

Әнәс Җомагылов.

«Йа татар! Вакыт йитте кузгалырга,
Мәгариф шәмгыданын кулга алырга».

М.Гафури.

—ИЛЕ БАР

рнең саны барлык абитуриентлар санының яртысын диярлек тәшкил итте. Агрофакка — 52, мехфакка — 42, экономфакка 23 студент кабул ителгән иде. Мехфакта — 2, агрофакта I группада татарча уку оештырылды. Нәтиҗәдә без татар телендә белем алырга теләүчеләрнең яртысын гына туган телдә укытуны оештыра алдык. Мондый хәлнең төп сәбәбе — укыту бүлегенең татар группалары эшен оештыруда планы юклыкта. Киләчәктә бу планны, һичшиксез, академия җитәкчесе буеңча үткәрергә кирәк. Уку әсбаплары, кулланмалар булдыру, дәреслекләр төзү белән факультетларның методик комиссияләре Татарстан Фәннәр академиясе төзегән план нигезендә шөгыльләнә башлады.

С.Гәрәева. Татарча укытырга алыну өчен башта кадрлар мәсьәләсен хәл итәргә кирәк бит әле. Вәгыйз Шәйхуллович, академиягездә бу мәсьәләне ничек хәл итәсез?

В.Фәтхуллин. Вузларда эшләүче татар укытучыларының күбесе хәзер урысча фикерли. Безнең үзебезгә дә квалификациябезне күтәрү өчен курслар, семинарлар оештыру сорала. Ә бәлки югары уку йортлары бер-берсе белән укытучылар алмашып торыр, бер үк укытучы башка вузларда да белем бирә ала бит. Студентларны ике телне дә камил белерлек итеп укытырга кирәк. Тупланган тәҗрибәдән чыгып, шуны әйтергә була: I-II курста студентларны татарча, III курстан өкренләп урысча укытырга күчәргә, ә соңгы курсларда урысча гына укытырга кирәктер. Минемчә, тактик яктан бу иң дөрес чишелеш. Мәктәптә татарча белем алган бала вузда фундаменталь фәннәрне туган телендә үзләштерсә, барлык фәннәрдән дә әйбәт укыячак.

Әгәр кабул ителгән законнар тулысынча тормышка ашса, безнең кадрлар мәсьәләсе хәл ителәчәк. Дәүләт Советы сессиясенең берсендә: 1997 елдан башлап эш урыннарына ике телне дә камил белгән кешеләр алыначак, дип әйтелгән иде. Бу юнәлештә күптән инде эш алып барылырга тиеш.

Безнең академиягә килгәндә, быел тагын бер татар группасына студентлар кабул итәргә исәбебез бар.

Р.Сибгатуллина. Вәгыйз Шәйхуллович, Сезнең академиядә техник вузларда татар телендә укыту проблемаларына багышланган республика конференциясе булып узды. Шуның нәтиҗәләре белән таныштырсагыз иде.

В.Фәтхуллин. Конференциягә Казанның барлык вузларыннан, шулай ук Чаллыдан вәкилләр килгән иде. Бик эчтәлекле 46 доклад тыңланды. Алар барысы да бер үк теманы төрле яктан яктырттты. Киләчәктә дә фикер алышуларны дәвам итәчәкбез.

Р.Сибгатуллина. Конференциядә терминнарны татарчага тәрҗемә итү мәсьәләсендә уртак бер фикергә килмәдегезме?

В.Фәтхуллин. Уртак комиссия бар. Тик аны әле әйбәт эшли дип әйтеп булмый. Без аның эшләп киткәнен көтеп тормадык, төзелеш терминнары буенча комиссия төзедек, төрле фәннәр буенча семинарлар уздырдык, һәм иң отышлы тәрҗемә ителгән терминнарны сайлап алабыз. Физика, математика атамаларының күбесе мәктәптә үк кулланыла. Без, татарча терминнар юк, дип укытуны туктатмадык. Күчеш чорында урысча терминнар белән дә укып торырга ярый, дип исәплим үзем. Аның әле шул ягы да бар: терминнар «обкатка» үтәргә, шомарырга тиеш.

Кама политехника институтында (КамПИ) — 3 ел, авыл хуҗалыгы академиясендә — 3, бездә 4 ел татарча укыту, әлбәттә, ниндидер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Һәр югары мәктәп үзендә укытыла торган фәннәргә караган терминнарга үзе «сынау» уздырса, сүзлекләрне әзерләү җиңеләер иде. Чөнки нинди генә әйбәт тел галиме булмасын, терминнарны ул белгечләрдән әйбәтрәк итеп, бөтен нечкәлекләрен белеп тәрҗемәли алмый.

Г.Даутов. Безгә, үзәкләштерелгән системаны җайга салырга вакыт. Үзебезнең университетта без дә урысча-татарча физик терминнар сүзлеге, шулай ук инглизчә-урысча-татарча сүзлек төзибез. Тик бу эш өчен беркем дә түләми. Ә моңа күпме көч түгелә. Болар бит ял, буш вакыт исәбенә эшләнә. Телләр турында законны гамәлгә кертүнең бер маддәсендә сүзлекләр, дәреслекләр төзү, укытучыларга түләүгә киткән чыгымнар чагылыш табарга тиеш. Законны гамәлгә кертәбез икән, аның барлык механизмнары келтерәп эшләсен.

> *«Акылга нур биргән уку,*
> *Мөкатдәс уй биргән уку!»*
>
> *С.Рәмиев.*

Р.Сибгатуллина. Гали Юнысович, Милли университетның шушы көнгә кадәр бинасы юк. 730 студенты булган югары мәктәпнең статусы билгесез. Укытучылар хезмәт хакы алмый, ягъни алар бушлай эшли. Быел студентлар II курсны тәмамлады. Ә менә аннан соң юридик институт, бизнес, коммерция институтлары ачылды. Аларга исә бина да, акча да табылды...

Г.Даутов. 1995 елда Югары Совет Милли университет ачу турында карар кабул итте. Мөхәммәт Сабиров рәислегендә оештыру комитеты да төзелгән иде. Рәис лаеклы ялга киткәч, эш бөтенләй тукталды диярлек. Ә бит комиссиядә вице-премьер, уннан артык галим бар.

> *«Йөк авыр, юл болгавыр булса да, милләт, әйдәле,*
> *Алда рәхәт кадрене белмәккә михнәт файдалы».*
>
> *Ш.Бабич.*

Вәгыйз Фәтхуллин.

Алмаз Юлдашев.

Ш.Зәбиров. Техник вуз галимнәре янына сәнгать академиясе вәкилен чакыруыбызның сәбәбе бар: анда урыс егетләре дә укырга керә һәм татарча өйрәнеп китә. Моның сәбәпләрен әйтсәгез иде, Фирдания ханым.

Ф.Садриева. Безнең академия шактый үзенчәлекле. Туган телдә укыту мәсьәләсе бездә җиңелрәк хәл ителә, нәнки ачылганнан бирле үзешчән сәнгать коллективлары өчен режиссерлар хәзерләү бүлегендә татарча укытыла. Режиссура, сәхнә теле фәннәрен студентлар елның-елында әйбәт үзләштерәләр. Ләкин башка фәннәр урысча укытылганлыктан, кайбер имтиханнарны бирә алмыйча, талантлы гына балалар югары уку йортын ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Бүгенге көндә китапханәчеләр бүлегендә татарча укытабыз. Мин үзем театр факультетында эшлим. Анда да укулар татарча.

Безгә урыс егетләре-кызлары да күп килә. Эдуард Камбалов, мәсәлән, академиягә кергәндә татарча бер авыз сүз дә белми иде. Ә хәзер, кем әйтмешли, татарның үзен сатып җибәрер.

Быел академия театры өчен бер төркем артистлар хәзерләп чыгардык. Әлеге группадагы 12 студентның икесе генә татар телен яхшы белә иде.

С.Гәрәева. Сезнең академия башка төбәкләрдәге татарлар ихтыяҗын кайгыртамы? Татарлар бит чәчелгән дә сибелгән. Ә артистлар, җырчылар һәркайда кирәк.

Ф.Садриева. Безгә Кыргызстаннан, Әстерхан, Тәмән, Пермьнән һәм башка күп кенә өлкәләрдән абитуриентлар килә. Узган ел яңа бүлек — татар җыр һәм милли уен кораллары бүлеге ачылды. Милли сәнгатебез үсешенә дә аның файдасы тияр әле.

С.Гәрәева. Сездә татарча укыткан өчен өстәмә түлиләрме?

Ф.Садриева. Түләмиләр.

В.Фәтхуллин. Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәр югары мәктәпкә татар телендә укыту өчен акча бирелде.

Ф.Садриева. Безгә дә бирелергә тиеш иде ул акча, әмма академиянең түләнмәгән ссудасы өчен тотып калдылар.

Ә.Җомагылов. Монда күтәрелгән мәсьәләләрне мин сәяси мәсьәлә дип карыйм. Татар телендә югары белем алу мөмкинлеге бик күп юридик документлар белән билгеләнә: Татарстан Республикасының мөстәкыйльлеге турында Декларация, Татарстан Республикасы Конституциясе (4 нче маддә), Татарстан Республикасында белем алу турында закон, «Татарстан халыкларының телләре турында»гы Закон, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләтләренең югары белем алу өлкәсендә үзара килешүләре... Безнең милли байлыгыбызны тәшкил иткән табигый ресурслар, игенчелек, терлекчелектән кергән байлык һәм акыл потенциалы тулысынча республика файдасына эшләми әле. Энтузиазм нигезендә генә бу эшне озак еллар дәвам иттерү мөмкин түгел. Шуңа күрә хөкүмәтебез вузларда татар телендә укытуны җайга сала торган тәртипне эшләргә тиеш.

Архитектура-төзелеш академиясендә уздырылган конференция һәм анда кабул ителгән карарлар, һичшиксез, бу өлкәдә этәргеч булыр, дип ышанасы килә.

Г.Даутов. Техник уку йортларында татарча укыту проблемаларына багышланган Республика конференциясе бик вакытлы уздырылды һәм мөһим карарлар кабул итте. Аларның иң мөһимнәрен бу газетаны укучылар да ишетсен иде.

З.Мансуров. Хөрмәтле кунаклар! Шундый эчтәлекле әңгәмәгез өчен рәхмәт. Киләчәктә дә «Мәдәни җомга» битләрендә тирән мәгънәле язмаларыгыз белән катнашсагыз иде.

Әңгәмәне
Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА
язып алды.

■ ***Ике дәүләт телендә эш алып барырлык белгечләр әзерләү үтә мөһим дәүләт эше булганлыктан, моннан соң аны дәүләт программасы нигезендә башкарырга кирәк. Дәүләт программасын төзү, үтәү, финанслау өчен республика хакимияте структурасында дәүләт органы булдырырга. Дәүләт программасын гамәлгә ашыру максаты белән югары уку йортларында татар телендә укытуны оештыру кафедралары булдырырга, тәҗрибә рәвешендә моны Казан архитектура-төзелеш академиясендә оештырырга.***

■ ***Техник югары уку йортлары өчен дәреслекләр һәм методик кулланмалар язу һәм бастыру мәсьәләләрен нәтиҗәле чишәр өчен вузара фәнни-методик үзәк (методик комиссия, методик кабинет) оештырырга. Бу үзәк даими рәвештә фәнни-методик җыентыклар чыгарту мәсьәләләрен карарга тиеш. Казан дәүләт архитектура-төзелеш академиясенең татар телендә укыту өлкәсендәге тәҗрибәсен искә алып, Үзәкне оештыруны КДАТАга йөкләргә.***

■ ***Югары уку йортларында татар телендә укытуны, ике телле белгечләр әзерләүне югары дәрәҗәдә алып бару өчен республика күләмендә кадрлар белемен камилләштерүне оештырырга.***

■ ***Техник фәннәр буенча бердәм терминнар булдыру, бу эшне югары фәнни дәрәҗәдә алып бару максатыннан, Казан архитектура-төзелеш академиясендәге терминология комиссиясе нигезендә төгәл фәннәр буенча тармак комиссияләре оештырырга, тәкъдим ителгән терминнарны бердәмләштерү һәм пропагандалау өчен бюллетень чыгарырга.***

■ ***Татарстан Фәннәр академиясе һәм Казан дәүләт университеты каршындагы күмәк фәнни-тикшеренү лабораториясенең, Казан дәүләт техник университетындагы гомуми физика кафедрасының компьютерларны татарчалаштыру, татар телендә программалар, клавиатура стандартлары булдыру буенча алып барган эшләрен хупларга. Бу эшләрнең фәнни һәм практик нәтиҗәләрен татарча укытуны алып барган югары уку йортларында гамәлгә кертергә, китап бастыру эшендә кулланырга.***

■ ***Югары уку йортларында татарча укыту проблемаларына багышланган Республика конференциясен 1996 елның май аенда Чаллыда Кама политехник институтында үткәрергә.***

Китап күңел үстерә

«Сез кайдан?» дип сорасагыз...

Татарстан Фәннәр академиясенең гуманитар фәннәр бүлеге галимнәре элекке Советлар Берлегендә юкка чыгарга дучар ителгән милләтләрне яңадан торгызу һәм үстерү проблемалары буенча зур эш алып баралар. Аларның күп санлы мәкаләләре, гыйльми җыентыклары һәм монографияләре өледән-өле дөнья күреп тора. Шундыйларның берсе — М.Зәкиевнең «Татары: проблемы истории и языка» дигән китабы.*

Тел һәм тарих проблемалары буенча академик М.Зәкиев озак еллар армый-талмый эшләп килә. Әле генә дөнья күргән яңа китабында галим татар тарихы һәм теленә багышланган үзенчәлекле карашларын тагын да тирәнәйтә, аларны яңа фактлар белән баетып, укучыга тагын да аңлаешлырак рәвештә тәкъдим итә, һәм нәтиҗәдә бик тә катлаулы мәсьәләләрне уңышлы чишүгә таба ышанычлы адымнар ясый.

Китапта сүз татар халкын саклау һәм үстерүгә турыдан-туры кагылышлы өч төрле проблема турында бара: татар халкының этник тамырлары; милли телнең структур һәм функциональ үсеше; шовинизм һәм милләтчелек чикләре мәсьәләсе. Шулай да бу кечкенә рецензиядә сүз бер генә мәсьәлә — татар халкының үзенә «кайтарып бирелгән» тарихи чорлары хакында барачак. Мәгълүм ки, хаким милләт, башка халыкларны үз арасында эретеп юкка чыгару өчен, иң элек аның бу җирдәге тарихын кыскарта, аның үзен килмешәк дип күрсәтергә тырыша, халыкның тарихи җирлеген-нигезен сүтә башлый.

Күтәрелгән мәсьәләләр катлаулы һәм күп төрле булсалар да, яңа китапның зур бер өлеше төрки-татар халыкларының өлегә кадәр рәтләп өйрәнелмәгән яисә ялгыш карашлар нигезендә хәл ителгән борынгы чор тарихы мәсьәләләренә багышланган. Билгеле булганча, борынгы төркиләрнең тарихын да өлегә кадәр һиндевропалылар язып килделәр. Ләкин төрки-татар тарихы дөрес килеп чыксын дип түгел, ә һиндевропалылар тирәсендә вак-төяк күчмә, кыргый тарихлылар да булганын күрсәтү өчен. Алар, Европага төркиләр безнең эраның IY йөзләрендә генә, ә Идел-Уралга тагын да соңрак килә башлаганнар, дип аңлатырга тырышып карадылар. Безнең эрага кадәр IX йөздән алып б.э. IY йөзенә кадәр бу тирәләрдә яшәгән киммер-скиф-сармат-аланнар бары һинд-иран телле генә булганнар, дип исбатлау өчен европацентристлар бик күп хезмәтләр яздылар, тел материаллары белән бу фаразны исбатларга омтылдылар. Аларның фикеренчә, дөньядагы иң алдынгы һәм иң тәрәккый халыклар — ул, барыннан да элек, һиндевропалылар, дөньяның иң зур бер өлешен гомер-гомергә әнә шул халыклар алып торган; төркиләр исә, күчмә тормышлы халык буларак, гасырлар буе бер җирдән икенче җирләргә күченеп йөргәннәр. Шулай булгач, хәзер Идел буенда яшәгән татарлар да бу җирләрдә формалашып, шунда барлыкка килгән халык түгел; гомумән, төрки-татар халыкларының барысы да хәзергә яшәгән җирләренә кайчандыр һәм каяндыр күчеп килгәннәр; аларның берсе дә һәм беркайчан да үзләренең хәзерге ватаннарында яшәмәгәннәр. Һиндевропеистика фәнендә өлегә кадәр әнә шундый европацентризм карашлары хөкем сөреп килә.

Ә инде тарихка чын фәнни нигездән килә башласаң, өлеге карашларның барысы да акрынлап юкка чыга башлый. Чөнки алар тарихи чынбарлыкка берничек тә туры килә алмыйлар. М.Зәкиев китабы — әнә шул юнәлештә, төрки-татар тарихын чын фәнни нигездә өйрәнүгә багышланган җитди хезмәт. Бирердә автор, барыннан да элек, тел мәгълүматларына таяна һәм, һиндевропеистикадан аерма лы буларак, төрки-татар халыкларының чын тарихын, бигрәк тә аның борынгы һәм бик борынгы чорларга караган өлешен ачык итеп күз алдына китерә. М.Зәкиевнең яңа китабы менә шушы яктан әһәмиятле дә.

Күзәтелә торган хезмәттә шулай ук татар халкы үсеше, телебезнең төзелеш һәм кулланыш ягыннан үсү-үзгәрү юллары белән бәйле проблемалар да куелган, һәм алар үзенчәлекле рәвештә хәл ителәләр. Әнә шуңа күрә, бу китап татар халкының килеп чыгышы һәм үсеше белән кызыксынган укучыларга, студентларга, тел һәм тарих укытучыларына файдалы кулланма булыр, дигән ышаныч белдерәсе килә.

Фатих УРМАНЧЕ,
филология фәннәре докторы, профессор.

*** М.З.Зәкиев. «Татары: проблемы истории и языка». ИЯЛИ им.Г.Ибрагимова АНТ, 1995. 464 стр.**

Халык рухы ничек байый



Татар халкының тарихы зур да, катлаулы да. Ә татар әдәбияты тарихына килгәндә, ул үз эченә гасырлар катламын сыйдырган һәм моңа кадәр аның серләрен тулаем ача алганыбыз юк әле.

Әдәбият тарихы өлкәсендә дистәләгән галимнәребез эшли, аларның өледән-өле гыйльми хезмәтләре дөнья күрә тора. Шулар ярдәмендә без үзебезнең үткәнебез, халкыбызның бай мәдәният тарихы, рухи кыйммәтләребез турында күбрәк мәгълүмат алабыз. Мондый хезмәтләр укытучыларга яшь буынны тәрбияләү эшендә ифрат күп ярдәм итәләр.

Күптән түгел Казан университеты нәшриятында нәкъ безгә — укытучыларга атап язылгандай бик кирәкле китап басылып чыкты. «Татар әдәбияты һәм шәрык классикасы» («Татарская литература и Восточная классика»)* дигән бу саллы хезмәтнең авторы — күренекле татар галиме, әдәбиятчы, профессор Хатип Миннегулов. Кереш сүзне танылган тарихчыбыз академик Миркасыйм Госманов язган. Тиражы мең генә данәдән торган өлеге китап һәр укытучы, һәр мәдәният хезмәткәре өчен өстәл китабы булырлык.

Монография, этногенез процессларына бәйләп, татар һәм шәрыкъ әдәбиятларының үзара мөнәсәбәтен, уртак әдәбиятларның географик таралу юлларын, Фирдәүси, Низами, Сәгъди, Әхмәди һ.б. шәрык әдипләре әсәрләренең ничек татарлар арасына килеп керүен, аларның халык әхлагын төзүгә, рухын баетуга хезмәт итүен ачып бирә. Бу китапта шәрык классик әдәбиятында поэзияне өйрәнү мәсьәләләре үзәккәрәк алына. Шушында ук борынгы классик әдәбият үрнәкләреннән «Кәлилә һәм Димнә», «Тутинамә», «1001 кичә», «1001 иртә» үрнәгендә татар хикәяте жанрының үсеше яктыртыла.

Галим Хатип Миннегулов укучыны татар һәм шәрык әдәбияты бәйләнешләре белән таныштыра, шушы бәйләнешләрне яктырткан мәдәни һәйкәлләр, иҗади тәрҗемә мәсьәләләре, шәрык әдипләреннән Низами һәм Котб иҗаты, «Гөлстан бит—төрки», «Диване хикәяте татар» һ.б. әдәбият һәйкәлләре турында тирән һәм төпле фикерләр әйтә.

Гомумән, бу хезмәт галимнәр, укытучылар, студентлар өчен алыштыргысыз кулланма буларак бәяләп бетергесез кыйммәткә ия. Дөрес, хәзергә ул урыс телендә нәшер ителгән. Әмма укучылар аны туган телләрендә дә күрерләр әле дигән өметтә каласы килә.

Шунысын да әйтергә кирәк: китап — Казан дәүләт университеты тарафыннан хаклы рәвештә Татарстан дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгән, чөнки ул гамәли яктан бик кирәкле һәм гасырларга кала торган саллы хезмәт.

Халидә ФӘРДИЕВА,
Татарстанның атказанган укытучысы.

*** Хатип Миннегулов. «Татарская литература и Восточная классика». Казань, издательство Казанского университета, 384 стр.**

Иясе белән йөргән мәзәкләр

Соңгы елларда «Ватаным Татарстан» газетасында «Мәзәкчеләр мәҗлесе» исеме белән даими рәвештә мәзәкләр басылып килә. Моны, әлбәттә, хупларга кирәк. Беренчедән, өлеге тупламалар укучы өчен кызык һәм файдалы булсалар, икенчедән, алар фольклор дигән хәзинәбезне баетуга да мөһим өлеш кертәләр. Әмма бу әсәрләрне газетадагы килеш саклау һәм куллану шактый мәшәкатьле; гадәттә, алар шулай чәчелгән хәлдә яталар, кабат файдалану һәрчак мөмкин дә булмый. Иң яхшысы — бу хәзинәне китап итеп чыгару. Журналист Габделбәр Ризванов нәкъ шулай эшләгән дә. Татарстан китап нәшрияты шушы көннәрдә генә «Мәзәкчеләр мәҗлесе» дигән китапны* укучыларыбыз хөкеменә тапшырды.

Туплап чыгарылган мәзәкләрне мин төп ике төркемгә бүлеп карар идем: «йөремсәк мәзәкләр» һәм «адреслы мәзәкләр» (төгәлрәк атама табылса, башкача да исемләргә мөмкин). Беренчесендә сүз «бер кеше», «берәү»ләр турында барса, икенчесендә вакыйганың урыны да мәгълүм, герое да исем-фамилиясе булган конкрет шәхес. Мәсәлән, Арча районының Кысна авылыннан Миләүшә Габделхакова язып җибәргән мәзәкләрнең берсе мондый: «Шәһидә әбине кече кызы мунчага чакыра. Ләүкәгә менеп, чабынырга гына тотына әби, тышкы яктан югары очта яшәүче олы кызының тавышы ишетелә. Ул да мунчага дәшәргә килгән икән. Шәһидә әби аптырап калмый: «Хәзер, кызым, чабынып кына бетерәм дә килеп тә җитәрмен», — дип җавап кайтара». Чынбарлыкны тасвирлаган шушы берничә юлда милләтебезнең пакьлеге дә, мәрхәмәтлелеге дә, анага булган шәфкатьлелеге дә, җорлыгы вә тапкырлыгы да чагыла.

Мәзәкнең жанр буларак формалашуы риваятьнекенә охшаш. Риваятьнең үсеше исә истәлек һәм сөйләк баскычлары аша уза. Алдарак мисал итеп күрсәтелгән мәзәкне сөйләк-мәзәк дип әйтергә мөмкин булыр иде. Истәлек-мәзәккә дә бер мисал китерик: нәрсәләр генә уйлап тапмыйлар бу галимнәр! Башта «интенсив технология», диделәр. Аннан шул ысул белән игелә торган арышның өске яфрагын флаг дип атадылар. Ул вакыттагы КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Усманов районга килгәч, кайсы басуга керсә дә, шул флагны таптырып аптыратты бит, малай. Ә менә Карл Маркс исемендәге колхоз рәисе Фәтхерахман Рәфыйков аптырап тормады. Башта «ха-ха-ха», дип шаркылдап көлде ул, имтихан алучыны шаккатырып. Аннан авыл Советы түбәсен күз алдына китерде дә җайлап кына әйтеп куйды: «Арышта флаг буламыни?!»

Бу әсәрнең авторы Саба журналисты Тәлгат Нәҗмиев — бәян ителгән өлеге вакыйгада үзе катнашкан кеше. Шуңа күрә аның сурәтләвен истәлек-мәзәк төркеменә кертергә мөмкин. «Адреслы мәзәкләр»дән мондый әсәрләрнең кайсылары риваять-мәзәк дәрәҗәсенә ирешер — бу инде вакыт эше, тарих эше. Моның өчен аларның киләсе буын кешеләрен дә дулкынландыруы кирәк. Шул шартларда гына алар чын мәгънәсендә «йөремсәк мәзәк»ләргә әверелерләр.

Мәзәк — фольклорның «кул тыгарга» рөхсәт ителә торган бердәнбер төре. Чөнки бирердә һәр сүзнең олы йөкләмәсе бар. Шуңа күрә матбугатка әзерләгәндә аларның сүз остасы кулыннан узуы хәерле. Бу җыентыкта, мәсәлән, бигрәк тә Г.Ахунов, Ф.Галимуллин, Т.Нәҗмиев тарафыннан кәгазьгә төшерелгән мәзәкләрдә бер сүз артык түгел, бер сүз ким түгел — барысы да үз урынында.

Беренче коймак төерле була, диләр. Әлбәттә, китапта чатаклыклар да табарга мөмкин. Шул җәһәттән, теләк рәвешендә, бер-ике сүз әйтәсем килә. Әсәрләргә, минемчә, исем кушарга да мөмкин булгандыр, чөнки аларның күбесе исемне үзләре сорап тора. Җыентыкның композициясен дә бер принциптан төзегәндә отышлырак килеп чыгар иде. Тәрҗемә мәзәкләрне киләчәктә, бәлки, махсус бүлеккә туплап бирергә кирәктер, чөнки алар безнеке түгел бит инде. Шулай иткәндә, китаптагы төп бүлекләр эчендә тематик бүлекчәләр ясарга да мөмкин. Ә менә башка жанрларга караган әсәрләрне («Тел чарлагычлар»ны, «Беләсезме!» дигән баш астында урнаштырылган кызыклы мәгълүматларны, шулай ук афористик шигъри юлларны), бик кирәк дип саналса, кушымта рәвешендә биргәндә уңышлырак булыр иде. Әлбәттә, иң яхшысы — аларны туплап, аерым (махсус түгел) китап итеп чыгару.

Бу фикерләр — киләчәккә төбәп әйтү. Ник дигәндә, титул битендә булмаса да, тышлыкта «№ 1» дигән тамга бар. Моны инде дәвамлы басма дип аңларга кирәктер. Эшләнгән эшне тәкъдир итеп, төзүчегә дә, нәшриятка да киләчәктә бу изге юлда уңышлар телик.

Ленар ҖАМАЛЕТДИН,
филология фәннәре кандидаты.

*** «Мәзәкчеләр мәҗлесе». Төзүчесе — Габделбәр Ризванов. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1995, 55 бит.**

АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

ДҮШӘМБЕ
31 ИЮЛЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.30 Мультфильм. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булыр? 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.25 «Бакчачының август мәшәкатьләре». 20.55 «Әйләнә сәхнә». Нурия Ирсаева. 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильмнар: «Гришкины книжки». «Чудеса в решете». 7.30, 18.45 -- «КиноМеню». 7.45, 23.25 «Эфирда -- музыка». 8.20 Нәфис фильм: «Печки-лавочки». 8.55 Мультфильм: «Когда я был маленьким». 10.05 Документаль фильм: «Полицейский звездный пробег». 10.15 «Кремльдән рок». «ДДТ» группасы. 10.50 Спутниклы телевидение. 17.00 Тагын балет турында. 18.00 «Минем каналлы Россиям». 3 нче кисәк. 18.30 Мультфильм: «Сонное царство». 19.00 «Камиллек». 19.30 «Видеомода». 19.50 «Дорфалар һәм матурлар». 20.20, 23.00 -- «Шәһәр». Информацион программа. 20.45 «Телеэкспресс». 21.10 Казан: атна йомгаклары. 21.25 Нәфис фильм: «Люми».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.30 — Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Могҗизалар кыры». 10.55 «Спортның жиде көне». 11.25 Мультфильм. 11.35 Документаль сериал: «Дромадеры». «Бактрианы». 12.20 Нәфис фильм: «Два капитана». 13.35 «Клип-ревю». 14.00 Информацион күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 Мультфильм. 15.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 Йолдызлар сәгате. 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Ышанычлы» телевидениесе. 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.05 «Без». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.45 Нәфис фильм: «Гамлет». 1 нче серия. 23.00 Юрамалар. 23.20 «Спортның жиде көне». 23.50 Эксклюзив.

«РОССИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Нәфис фильм: «Дедушкин раз...». 10.20 Мульти-пульти. 10.30 Төп мизгел. 10.40 Телегазета. 10.45 Музыкаль экспромт. 11.05 Провинция җәүһәрләре. 11.35 Милиция хроникасы. 10.45 «Ура, каникуллар!» 12.15, 17.20 — Яңа тармак. Урыннардан репортажлар. 12.30, 14.20 — Эшлекле Россия. 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 Көн дә бәйрәм. 16.30 Мульти-пульти. 17.50 «Шундый фамилия». 18.05 Эксповидео. 18.20 «Кыргамы-алмаскамы». 18.30 «Коткару-911». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Де факто». 20.35 Нәфис фильм: «Улица на компьютере». 21.40 Репортер. 22.00 «Бизәүсез». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.00 Сериал: «Четыре танкиста и собака». 10.15 Төш юрау. 10.45 «Гүзәллек». 11.15 «Коллекционерлар». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Мультфильм: «Медной горы хозяйка». 13.35 ТВ мәгълүматлары. 13.50 Көнлек телевизион программа. 13.55 Шәһәр һәм анда яшәүчеләр. 14.25 Нәфис фильм: «Открытая книга». 15.30, 22.50 — ТВ мәгълүматлары. 15.45, 17.15 — «Музыка мизгеле». 15.50 «Бакчачыларга киңәшләр». 21.25 «Кино йорты». 22.00 «Санкт-Петербург» телевидениесе. 23.05 «Спорт, спорт, спорт...» 23.20 Имиплек телехезмәте. 23.30 Иртәгәсе көнгә телевизион программа. 23.35 Музыкаль шоу: «Параллар парады».

СИШӘМБЕ
1 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.30 «Ералаш» киножурналы. 18.40 «Күңелләремдә нилер бар». Энҗе Авзалова. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Азнакай хәбәрләре». 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.15 Күп сериялe нәфис фильм: «Тарзан». 1 нче серия. 20.40 «Студент язы-95». 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 Мультфильмнар: «Баба-Яга против», «Глаша и Кикимора». 7.30, 20.20, 23.10 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (31 июль тапшыруын кабатлау). 8.20 Нәфис фильм: «Неотстрелянная музыка». 9.30 «Карденнан комодка каләргә мода». 9.50 Документаль фильм: «Обустройство границ». 10.05 «Кремльдән рок». 10.25 «Базар» тележурналы. 11.05 Спутниклы телевидение. 17.00 «Юмор антологиясе». Эраст Гарин. 17.40 Мультфильм: «Тайна зеленого острова». 17.50 Кыска метражлы нәфис фильм: «Лимонный торт» (Грузия). 18.05 «Декабрь аенда томан». В.Малежик җырлый. 19.05 Документаль фильм: «Василий Кандинский». 19.50 «Дорфалар һәм матурлар». 20.45 «Телеэкспресс». 21.05 «Коммерция әйләнмәсе». 21.30 Нәфис фильм: «Круг обреченных». 23.35 «Эфирда — музыка».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.25 -- «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Кеше һәм закон». 10.40 «Спортның жиде көне». 11.10 Мультфильм. 11.35 Документаль сериал: «Осьминог». 12.20 Нәфис фильм: «Два капитана». 13.45 Классик музыка концерты. 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 «Ел әйләнәсендә — яшелчә бакчасы». 15.20 Эфирда -- «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 «Кара, тыңла». 16.20 Яшь талантлар. 16.40 Марафон-15. 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 «Беренче куллардан». 22.00 Нәфис фильм: «Гамлет». 2 нче серия. 23.25 «Юрамалар». 23.40 Солдат җырлары фестивале «Виктория».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 10.55 «Телегазета». 11.05 Документаль фильм: «Генеральный конструктор». 11.35 «Милиция хроникасы». 11.45 «Ура, каникуллар!» 12.15, 17.20 — Яңа тармак. 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.15 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 Өмет стартлары. 16.50 «Ай тотучы». 17.50 Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера». 18.15 «Беркем дә онытылмаган». 18.20 Әдәби-публицистик цикл: «Россия. «Мәхәббәттә аңлашу». 18.55 Популяр булмаган тема. 19.10 «L» клубы. 20.25 Нәфис фильм: «Допрос». 22.05 Телефильм: «Подлинный художник, истинный артист, настоящий убийца». 1 нче серия. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Нәфис фильм: «Океан». 0.30 «ЭКС».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 9.00 Телесериал: «Четыре танкиста и собака». 10.00 «Төш юрау». 10.35 «Кумирлар». 11.15 «Аукцион». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Мультфильм. 13.35, 15.30, 22.40 — ТВ мәгълүматлары. 13.50 Көнлек телевизион программа. 13.55 Шәһәр һәм анда яшәүчеләр. 14.25 Нәфис фильм: «Открытая книга». 15.45, 18.10 «Музыка мизгеле». 15.50 Бакчачыларга киңәшләр. 16.00 Нәфис фильм: «Фильмоскоп». «Хромые приходут первыми». 17.55 Телефильм. 22.00 Юмористик программа. 22.15 Новгородның җир асты хәзинәләре. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Иртәгесе көнгә телевизион программа. 23.15 Ульямс. «Татуированная роза».

ЧӘРШӘМБЕ
2 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.20 Эфирда — эшлекле мәгълүмат. 18.25 «ЗИПОПО». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Турыдан-туры элемтә». Телевизор караучылар сорауларына Казан шәһәре һәм районнары хакимият башлыклары җавап бирә. 20.35 «Әлли-бәлли-бәү». 20.55 «Кайтса әгәр яшь чагым». Рамил Курамшин концерты. 21.55 Киноның 100 еллыгына. Нәфис фильм: «Война и мир». 3 нче серия. 22.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильмнар: «Гномы и горный король», «Сказка о глупом мышонке». 7.30, 20.20, 23.40 — «Шәһәр». Информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (1 август тапшыруын кабатлау). 8.20 Нәфис фильм: «Фонтан». 10.00 «Грация». 10.45 Спутникли телевидение. 17.00 Документаль фильм: «Святые не любят славы». 17.20 «Палитра: Веронезе. Левий йортындагы мәҗлес». 17.45 «Виртуаль чынбарлыклар». 18.15 Мультфильм: «Самая скорая помощь». 18.25 Кыска метражлы нәфис фильм: «Удача» (Грузия). 18.45 Музыкаль программа «Поп ТВ». 19.15 Телефильм: «Евгения». 19.50 «Дорфалар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 «Enter club». 21.35 «Поза». 22.00 Нәфис фильм: «Прикосновение».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.10 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Хайваннар доньясында». 10.45 «Спортның җиде көне». 11.15 Мультфильм. 11.35 Документаль сериал: «Сибуч». 12.20 Нәфис фильм: «Два капитана». 13.30 «Хит-конвейер». 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 Телеуен: «Мине аңла». 15.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 «Күңелле ноталар». 16.20 Мультсериал: «Путешествие в прошлое». 16.50 «Фэн-клуб». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тин-тоник». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 Киноманзара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Нәфис фильм: «Ответный ход». 23.20 «Юрамалар». 23.40 «Тылсым-шоу».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.20 «Клип-антракт». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Пилигрим». 9.40 Телегазета. 9.45 «Антреприза». 10.30 «Төп мизгел». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 Рәссам Анатолий Белкин. 11.35 «Милиция хроникасы». 11.45 «Ура, каникуллар!» 12.15, 17.20 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Кем ягы?» 17.50 Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера». 18.15 Сәнгать мәйданы. 18.45 «Сәүдә йорты». 19.00 Мин — әйдәп баручы. 19.25 «Үз уены». 20.25 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.20 «Рек-тайм». 21.50 «Бию-экспресс». 22.10 Губернаторлар клубы. 22.50 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «ЭКС». 23.50 «Уик-энд». Ж.Л.Годар.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.00 Сериал: «Четыре танкиста и собака». 10.15 «Төш юрау». 10.45 «Гүзәллек». 11.15 «Аукцион». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Мультсериал: «В стране веселого детства». 13.35, 15.30 — ТВ мәгълүматлары. 13.50 Көнлек телевизион программа. 13.55 Шәһәр һәм анда яшәүчеләр. 14.25 Нәфис фильм: «Открытая книга». 15.45, 17.35 — «Музыка мизгеле». 15.50 Бакчачыларга киңәшләр. 16.00 Нәфис фильм: «Линия смерти». 17.40 Телефильм: «Грибная пора». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Иртәгәсе көнгә телевизион программа. 23.15 «Гыйбадәтханә». 23.45 Нәфис телефильм: «Жермена и Бенжамен».

ПӘНҖЕШӘМБЕ
3 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.25 «Эфирда — эшлекле мәгълүмат». 18.30 «Айсылу» балалар ансамбле концерты. 18.50 «ГАИ» мәгълүматлары. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Хөкүмәт сәгате». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 Борынгы татар халык җырлары. 20.20 «Ихлас». «Игелек җирдә ятмый». «Нижнекамскнефтехим» акционерлар җәмгыяте Президент-генераль директоры Гаяз Җәмикъ улы Сәхапов. 21.20 Киноның 100 еллыгына. Нәфис фильм: «Война и мир». 4 нче серия. 22.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Межа». 7.30, 20.20, 23.35 — «Шәһәр». Информацион программа. 7.55 Телеэкспресс (2 август тапшыруын кабатлау). 8.20 Мультфильмнар: «Перепись населения», «Банный день». 8.40 Нәфис фильм: «С течением времени» (Һиндстан). 1 серия. 9.45 «Табигать серләре». 10.00 «Барысын да беләргә телим». 10.10 Мультфильмнар: «Обезьянка, вперед!», «Шарман-Шарман». 10.35 «Спутникли телевидение». 17.00 Нәфис фильм: «Машенька» (В.Набоков романы буенча). 18.15 «Видеогид». 18.35 Телесериал: «Саломея». 19.30 Эфирда — музыка. 19.40 «Дорфалар һәм матурлар». 20.10 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 20.45 «Телеэкспресс». 21.05 «Коммерция әйләнмәсе». 21.30 Атна фильмы. Нәфис фильм: «Мадам Фельдмаршал».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.40 --- «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Сәяхәтчеләр клубы». 10.55 «Спортның җиде көне». 11.25 Мультфильм. 11.35 Документаль сериал: «Змеи». 12.20 Нәфис фильм: «Два капитана». 13.35 «Клип-ревю». 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 Мультфильм. 15.20 Эфирда — «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 «Йолдызлар сәгате». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.30 «Ышаныч» телевидениесе. 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телуен: «Көен таны». 20.05 «Без». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.45 Нәфис фильм: «Гамлет». 23.00 «Юрамалар». 23.20 «Спортның җиде көне». 23.50 Эксклюзив.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Телегазета». 9.00 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Музыкаль экспромт». 11.20 «Милиция хроникасы». 11.30 «Сәүдә йорты». 11.45 «Ура, каникуллар!» 12.15, 17.20 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Төрле төстәге призма». 17.50 Нәфис фильм. «Бегство с Юпитера». 18.20 «Сезнең партнер». 18.35 «Карьера». 19.05 «Алты сутый». 19.25 Барлык буын кешеләре өчен музыка. 20.25 Де факто. 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Джентльмен-шоу». 22.05 Телефильм: «Подлинный художник, истинный артист, настоящий убийца». 2 нче серия. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 «Хроно». 0.15 Музыкаль фильм: «Вот я стал богатый сэр».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 9.00 Сериал: «Четыре танкиста и собака». 10.15 Төш юрау. 11.15 «Аукцион». 11.45 «Тәҗрибә». 12.15 «Спартак». 12.40 «Кунак». 15.55 Көнлек телевизион программа. 16.00 Нәфис фильм: «Открытая книга». 17.05 Телефильм: «Вуокса». 17.15, 18.00 — «Музыка мизгеле». 17.20 Бакчачыларга киңәшләр. 17.30 Режиссер О.Ерышев фильмнары. 18.05 Бөтен Россия буйлап. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Иртәгесе көнгә телевизион программа. 23.10 «Наобум». Кинорежиссер А.Рогожкин. 23.30 Спорт гимнастикасы. 0.00 Нәфис фильм: «Жермена и Бенжамен».

ҖОМГА
4 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы.17.55 «Аренада - - кытай циркы».19.00 «Татарстан».19.30 «Видеоспорт».19.45 «Урак өсте».20.05 «Әлли-бәлли-бәү».20.20 «Ислам чакыруы». 20.30 «Җомга көн кич белән». Альманах.21.10 Р.Нуриев исемендәге классик балет фестивалендә. Гала-концерт.22.45 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Ограбление по...» 7.30, 20.20, 22.25 -- «Шәһәр». Информацион программа.7.55 «Турыдан-туры элемтә». (3 август тапшыруын кабатлау). 8.20 Нәфис фильм: «С течением времени». 2 нче серия. 9.05 Кино яңалыклары. 9.25 «Синең һәм минем хакта». Юрий Антонов җырлый. 10.10 «01» тележурналы. 10.45 «Спутниклы телевидение». 17.00 Телесериал: «Криминальные истории». «Спасение». 17.50 Документаль фильм: «Бегство Сент-Экзюпери». 18.40 Мультфильм: «Всю ду жизнь». 18.50 Телесериал: «Саломея». 19.50 «Дорфалар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 «Суперспорт».21.25 Сериал: «Сирены» (АКШ).22.50 Нәфис фильм: «Подземка».

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә».9.00, 12.00, 15.00, 0.50 — Яңалыклар.9.20 Телесериал: «Тропиканка».10.10 Иннокентий Смоктуновский. «Көтеп алынган актер».10.50 «Спортның җиде көне». 11.20 «Экслибрис».11.35 Документаль сериал: «Зубр».12.20 Телесериал: «Два капитана».13.25 «Компас».14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 14.35 Телеуен: «Мине аңла».15.20 Эфирда -- «Мир» телерадиокомпаниясе тапшырулары. 16.00 Балалар өчен телесериал: «Белый клык». 16.25 «Орфей йолдызлыгы».16.35 «Яңа чыибарлык». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 «Рок-дәрес». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Кыргый кыр».19.25 «Кеше һәм закон».19.55 «Могҗизалар кыры».20.45 «Тыныч йокы, нәниләр».21.50 Телесериал: «Камо Грядеши». 22.55 «Юрамалар».23.15 «Караш». 0.10 «Музыкаль күзәтү».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли».8.35 «Ритмика».8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Үтә яшерен». 9.45 Телегазета. 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 Документаль фильм: «Под сенью липовых аллей». 11.20 «Милиция хроникасы». 11.30 «Сәүдә йорты». 11.45 «Ура, каникуллар!». 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Көнгерә». 16.50 «Ай тотучы». 17.50 Нәфис фильм: «Суперпапа». 19.30 Киноафиша. 19.40 «Кайнар униык».20.25 Телесериал: «Санта-Барбара».21.25 Телефильм: «Подлинный художник, истинный артист, настоящий убийца». 3 нче һәм 4 нче серияләр. 22.50 Клип-антракт. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 Нәфис фильм: «Эти старые любовные письма».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.00 «Хәерле иртә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.00 Сериал: «Четыре танкиста и собака». 10.15 «Төш юрау». 10.35 «Кумирлар». 10.45 «Гүзәллек». 11.15 «Коллекционерлар». 11.45 «Тәҗрибә». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «Яшәү стиле». 13.15 Мультфильм: «Белая цапля». 13.35 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.50, 17.10 «Музыка мизгеле». 13.55 Көнлек телевизион программа. 14.00 «Шәһәр һәм анда яшәүчеләр». 14.30 «Камера музыкасы концерты» ретроэкраны. 14.55 Мультфильм. 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 22.40 ТВ мәгълүматлары. 15.45 «Ура, комедия». 17.15 Мультфильм. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Иртәгәсе көнгә телевизион программа. 23.15 Нәфис фильм: «Ночное пение соловья на Беркли сквер».

ШИМБӘ
5 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы.19.00 «Татарстан».19.30 «Үткән белән киләчәк арасында». Тележурнал.19.50 «Өй академиясе».20.05 «Әлли-бәлли-бәү».20.30 Т.Миңнуллин. «Әниләр һәм бәбиләр». Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры спектакле.22.30 Клара Хәйретдинова җырлый.22.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.15 Эфирда — музыка.7.30 «Шәһәр». Информацион программа.7.55 Телеэкспресс (4 август тапшыруын кабатлау).Узган атна тапшырулары:8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (1 август көнендәге тапшыруны кабатлау). 8.35 «Видеомода».8.55 «Камиллек». 9.25 «700 нче клуб». «Җаваплар».9.55 «Enter club». 10.25 «Поза». 10.50 Эфирда — музыка.11.00 Нәфис фильм: «Кащей Бессмертный». 12.00 Документаль фильм: «Летящие (Трасса)». 12.15 «Минем сиңа сүзем бар». 12.35 «Зураб Церетели». 12.50 Нәфис фильм: «Модернисты». 1 нче серия. 13.50 «Искә әйберләр турында яңалыклар». 14.10 Мультфильм: «Пробег». 14.20 «Саф җил». Олег Газманов җырлый. 14.40 Эфирда — музыка. 15.05 Документаль фильм: «Ближний круг А.Кончаловского». 15.45 Мультфильмнар. 16.10 Телесериал: «Тропическая жара».17.10 Телесериал: «Детективы на полставки».18.15 «Фантом». 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар дөньясы». 21.30 Сериал: «Сирены» (АКШ).22.25 Нәфис фильм: «Прощай, моя наложница!»

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 15.00, 0.40 — Яңалыклар. 9.20 «Лего-го». 9.50 Балаларга фильм: «Секреты моего лета». 10.25 «Иртәнге почта». 11.00 «Татлы». 11.15 «Сәламәтлек». 11.50 «Провинция». 12.20 «Бомонд». 12.40 Нәфис фильм: «Большая руда». 14.25 «Көзге». 15.20 «Зур узышлар». 15.50 «Алтын кадр». Ираклий Андроников. 16.35 «Хайваннар дөньясында». 17.15 Телеуен: «Тәвәккәлләргә һәм җиңәргә». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.25 Роберт Рэдфорд мелодрамасы: «Здесь течет река» (АКШ). 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Телесериал: «Камо Грядеши». 22.55 «Көлкеле манзара». 23.45 «Аңа кадәр һәм аннан соң...»

«РОССИЯ»

8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 Документаль фильм: «Отсветы». 8.45 «Шөрептән башлап». 9.00 «Онытылган көн». 9.15 «Бабулештада кич утырулар». 9.45 «Десертка музыка». 10.00 «Пилигрим». 10.45 «Аниматека». 11.15 «Мәскәүгә кадәр ерак». 12.00 Нәфис фильм: «Рождение звезды». 14.20 «Де факто». 14.35 Нәфис фильм: «Мегрэ у министра». 15.20 Документаль фильм: «Горбатые киты — тихие гиганты». 16.15 Мульти-пульти. 16.25 «Алтын шпор». 16.55 Футбол. Россия чемпионаты. 18.55 «Ике катлы портрет». 19.45 «Клип-антракт». 20.25 «Мэрилин Монроның ачышы». 21.20 Җиңел атлетика. Дөнья чемпионаты. 22.15 Телефильм: «Подлинный художник, истинный артист, настоящий убийца». 5 нче серия. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «А» программасы. 0.40 Җиңел атлетика. Дөнья чемпионаты. 1.20 «Төнге сөйләшү». 1.25 Мультфильм.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос — бөтен дөньяда». 8.00 «Хәерле иртә». 10.00 «Яшәү стиле». 10.15 Режиссер О.Ерышев фильмнары. 11.15 Телекөн программасы. 11.20 Нәфис фильм: «Жизнь и удивительные приключения Робинзона Крузо». 12.50 «Минем музыка». 13.20 «Теледоктор». 13.40 Телефильм: «Арктическая Одиссея». 14.35 «Тарихи альманах». 15.05 Нәфис фильм: «Воздушный извозчик». 16.23 Телефильм: «Поздние времена». 16.56 Музыкаль телефильм. 18.00 «Балаларга җәнлекләр турында». 23.05 Нәфис фильм: «Не будите спящую собаку».

ЯКШӘМБЕ
6 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы.18.00 Балалар өчен фильм: «Полет навигатора» (татар теленлә).19.30 Телефильм: «Кырлай». 20.00 «Телевизион буклет». Тапшыру анонслары.20.10 «Әлли-бәлли-бәү».20.30 Фән Вәлиәхмәтов. Иҗат кичәсе.22.05 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

8.00 Эфирда — музыка.8.10 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). Узган атна тапшырулары:10.00 Коммерция әйләнмәсе (3 август тапшыруын кабатлау).10.25 «Видеогид». 10.45 «Мавыгулар дөньясы». 11.15 «Фантом». 12.00 «Суперспорт». 12.20 Эфирда — музыка.12.30 Нәфис фильм: «Модернисты». 2 нче серия. 13.30 «Карденнан комодка кадәрге мода». 13.50 Документаль фильм: «Композиция» (Джаз музыканты В.Ганелин турында). 14.35 Нәфис фильм: «Про Красную Шапочку». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 16.45 Телесериал: «Тропическая жара».17.45 «Кремльдән рок», «С бригадасы». 18.05 А.Вески җырлый. 18.30 Телесериал: «Детективы на полставки».19.30 Мультфильм: «Шарман-Шарман». 19.45 «КиноМеню».20.15 «Җирле вакыт». Информацион программа.20.45 Нәфис фильм: «Охота на мужчину». 22.30 «Исәнмесез!» (5 август тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 9.00, 15.00, 0.40 — Яңалыклар. 9.20 «Иртә таңнан». 9.50 Мультфильм. 10.10 «Бар да өйдә чакта». 10.40 «Иртәнге йолдыз». 11.30 «Россиягә хезмәт итәм». 12.00 Тележурнал: «Бөтендөнья географиясе». 12.45 «Бөтен Россия». 13.15 «Салават күпере» халык иҗаты турында телепрограммаларның X Халыкара фестивале. 13.45 «50 ел элек бу көннәрдә». 14.00 «Пи» билгесе астында. 14.40 Мультфильм. 15.20 «Хыял вокзалы». Ю.Башмет. 16.10 «Сәяхәтчеләр клубы». 17.00 «Европага тәрәзә». Д.Кисилев алып бара. 17.35 Мультсериал: «Доктор Айболит». 18.00 «Вакыт». 18.20 «Театр+ТВ». 19.00 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 19.30 «Кумирлар, кумирлар...» 20.10 Фантастик триллер. «Глубинная звезда» (АКШ). 22.00 «Якшәмбе». 22.55 Телесериал: «Камо Грядеши». 0.05 «Бер күрүдә ярату».

«РОССИЯ»

8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 Документаль фильм: «Свидетельство красоты». 9.00 «Беренче дубль». 9.15 «Алтын ачкыч». 9.30 «Футболга чикләр юк». 10.15 «Хәерле иртә, Европа». 10.45 «Аты, баты...» 11.15 «Консолидация». 11.20 «Рус лотосы». 12.10 «Тапшырулар тартмасы». 12.25 Нәфис фильм: «Нежность». 13.50 «Беренче нөсхә». 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык». 14.35 Нәфис фильм: «Мегрэ у министра». 15.20 «Янәшәләр». 15.35 «Синең мөмкинлекләрең, кеше». 16.05 «Җырлы Бьеннале». Паата Бурчуладзе. 16.55 «Бөтенесе мода турында». 17.25 Әдәби публицистик программа: «Веди». 18.00 Диснейның тылсымлы дөньясы. 18.55 Җиңел атлетика. Дөнья чемпионаты. 20.25 Нәфис фильм: «Ход королевой». 22.15 Мультфильм. 22.25 «Ксюшада кунакта». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.40 «XX гасыр кадрда һәм кадр артында». 0.30 Җиңел атлетика. Дөнья чемпионаты.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез». 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә». 10.00 «Яшәү стиле». 10.15 Музыкаль телефильм: «Петрушка». 10.55 Нәфис фильм: «Шапка Мономаха». 12.00 «Якшәмбе лабиринты». 13.15 Телефильм-концерт: «С улыбкой доброй». 14.10 «Музыка мизгеле». 16.35 «Антре». Цирк программасы. 17.00 Мультфильм. 17.15 А.С.Пушкин. «Медный всадник». 22.15, 23.40 — Телеспектакль: «Мелкий бес». 23.15 ТВ мәгълүматлары.

ДҮШӘМБЕ, 31 ИЮЛЬ

6.00, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 Иртәнге дулкында. 6.43, 20.45 — Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 20.53 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45, 20.53 — Тапшырулар программасы. 8.00, 18.30, 21.00 — Радио-1. 17.45 «Борын-борын заманда». 19.45 Һәвәскәр башкаручылар концерты.

СИШӘМБЕ, 1 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.05 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.43, 20.4[illegible] — Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.[illegible] 20.53 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 20.53, 12.25 — Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18,30 21.00 — Радио-1. 12.25—14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 К.Паустовский. «Телеграмма». Радиопостановка. 17.45 «Яшьлек» студиясе. 18.15 «Көн темаларына». Әңгәмәләр, аңлатмалар. 19.45 С.Хәким шигырьләренә язылган җырлар.

ЧӘРШӘМБЕ, 2 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында». 6.43, 20.45 — Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.25, 20.53 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.[illegible] — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 21.00 — Радио-1. 12.25—13.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Эшмәкәрләр клубы». 19.45 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 3 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.43, 20.30 — Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 20.45 — Радио-1. 12.25—14.30 — «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 «Яшь талантлар». Балалар өчен музыкаль тапшыру. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 Н.Гаетбаев. «Курай моңы». Башкорт яшьләр театры спектакле. 19.45 Яшь башкаручылар концерты.

ҖОМГА, 4 АВГУСТ

6.00 «Балкыш». 6.43, 20.30 — Татарча өйрәнәбез. 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 -- Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00, 13.05, 19.05 — «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 — Радио-1. 12.25—13.30 — «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 «Саз» вокаль ансамбле концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 19.45 Равил Фәйзуллин шигырьләренә язылган җырлар.

ШИМБӘ, 5 АВГУСТ

6.00, 7.00 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58, 7.58, 14.30 — Һава торышы. 7.15 Иртәнге концерт. 7.45, 14.30 — Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00, 11.00, 14.35 — Радио-1. 8.15 «Сезнең хатларыгыз». 8.40 «Көмеш кыңгырау». 9.00 «Әдәби укулар». Р.Мөхәммәдиев. 9.30 «Шигърият». 10.00 Кыска хикәяләр. 10.30 «Пар канатлар». 11.45 «Кардәшлеккә чикләр юк». 12.15 Татар халык көйләре. 13.10 Яңалыклар эстафетасы. 13.30 «Яшьлек» студиясе. 14.00 «Көзге».

ЯКШӘМБЕ, 6 АВГУСТ

7.00, 7.58, 13.15 — Һава торышы. 7.04 «Хәерле иртә!» 7.45, 13.15 — Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00 «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 9.00 Л.Ихсанова. «Җир астында җиде көн». Радиопостановка. 9.30 «Гасырларны бәйләүче җеп». 10.15, 16.00 — Радио-1. 11.45 «Кредо». 12.15 Ял концерты. 13.20 «Татарстан дулкынында». 13.50 М.Маликов. «Синең өчен үзем үләрмен». Әлмәт татар драма театры спектакле.

ӘҖЕР ҖИҢЕЛ БИРЕЛМИ

Әдәбият һәм сәнгать әһелләрен кызыксындырган сорауларга Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) директоры, язучы Рәфкать КӘРАМИ җавап бирә.

Сорау. Сез җитәкләгән оешманың төзелүенә ике ел тулды...

Җавап. Гафу итәсез, төзелүенә ике ел дип әйтү дөреслеккә бик үк туры килмидер. Әйе, Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев кул куйган Указ моннан нәкъ ике ел элек, 1993 елның 2 июнендә, басылып чыкты. Министрлар Кабинеты мине директор итеп 1993 елның 17 декабрендә билгеләде, ә Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы турындагы положение былтыр 22 мартта гына расланды.

Сорау. Димәк, Указ чыгу ул әле оешу дигән сүз түгел икән.

Җавап. Әйе. Шулай да без, оештыру эшен озакка сузмыйча, 1994 елның июль аеннан төп вазифабызны үтәүгә керештек.

Сорау. Яңадан Указга әйләнеп кайтыйк әле. ТАИСны төзегәндә нинди максатлар күздә тотылды?

Җавап. Бу Указда: «Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә авторлык һәм аңа бәйле хокукларны яклау буенча эшчәнлекне тәэмин итү зарурлыгыннан чыгып, Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) төзергә», диелә. Иң мөһим бурычлар итеп, ТАИСка авторлык һәм аңа бәйле хокукларны саклау даирәсендә тәкъдимнәр эшләү һәм дәүләт сәясәтен тормышка ашыру, шулай ук авторлык һәм аңа бәйле хокуклар турында Татарстанда гамәлдә булган законнарның үтәлүенә контрольлек итү вазифасы йөкләнә.

Сорау. Закон димәктән, бездә андый законнар бармы соң?

Җавап. Үзегезгә мәгълүм, Татарстан территориясендә Россия Федерациясенең байтак законнары гамәлдә. Без дә РФнең 1993 ел, 9 июльдә кабул ителгән «Авторлык хокуклары һәм аңа бәйле хокуклар турында»гы Законы белән эш итәбез. Бу законда авторларның хокуклары һәм аларны яклауга кагылышлы бик күп мәсьәләләр чагылыш тапкан. Әйтик, кем автор дип санала, авторлык хокуклары турында гомуми төшенчәләр, аның таралыш чикләре, аңа ия булган объектлар, әсәрләр һ.б.

Сорау. Безнең газета әдәбият һәм сәнгать тормышын чагылдырачак. Шуңа күрә, язучылар, композиторлар, рәссамнарның Сезнең оешма документларында каралган кайбер хокуклары турында әйтсәгез иде.

Җавап. Менә шуларның берсе. Мәсәлән, авторлык хокукы, автор исән чагында гына түгел, вафат булганнан соң да 50 ел буена саклана. Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм шул чорда эшләүчеләр өчен мондый хокук чиге тагын 4 елга арттырыла. Репрессиягә эләккән әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең варислары белеп торсыннар: аларның 50 елы акланган елдан башлап санала, үлгән елдан түгел.

Тагын шундый яңалыкны искәртик. Бер әсәрне ике яки берничә автор иҗат итәргә мөмкин. Бу очракта 50 еллык авторлык хокукы соңгы автор вафат булганнан соң гына санала башлый. Авторлык хокукы барлыкка килсен өчен, хәзер бернинди дә теркәү яки махсус рәсмиләштерү таләп ителми. Әсәр кәгазьгә төшкән икән, шул минуттан ул авторлык хокукына да ия дигән сүз.

Сорау. Авторларның шәхси хокуклары нидән гыйбарәт?

Җавап. Автор булып саналу хокукы: исемгә хокук, ягъни әсәрне үз исемең белән яисә псевдоним белән файдалану һәм файдаланырга рөхсәт итү; әсәрне халыкка җиткерү, игълан итү яки игълан итәргә рөхсәт бирү хокукы һәм кире алу хокукы; әсәрне, аның исемен яклау һәм авторның абруена зыян китерә торган хәлләрдән саклау. Минемчә, болар бик мөһим хокуклар. Чөнки автор рөхсәтеннән башка аның әсәрен бастыру, алай гына да түгел, исемен һәм эчтәлеген теләсә ничек үзгәртү очраклары бик еш күзәтелә. Бөтен кеше дә Әмирхан ага Еники кебек таләпчән һәм батыр кеше була алмый. Бигрәк тә яшь язучыларның иҗатына сак кагылу очраклары тормышта булып тора. Хәер, аларга карата гына микән...

Сорау. Болар шәхси, ягъни, үзмилек белән бәйләнмәгән хокуклар. Ә менә икътисадка, акчага бәйле хокуклар нидән гыйбарәт?

Җавап. Болар — әсәрне күпләп чыгару, тарату, прокатка биреп тору, чит илләрдә бастыру, халыкка күрсәтү һәм башкару хокуклары. Радио һәм телевидениедән тапшыру, тәрҗемә итү, яңадан эшкәртү дә шушылар рәтенә керә.

Сорау. Ә менә авторның рөхсәтеннән башка әсәрне файдалану һәм аны файдаланган өчен гонорар түләмәү очраклары бармы?

Җавап. Бар. Ләкин алар бик чикләнгән. Моны авторлар белеп торсын иде һәм бигрәк тә файдаланган кешеләр сак эш итсеннәр иде. Шәхсән үзе өчен генә файдалану, фәнни хезмәтләрдә цитаталар китерү, аерым өзекләр, газета-журналларда басылган сәяси, икътисадый, социаль һәм дини мәкаләләрне, сәяси нотыкларны, өндәмәләрне, докладларны күпмедер күләмдә куллану очраклары була. Ә менә басылып чыккан әсәрләрне сукырлар өчен, суд өчен файдалану, музыка әсәрләрен рәсми һәм дини тантаналар, матәм җыеннарында файдалану рөхсәт ителә. Кабатлап әйтәм, монда бик сак эш итәргә кирәк. Һәр очракта закон кысаларыннан чыгарлык булмасын. Чөнки ахыры хәерле бетмәскә мөмкин.

Сорау. Башкаручылар, тавыш язу студияләре, декоратив-гамәли сәнгать оешмалары белән дә эш итәсезме?

Җавап. Әйе. Аларның хокукларын да яклыйбыз, гонорар түләүне дә таләп итә алабыз.

Сорау. Гонорар димәктән, мәсьәләнең бу ягы ничек каралган, һәм ул бездә нинди хәлдә?

Җавап. Россия Федерациясе хөкүмәтенең 1994 ел, 21 мартта кабул ителгән карарында бөтенесе дә бәйнә-бәйнә күрсәтелгән: оригиналь драма әсәрләре, инсценировкалар, тәрҗемәләр, музыкаль-драматик әсәрләр, концертлар, эстрада, цирк программалары һ.б. Сәхнә әсәрләре олылар яки балалар өченме, проза яки шигырь белән язылганмы, кыскасы, һәрберсенә гонорар түләү аермачык әйтелгән. Композиторга, язучыга, рәссамга күпме түләнергә тиешлеге дә билгеле. Әгәр мисаллар китерә башласам, газетада урын җитмәс иде. Чөнки безгә һәркөн кешеләр килеп тора. Һәрберсендә нинди дә булса сорау... Шуны гына әйтәсе килә, бу документта режиссерлар турында бер сүз дә юк. Алар зарлана. Әйе, кызганычка каршы, режиссер спектакльнең авторы (пьесаның түгел) булса да, ничектер аларга түләү каралмаган. Бу кемнеңдер күреп җиткермәве булды микән, махсус эшләнде микән — әйтә алмыйм. Бәлки киләчәктә бу гаделсезлек бетерелер.

Сорау. Авторлар нәшрият, газета һәм журналлар белән килешү төзегәндә үзләрен ничегрәк яклый алалар?

Җавап. Кызганычка каршы, безнең авторлар элек тә, хәзер дә иркенләп эш итә алмыйлар. Чөнки җөмһүриятебездә карап торган ике нәшриятыбыз бар: Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф» нәшрияты.

Сорау. Гафу итәсез, хәзер нәшриятлар байтак түгелме соң?

Җавап. Әйе. Хәтерем ялгышмаса, йөз иллеләп. Аларның йөздән артыгы үзебездә теркәлгән, егерменләп нәшрият — Россия Федерациясендә. Язучы китап чыгарырга барыбер фәкать алда исемнәре телгә алынган нәшриятларга гына бара ала.

Сорау. Авторлар кем беләндер килешү төзегәндә нәрсәләргә игътибар итәргә тиеш?

Җавап. Автор килешү төзегәндә әсәрне файдалану ысулы, вакыты һәм территориясе, гонорар күләме, аны түләү тәртибе һәм вакыты, тираж кебек нәрсәләрнең игътибарга алынуы зарур. Авторлык договоры язма рәвештә төзелергә тиеш. Әсәрне көндәлек матбугатка биргәндә телдән дә килешенергә мөмкин. Болардан тыш, заказ биреп эшләтү очраклары булды. Бүгенге көндә ул бәлки бөтенләй юктыр да инде.

Сорау. Хәзер авторлык хокукына бәйле мәсьәләләр турында бераз сөйләшеп алыйк.

Җавап. Мондый хокуклар башкаручылар, фонограмма эшләүчеләргә, радио һәм телевидение оешмаларына кагыла. Боларның һәрберсе аерым сөйләшүне сорый. Шуны гына әйтә алам: әле бу өлкәдән берсенең дә, безнең хокукларны яклагызчы, дип килгәннәре юк.

Сорау. Ни өчен?

Җавап. Чөнки алар безнең оешманы читләтеп үтәргә тырышалар. Бүгенге көнне республикада егермедән артык концерт бригадасы бар. Сүз филармониягә карамаган коллективлар турында бара. Без алар белән инде бер ел буе көрәшәбез. Нәрсә хакында, дип соравыгыз ихтимал. Авторларга тиешле гонорарны түләү хакында. Закон буенча алар һәр концерттан композиторлар һәм шагыйрьләргә өлеш чыгарырга тиеш. Ә менә кайбер коллективлар, шуны түләмәс өчен, нинди генә сәбәпләр уйлап тапмыйлар. Югыйсә, шагыйрь — сүзләрен, композитор көен язмаса, җыр булмый бит. Кайбер җырчылар, филармониядән китеп, я бөтенләй анда эшләмичә, үзләреннән-үзләре группалар оештырдылар. Аларның күбесе җир белән күк арасында (чөнки теркәлгән урыннары да юк). Менә шуңа күрә мондый төркемнәр бездән читләшү ягын карыйлар.

Сорау. Барысы да шулай закон бозамыни?

Җавап. Юк, әлбәттә. Зөфәр Билалов һәм Зәйнәп Фәрхетдинова группасы, Асаф Вәлиев бригадасы, «Җидегән» оешмасы һ.б.лар авторлар хакын даими рәвештә безгә күчереп баралар. Кызганычка каршы, кайбер яшьләр беренче көннән үк закон бозу юлына бастылар.

Сорау. Сез аларга карата нинди чаралар кулланасыз?

Җавап. Әсәр өчен тиешле әҗерне фәкать суд аша гына юллап алачакбыз.

Сорау. Андый мисаллар әле булмагандыр?

Җавап. Булды һәм булачак.

Сорау. Ә Мәдәният министрлыгы, театрлар белән эш ничек тора? Чөнки драматурглар...

Җавап. Тел төбегезне аңладым. Мәдәният министрлыгы, шәхсән аның җитәкчесе Марсель Таишев белән, беренче көннән үк үзара аңлашып эшлибез. Хәзер барлык театрлар, филармония, ансамбль җитәкчеләре — безнең таянычыбыз. Районнар һәм шәһәрләрдәге мәдәният идарәләре җитәкчеләре дә безнең сүзгә колак сала башладылар. Кыскасы, бүгенге көндә безне аерып торган киртәләр, чишелмәстәй мәсьәләләр юк.

Сорау. Сезнең эшегез Татарстан белән чикләнәме?

Җавап. Юк, әлбәттә. Без үзебезнең авторларны теләсә кайда якларга бурычлы. Ләкин моның өчен безгә башка дәүләтләрдәге оешмалар белән бәйләнешкә керергә кирәк. Аның өчен исә иң әүвәл Россия авторлар җәмгыяте (РАО) белән эшне көйләү зарур. Без узган елның июль аеннан бирле Мәскәүгә авторлык гонорары җибәрәбез. Без болайрак уйладык: үзара аңлашып эшләү өчен кемдер беренче адымны ясарга тиеш. Аны без ясадык. Аннары без Мәскәүгә килешү проекты әзерләп җибәрдек. Озак кына көттереп, алардан җавап килде. Яңә сөйләшүләр башланды. Бүген мин әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре өчен куанычлы хәбәр җиткерәм: 6 июльдә, Мәскәүдә Россия авторлык җәмгыяте (РАО) белән Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) арасында килешүгә кул куелды. Килешү үзара тигез шартларда төзелде. Чөнки без — мөстәкыйль оешма. Бүген мин килешүнең эчтәлегенә тукталып тормыйм. Шуны гына әйтә алам: авторлар һәм аларның мәнфәгатьләре үзәктә тора.

Сорау. Сез хәзер дәүләт хезмәткәре, ягъни, чиновник...

Җавап. Бәхеткә, әле миңа чиновник дип әйткән кеше юк. Чөнки безнең ишек һәрвакыт һәм һәркемгә ачык.

Сорау. Кабинет ишеге һәрвакыт һәм һәркемгә ачык булган директорны беренче күрүем.

Җавап. Минем әле кабинетым да юк бит. (Булса да ишеге ачык торыр иде). Без, бөтен агентлык хезмәткәрләре, бер бүлмәдә утырабыз. Безне вакытлыча Язучылар йортына сыендырдылар.

Сорау. Сезгә бина бирергә тиешләрдер бит?

Җавап. Әле генә сез күздә тотып әйткән чиновникларның ишекләрен ачуы бик авыр. Аннары, алар өчен Президент Указы ни дә, Министрлар Кабинеты карары ни — мыеклары да селкенми.

Сорау. Сөйләшүне бераз төшенкерәк рухта тәгәллибез түгелме?

Җавап. Юк. Мин хәзер аларның кыланышларына күнегә башладым инде. Доресен генә әйткәндә, үзем өчен сорамыйм, әдәбият һәм сәнгать әһелләре өчен тырышам бит.

Сорау. Сөалебезнең соңгысы: сезнең оешмадан нинди дә булса файда бармы?

Җавап. Анысын инде ай саен гонорар алып торучы авторлардан һәм авторларның варисларыннан сорарга кирәктер.

Сорау. Җавап уңай булыр шикелле?

Җавап. Һичшиксез!..

ЖИДЕ БУЫН ЯДКАРЕ

Сирәк кулъязмалар ишәя

Борынгы китаплар фондын баету буенча Татарстан Милли китапханәсе үзенең күптөрле эзләнүләрен дәвам иттерә. Соңгы вакытта китапханә хезмәткәрләре юлыккан кайбер кызыклы табышлар белән газета укучыларны да таныштырмакчы булабыз. Күптән түгел генә Шиһабетдин Мәрҗани нәселе варисларыннан Суфия ханым һәм Мөхмүд ага Мостафиннар безгә бабалары Габдулла Апанаевтан калган китапларны тапшырдылар. Габдулла Апанаев (1862-1919) — үз чорының күренекле җәмәгать эшлеклесе, Казанның мәшһүр милләтпәрвәр муллаларыннан берсе, мөхәррир һәм нашир. Җәмәгате исә — Шиһабетдин Мәрҗанинең кызы Хауа (1870-1945). Габдулла хәзрәт Апанаевның төрле янгын-афәтләрдән исән калган бай китапханәсенең бер өлеше озак еллар буена оныклары Мостафиннар кулында сакланган. Китапларның һәрберсенә хуҗасы тарафыннан «Г.Апанаев милке» дип язылган. Кыйммәтле җиде берәмлек кулъязма, шулай ук Казанда, Төркиядә, Мисырда, Һиндстанда басылган 30 китап һәм кулъязмалар сирәк китаплар бүлегендә үз урыннарын алды. Басма китапларның берничәсендә — Ш.Мәрҗани кызы Хауаның автографлары; арада Мәрҗанинең үз кулы белән язылганы һәм шәхси мөһере сугылганы да бар. Әлеге китаплар арасында Мәрҗанинең үз әсәрләре дә күп. Кулъязма китапларны Мөхмүд ага берничә ел элек академик Әбрар Кәримуллинга биргән булган, ә соңгысы, үз чиратында, аларны Милли китапханәгә тапшырды. Әйтергә кирәк, кулъязмалар, шактый борынгы булсалар да, яхшы ук сакланган.

Казан шәһәренең 1 нче татар гимназиясен (элекке 35 нче мәктәп) белмәүчеләр бик сирәктер. Татарстан Милли китапханәсе гимназия җитәкчелеге (хәзерге директоры Фәния Мифтахова) белән тыгыз элемтә урнаштырды. Бу мәктәп-гимназиядә гаҗәеп бер музей эшләп килә. Нинди генә экспонатлар юк анда: мамонт һәм бизон сөякләре дисеңме, борынгы болгар сугышчысының очлымы, Болгар шәһәрлегеннән табылган көнкүреш һәм сугыш кораллары дисеңме, Казан шәһәрендәге Татар бистәсенең үткән тормышын төрле яктан чагылдыручы әйберләр, стенд һәм альбомнар, борынгы кулъязма һәм басма китаплар... Озак еллар музейның җитәкчесе булып эшләүче тәҗрибәле укытучы Гөлчирә ханым Шәмсетдинованың һәр экспонат хакында, Татар бистәсенең тарихы турында сәгатьләр буена сөйләрлек мәгълүматы бар. Гимназиядә шундый бай музейның булуы, һичшиксез, балаларның милли үзаңын сизелерлек үстерергә ярдәм итә.

Безнең исә бу хакта сүз башлауның сәбәбе — гимназия һәм музей җитәкчеләренең, татар кулъязмаларының тарихи әһәмиятен аңлап, аларны Татарстан Милли китапханәсенә тапшыруларында.

Гимназия музееннан килгән кызыклы кулъязмалар арасында сүздә эшләренә кагылышлылары, аерым алганда, 1765-1767 елларда теркәлгән татарча хосусый актлар һәм «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе» аеруча игътибарга лаеклы язма истәлекләрдән санала. 1751 елда Һиндстанга сәфәр кылган Исмәгыйль Бикмөхәммәд угълы сәяхәтнамәсенең моңа кадәр фәнгә тугыз язма нөсхәсе мәгълүм иде. Милли китапханәгә тапшырылган нөсхә дә шактый тулы (ахырдан ике бите генә югалган) һәм яхшы хәлдә сакланган. Күчерелү вакыты — XIX гасырның беренче чиреге.

Халкыбызның аңы, хәтере, тарихы теркәлгән язма һәм басма китапларның тарихи әһәмиятләрен тирәнтен аңлаган милләттәшләребезгә олы рәхмәтебезне белдерәсе килә. Мондый кадерле ядкарьләрнең турыдан-туры шул юнәлештә эш алып баручы гыйльми оешмаларда саклануы күптармаклы фән дөньясы һәм киләчәгебез өчен дә отышлы, дип уйлыйм.

Раиф МӘРДАНОВ,
Татарстан Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире.

Бу санда Р.МӨХӘММӘТҖАНОВ (1 нче бит), Ә.ШӘФИГУЛЛИН төшергән һәм авторларның шәхси архивыннан алынган фотолар, Р.ХӘСӘНШИН, А.ҮТӘГӘНОВ рәсемнәре файдаланылды.

АРЫСЛАН ЙОЛДЫЗЛЫГЫ АСТЫНДА ТУГАННАР

КОТЛЫЙБЫЗ!

29 июль

КУЗНЕЦОВА Евгения Борисовна — В.Качалов исемендәге Рус зур драма театры режиссеры ярдәмчесе;

РӘСҮЛОВА Фәридә Аттилла кызы — шагыйрә;

ГАБДУЛЛА ШӘРӘФИ (Шәрәфетдинов Габдулла Шәрәфетдин улы) — язучы.

30 июль

СӨНГАТУЛЛИНА Зилә Даян кызы — РФнең атказанган, Татарстанның халык артисты, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисты;

1 август

ГАНИЕВ Фуат Әшраф улы — Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының бүлек мөдире, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы;

ЗАЙЦЕВ Владимир Николаевич — Яшь тамашачылар театры артисты, Татарстанның атказанган артисты;

МИҢНУЛЛИН Роберт Мөгаллəм улы — шагыйрь, Татарстанның халык депутаты, Дәүләт Советының даими комиссия рәисе, «Сабантуй» газетасының баш мөхәррире.

2 август

ДӘҮЛӘТШИНА Асия Минзакир кызы — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры артисты.

3 август

АБДРАХМАНОВА Кәүсәрия Әхмәт кызы — Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле артисты.

ЙӨРӘКТӘН — ЙӨРӘККӘ...

Былбыл көнләшә беләме?

Чыннан да, былбыл көнләшә беләме икән? Әгәр мондый хис сайрар кошка ят түгел икән, бу хатымда аның бер көндәше турында әйтмәкче булам.

Һәр татар кешесе кебек, мин үлеп җыр яратам. Җырчыларыбызның күбесен тавышларыннан таныйм. Аларга рәхмәтем зур. Шулай да яраткан җырчыларым арасында аеруча күңелгә якыны бар: ул — Татарстанның халык артисткасы Зилә Сөнгатуллина.

Яшермим, бу җырчыбызга мин ихлас күңелдән гашыйкмын. Тавышына да, сәхнәдә, экранда үз-үзен инсафлы тотуына да, хәтта аның затлы һәм тыйнак киенүенә дә! Халкыбызның талантлы, гүзәл һәм үтә дә итагатьле кызы ул Зиләбез.

Опера сәнгатендә аның талантны югары бәяләнә — анысын да беләм. Ә минем татар халык җырларын, композиторларыбызның лирик әсәрләрен Зилә Сөнгатуллина үзәккә үтәрлек моңлы һәм шулкадәр самими башкара — сокландыргыч!

Теләгем: Зилә ханым, экранга ешрак чыгып, күбрәк җырлагыз әле! Ә инде безнең якларга килеп чыксагыз, без Сезне ипи-тоз белән каршы алыр идек. Аллаһ тарафыннан бирелгән табигый талантыгызга баш июче буларак, мин Сезгә озын гомер, саулык-сәламәтлек һәм бәхет телим.

Нурасмә ФАЗЛИӘХМӘТОВА,
шәфкать туташы.
Алабуга районы,
Морт авылы.

РЕДАКЦИЯДӘН. ***Хөрмәтле укучыларыбыз! Әгәр сез үзегезнең яраткан сәнгать осталарына ихлас сүзегезне, теләк һәм тәкъдимнәрегезне ирештерергә телисез икән, рәхим итегез: «Мәдәни җомга» мөнбәренә һәрвакыт чыгып сөйли аласыз. Сездән хатлар көтәбез.***

«Мәдәни җомга»

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыл[ыла]

Баш мөхәррир
Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбаса[ры]
Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип
Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-06-76 — баш мөхәрр[ир] урынбасары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлар[ы];
32-66-22 — публицисти[ка], очерк, сәясәт бүле[ге];
32-59-22 — әдәбият бү[леге];
32-57-48 — сәнгать бү[леге];
32-12-08 — тәнкыйть, тарих ...;
32-62-79 — мәдәният яңал[ык]лары, мәгълүм[ат], тәрҗемә бүл[еге];
32-59-55 — халык тормыш[ы], рухияте я[ңа] хатлар бү[леге];
32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче[ләр];
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редак[ция] фикере белән муафыйк б[улма]маска да мөмкин

Хатлар, кулъязмалар, [фо]тографияләр, рәсемнәр бәяләмә бирелми һәм а[вторга] кире кайтарылмый

Газетада басылган язма[ла]рны, фотографияләрне ф[айдаланганда], шулай ук өз[ек]ләр китергәндә, «Мәд[әни] җомга»дан алынганлы[гын] күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру ө[чен] заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүл[ләр]нең төгәллеге өчен рекла[ма] бирүчеләр үзләре җавап[лы]

Безгә иганәләк ярд[әм] күрсәтергә теләүчел[әр] өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
609403 МФО 265566
в Бауманском отд. ПС[Б]

Газета Татарстан Республикас[ы] Мәгълүмат һәм матбуг[ат] министрлыгында 428 нче таныклык бел[ән] теркәлде

Индекс — 541

Редакция адресы:
420503, Казан,
Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы:
420066, Казан,
Декабристлар урамы,

Басмаханә гаебе бе[лән] җибәрелгән сыйфат җит[ешсез]лекләре уңаен[нан] 49-36-62 номерлы теле[фон] буенча шалтыратырга

Газета редакциянең к[ом]пьютер үзәгендә эшлән[де]

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һә[м] журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4451